ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

№07 (402)
ИЮЛЬ 2025

1920 ЕЛДАН НӘШЕР ИТЕЛӘ

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

ТАТАРСТАН ИНЖИНИРИНГЫ – ЯПОН ДИҢГЕЗЕНДӘ

4 612750 670011

№07 (402)
ИЮЛЬ 2025

16+

Редакция:
Адрес: 420066, Россия,
Татарстан Республикасы,
Казан, Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина, vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров, sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасары: Фәридә Әхмәтҗанова
Әдәби мөхәррир: Луиза Янсуар
Бүлек мөхәррирләре: Руфия Фазылова, Николай Коновалов, Евгения Чеснокова, Дмитрий Сивков
Авторлар: Олеся Бондаревская, Илсөяр Закирова, Әхмәт Шакиров, Әлфия Шаһиева, Айдар Шәйхин
Фотографлар: Александр Ефремов, Лилиана Вәлитова
Дизайн-макет: Олег Бурилов
Вёрстка: Анастасия Хатыйпова
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Тышлыкта: «Союзхимпромпроект» институты директоры Павел Кочнев. Максим Платонов фотосы

Журнал 1920 елдан нәшер ителә
1977 елда Халыклар дуслыгы ордены белән бүләкләнә

ММЧ исеме: ТАТАРСТАН TATARSTAN

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәттә теркәлгән. Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Тираж:
2 400 данә
Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан» журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела. Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри. Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция җавап бирми.

«Татарстан» журналы шулай ук рус телендә 2350 данә тираж белән чыга.
Гомуми тираж: 4750 данә.
Реклама 16+

Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә басылды. Адрес: 420066, Россия, Татарстан Республикасы, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ №: М-1275
Басарга кул куелды: 16.07.2025
Чыгу көне: 22.07.2025

Коммерция директоры:
Рәшит Хәйретдинов,
тел.: (843) 222-09-76, +7-9600-487-900

Коммерция директоры урынбасары:
Алина Майорова,
тел.: (843) 222-09-76, +7-9033-132-741

Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Ирина Захарова, irinamoroz10@mail.ru

Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел.: (843) 222-09-80

РЕДАКЦИЯДӘН

– ҖӘЙ, СИН КАЙДА?

Социаль челтәрләр һәм мессенджерларда артык эссе температуралар белән куандырмаган һәм яңгырлар белән дөньяны томалап алган җәйнең җәй булмавына уфтанучылар шактый булды.

Һәм менә җәй безнең ялваруларны ишетте бугай: бар кызулыгында һәм хозурлыгында кире әйләнеп тә кайтты. Кәефебез бермәбер күтәрелеп китте! Шуны гына көткәндәй, «Татарстан» моңарчы игътибар читендәрәк кала килгән үзебезнең туристик территорияләрне йөреп чыгарга ашыкты. Бу урыннар кадерле рәссамнарыбыз, режиссёрларыбыз, артистларыбыз, шагыйрьләребез, кыскасы, бар дөньяга атаклы шәхесләребез белән бәйле. Татарстанның аларны хәтерләгән урыннарын, бәлки, сез дә белеп бетермисездер...

Озын сүзнең кыскасы, без җәебезне файдалы итеп уздырабыз. Сезгә дә шуны телибез! Туризм бит төрле була: рәхәтләнеп ял итү белән бергә яңа урыннар һәм тарихлар да ача алсак, икеләтә яхшы. Туган Татарстаныбыздагы истәлекле урыннар буйлап йөрегез, яңа ачышлар ясагыз!

Сезнең сәяхәт итәргә яратучы редакциягез

Редакция советы:
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рәфкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛАХОВ Мәгъзүм Хәлимуллович
ФАЗЛЫЕВА Ләйлә Ринатовна
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

ТАТ МЕДИА

Гамәлгә куючы: «ТАТМЕДИА» АҖ
Нәшер итүче: «ТАТМЕДИА» АҖ
Адрес: 420097, Россия, Татарстан Республикасы, Казан, Академическая ур., 2

«Татарстан» журналына ТРның барлык элемтә бүлекләрендә язылырга мөмкин:
Индекс **П2381** – татар телендә ярты елга
Индекс **ПА468** – татар телендә бер елга

Индекс **П2378** – рус телендә ярты елга
Индекс **ПА471** – рус телендә бер елга

2025 елның ярты еллыгына ТР буенча язылу бәясе:
1305 сум 00 тиен китерел биреше,
1274 сум 28 тиен соратып алганда.
2025 елга ТР буенча язылу бәясе:
2610 сум 04 тиен китереп биреше,
2548 сум 46 тиен соратып алганда.

«Татарстан» журналына РФ буенча онлайн-язылу:
Индекс **П7077** – татар телендә
Индекс **П7076** – рус телендә

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫНА 104 ЯШЬ

ТАТАРСТАННЫҢ 100 җәүһәре

бары тик татарстанда

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ, ТӘҮГЕ КӨН

«1552–1920 ел, 25 июнь – татар хезмәт ияләренең үзбилгеләнүе турындагы актны гамәлгә ашыру көне. Яшәсен автономияле ТАССР! Яшәсен РСФСР!» Зур-зур хәрефләр белән язылган бу язу Сөембикә манарасын 105 ел элек – 1920 елның 25 июнендә бизәп тора. Төп тантана кич белән Кызылармиячеләр сараенда оештырыла. Халык хакимиятне Татар республикасына тапшыру бәйрәменә җыела. «Татар республикасы хезмәт ияләре исеменнән, – дип белдерә трибунадан республиканың беренче җитәкчесе, Ревком рәисе Сәхибгәрәй Сәетгалиев, – барлык хезмәт ияләренең фикерен белдереп, Россия Республикасының Бөтенроссия Үзәк Башкарма комитеты рөхсәте белән эшләгән Ревком бүгеннән башлап яңа республика белән идарә итү вәкаләтләрен Казан губерна башкарма комитетыннан үз өстенә ала!» Кич белән болай да кызыл комиссар кебек бизәлгән Сөембикә манарасын бәйрәм иллюминациясе яктырта. Электрга кытлык заманда моңарчы күрелмәгән муллык. Ләкин иң матур бүләк – балаларга. Сабыйларга ул көнне 1/8 фунт (илле граммнан аз гына артыграк) ландрин өләшәләр. Татлы конфетларның күптән онытылган тәменә ата-ана да кызыгып карап торгандыр.

© «Татарстан» журналы

WWW.PROTATARSTAN.RU

ЭЧТӘЛЕК

акыллы гамәлләр

4. Файда китерә торган миллиардлар
Илкүләм проектлар тормышны ничек яхшы якка үзгәртә

6. Татарстан инжинирингы – Япон диңгезендә
Сәнәгать проектлары юнәлешендә кем алдынгылыкта

10. Камиллеккә юл
Цифрлы трансформация буенча кайсы төбәкләр беренчелектә

12. Электрон форматтагы гадел хөкем
Хыял яисә чынбарлыкмы?

игелекле эшләр

18. «Исемдә калганнар» буенча
Тукай эзләрен ничек яңартырга

22. Останың күзгә язы
Бакый Урманче каян көч һәм илһам алган

54. Гамьле әңгәмә
Филармония нинди уй-хыяллар белән яши

58. Сугыш эзләре буйлап
Эзтабарлар элекке сугыш кырларыннан нәрсәләр таба

62. 41 ел балалары
Сугыш чоры балалары нинди авырлыклар күргән

мәңгелек кыйммәтләр

66. Онытылмас исемнәр
Беренче татар совет философы кем булган

73. Әдәбиятта хатын-кыз галәме
Лена Шагыйрьҗан шигърияткә ничек килгән

78. Китап киштәсе
Китап дөньясында нинди яңалыклар бар

80. Татарстан авыллары
Тарихлы Тымытык авылы бүген ни белән гаҗәпләндерә

88. Казанның агач архитектура һәйкәлләре
Арбузовлар йорты ничек сакланган

Фото: kino-teatr.ru

Тулырак мәгълүмат түбәндәге сайтта:
protatarstan.ru

Акыллы гамәлләр

26.06

Михаил Карисалов, «СИБУР» ГАҖ генераль директоры, идарә рәисе, – Казанда, катализаторлар җитештерү заводы төзелешен башлап җибәргәндә:

– Бүген без, фундаменталь тикшеренүләрне, гамәли инженерияне, цифрлы технологияләрне һәм индустриаль компетенцияләрне берләштереп, инновацияле платформа булдырабыз. Технологияләрне бер урынга туплап кына калмыйбыз, бәлки яңа базарлар ачабыз һәм тармакны үстерүнең күп елларны күздә тоткан яңа стандартларын эшлибез. Бу эшне буш урында башлап җибәрмибез. Татарстан гаять зур сәнәгать, фән һәм кеше потенциалына ия.

Игелекле эшләр

26.06

Федор Добронравов, РФ халык артисты, – Казанда, «Семь дней Петра Семёныча» фильмы премьерасыннан соң:

– Мин Казанны бик яратам һәм монда булуым белән бәхетле. Әлбәттә, бу шәһәргә беренче генә килүем түгел, монда театр белән гастрольләргә килгәләдем, күп кенә премьераларым да биредә үтте. Кайсы яктан карасаң да, бик җылы: урамда гына түгел, күңелдә дә. Сездә бик рәхәт атмосфера, сулавы җиңел.



Мәңгелек кыйммәтләр

30.06

Рөстәм Гаффаров, Казан башкарма комитеты рәисе, – мэриядә узган киңәшмәдә:

– Һөнәри яктан нәрсә белән генә шөгыльләнсәк тә, безгә ышанычлы тыл, ныклы гаилә, туган калабыз белән элемтә һәм уңайлы тел мохите кирәк. Нәкъ менә шуңа күрә мэрия эшенең өстенлекле юнәлешләренең берсе – туган телләрне саклау һәм үстерү, шулай ук милли-мәдәни проектларга ярдәм күрсәтү.

Фото: tatar-inform.ru, tatarstan.ru, vk.com/fedor_dobronravov_svati

игелекле эшләр

акыллы гамәлләр

мәңгелек кыйммәтләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Татарстанда **күпме** илкүләм проект гамәлгә ашырылган

Япон диңгезендә Татарстан инжиниринглы **нәрсә** эшли

Цифрлы трансформация программасын тормышка ашыруда **кемнәр** алда бара

Республикада гомуми юрисдикция судлар системасының беренчел звеносы **ничек** торгызыла

ТАТАРСТАН ИЛКҮЛӘМ

46,9 млрд сум

13 илкүләм проектны
һәм Магистраль инфраструктураны модернизацияләү һәм киңәйтүнең комплекслы планын гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән,

Шул исәптән:

29,5 млрд сумы
федераль бюджет акчалары

17,4 млрд сумы
Татарстан Республикасы бюджеты акчалары

ИЛКҮЛӘМ ПРОЕКТЛАРНЫ ГАМӘЛГӘ АШЫРУ НӘТИҖӘСЕНДӘ:

- Балалар өчен мәктәпкәчә белем алу мөмкинлеге **100%** тәшкил итә
- Гражданнарның **65,8%ы** физкультура һәм спорт белән даими шөгыльләнә
- Гражданнарның спорт корылмалары белән тәэмин ителү дәрәҗәсе **72,5%** (бер үк вакытта үткәрү сәләтеннән чыгып исәпләнгән)
- Хезмәткә сәләтле гражданнардан өлкәнрәкләрнең **70%ы** профилактик тикшеренүләр (диспансеризацияләүне кертеп) уза
- Бөтен халыкның **74,28%ы** ел саен профилактик медицина тикшеренүләре һәм (яисә) диспансеризацияләү уза
- Җәмәгать фикере бәяләмәләренә караганда, халыкның медицина ярдәменнән канәгать калу дәрәҗәсе **62,9%**
- **828,5 мең** кеше кече һәм урта эшкуарлык (шәхси эшкуарларны да кертеп) өлкәсендә мәшгуль
- Электрон рәвештә күрсәтелә торган массакүләм социаль әһәмияттәге дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең өлеше **100%** тәшкил итә
- Торак төзелешенең күләме **3,45 млн** квадрат метрны тәшкил итә
- **355** иҗтимагый киңлек төзекләндерелгән

РЕСПУБЛИКАСЫНДА ПРОЕКТЛАР*

311 объект
төзелгән һәм ремонтланган

Кулланугa тапшырылган:

6 Казанда, Яр Чаллыда, Биектау һәм Лаеш районнарында **гомум белем бирү мәктәбе**

+

Питрәч районында «Алгоритм» Технологик лицее» МБМУнең **өстәмә корпусы**

Капиталь төзекләндерелгән:

2 **спорт залы** Тукай һәм Ютазы районнарында

42 иҗтимагый **киңлек төзекләндерелгән,**
шул исәптән парк һәм скверлар

Сәламәтлек саклау объектлары:

төзелгән **23**

капиталь төзекләндерелгән **105**

Мәдәният учреждениеләре:

18 капиталь төзекләндерелгән, шул исәптән **14** авыл мәдәният йорты

Муниципаль районнарда **103** **юл челтәре объекты** норматив хәлгә китерелгән

* *2024 йомгаклары буенча*

ЯПОН ДИҢГЕЗЕНДӘ ТАТАРСТАН ИНЖИНИРИНГЫ

«СОЮЗХИМПРОМПРОЕКТ» – ИМПОРТНЫ АЛМАШТЫРУ ДУЛКЫНЫНДА

Олеся Бондаревская

Институт директоры Павел Кочнев тамырлары совет чорыннан булган проект оешмасының югары конкуренциягә ия сәнәгать проектлашыруы базарында ни рәвешле алдынгы уенчыга әверелүе хакында сөйли.

– Павел Владимирович, сәнәгать өлкәсендә бүген кадрлар өчен чын мәгънәсендә көрәш бара, күп компанияләр өчен белгечләр җитешмәү – бу бит җитди проблема. Ә «Союзхимпромпроект» бер ел эчендә штатны 490 кешедән 600 гә кадәр арттырды. Яңа хезмәткәрләрнең күпчелеге 35 яшьтән дә яшьрәк. Шулкадәр яшь белгечне җәлеп итү өчен сез, башка предприятиеләрдән аермалы буларак, нәрсә эшләдегез?

– Беренчедән, без шартлар тудырдык. Бүген яшьләр эш бирүчедән күпне көтә, конкурентлыкны безнең файдага авыштыра алырдай эш хакы гына җитми. Уңайлы һәм чиста экологияле система булуы да зарур. Без хәзер аны булдыру юнәлешендә эшлибез. Яшьләр советы, актив ял, кызыклы чаралар, остаханәләр – болар барысы да инде бар, аларга ихтыяҗ да бик нык сизелә. Әмма без ирешкәндә генә тукталып кала торганнардан түгел.

Фото: Максим Платонов. РЕКЛАМА

– Бу инвестицияләр үзен аклыймы?

– Санкцияләр һәм импортны алмаштыруга курс алу нефть химиясе һәм нефтьне эшкәртү объектларын проектлауга искиткеч зур ихтыяҗ тудырды. Эшебездә совет дәвереннән институтта калган иң яхшы нәрсәләрне саклап калырга һәм заманча технологияләрне дә вакытында кертергә насыйп булды. Заказларның зур күләменә әзер идек. Үсешкә инвестицияләр кертү, ә иң беренче чиратта, кадрлар мәсьәләсе, безнең өчен – өстенлекле өлкә.

ҖИҺАЗЛАР – ЮГАРЫ СЫЙФАТЛЫ, ҮСЕШ – СОФТ ДӘРӘҖӘСЕНДӘ

– Импортны алмаштыру темасын дәвам итеп... «Союзхимпромпроект» Россия продуктларына күчә алдымы? Бу процесста иң катлаулысы нәрсә?

– Без Россия җитештерүчеләреннән бик күп офис техникасы, шул исәптән компьютерлар белән ноутбуклар сатып алдык. Алар барысы да югары сыйфатлы. Ә менә программа белән тәэмин итү катлаулырак. Кайбер җитештерүчеләр дәүләт заказын үтәгәндә, Россия программасын кулланырга дигән законны продуктларны куллланучының ихтыяҗларына туры килерлек итеп җиренә җиткереп эшләп бетерүдән саклый торган калкан рәвешендә кабул итә. Дөрес, безнең сүзгә колак салып эш итәргә әзер торучылар да бар. Исәп-хисаплар ясау һәм документлар әйләнеше буенча Россия программалары безнең ихтыяҗларны тулаем канәгатьләндерә. Шуны да әйтергә кирәк: үзебезнең программа белән тәэмин ителеш юнәлеше дә үсә, камилләшә, сыйфат һәм функционал ягыннан дөнья дәрәҗәсенә чыгу перспективасы бар.

– Проектлауда ясалма фәһем куллануга ничек карыйсыз?

– Бу – зур потенциалы булган кызыклы технология. Проектлау документациясен эшләп чыгу өчен әлегә тиешле дәрәҗәдәге чишелешләрне табып бетермәдек, әмма ЯФ мөмкинлекләрен проект документациясенә экспертиза ясаганда сыныйбыз. Нәтиҗәләр начар түгел.

– Сез импортны алмаштыру сәнәгать төзелеше өчен көчле этәргечкә әверелде, дидегез. Хәзерге вакытта иң югары нокта нинди?

– Иң тиз үсештәге юнәлешләрнең берсе – аз тоннажлы химия. Нефтьхимия компанияләре процесска актив кушылды, чөнки аңлыйлар – технологик мөстәкыйльлек икътисади яктан перспективалы.

ТӨП СЫНАУ – КАРАРЛАРНЫ ТИЗ АРАДА ИНТЕГРАЦИЯЛӘҮ

– Иң кызыклы проектлар турында сөйләгез әле.

– Без иң эре заказчыларыбызның берсе – «Сибур» өчен Тобольскида полиолефиннар синтезы үзәген проектладык. Бу полиэтилен, полипропилен, полистролның яңа маркаларын җитештерү буенча мини-завод, дисәк тә була. Асылда, компания илебездәге полиолефин ихтыяҗын каплый алырлык мөмкинлек тудыра, димәк, бу инде импортны алмаштыру да булып чыга. Воронеж белән Казанда әлеге компания катализаторлар җитештерүне җайга салып җибәрәчәк. Воронежда – N-бутиллитий, каучук җитештерү катализаторын. Кайчандыр бу төр җитештерү илдә булган, хәзер исә технологияләр модернизация кичерде. Казанда берничә катализатор фабрикасы гамәлгә керәчәк. Алар полимерлар җитештерү өчен төрледән-төрле катализаторлар чыгаруны күздә тота, бу исә АКШ, Япония, Европа, Кытай импортын алмаштырачак. Тагын бер заказчы – «Аммоний – 2» компаниясеннән кызыклы



проект бар. Хәзерге вакытта алар экологик һәм баш дәүләт экспертизасын уза (журнал басарга әзерләнгәндә, инде уңай нәтиҗәләр билгеле булды. – **Ред. иск.**).

– Санкцияләр аркасында кайбер чит ил партнёрлары Россиягә җиһазлар китерүне туктатты. Сезнең андый партнёрлар белән эшләү тәҗрибәгез бармы?

– Соңгы ике-өч елда без сәнәгать объектларын җиһазлар алмаштыру ягыннан берничә мәртәбә яңадан проектладык. Иң эре шундый заказларның берсе – «Казаноргсинтез»дагы реакторны модернизацияләү. Инде эшләп торган җитештерүгә яңа технологияләр кертү белән беррәттән, сроклар зур кыенлык тудырды. Яңа эшләүчеләрне сайлаганнан соң, документациягә төзәтмәләр кертер өчен, безнең нибары 2 аебыз калды. Шөкер, бу сынауны да узып чыктык, 2024 елның декабрендә объект эксплуатациягә тапшырылды.

«ТӨЗЕЛЕШ СТАДИЯСЕНДӘ КЛИЕНТНЫ КИРӘКМӘГӘН СЮРПРИЗЛАР КӨТӘРГӘ ТИЕШ ТҮГЕЛ»

– Зур проектлар вакытында килеп чыгарга мөмкин хәтәр нәрсәдә, аңардан ничек котылып була?

– 400-500 ләп проектлаучы, ягъни бөтен институт катнашырга тиешле зур проектлар субподрядчылар белән эшне киңрәк җәелдерергә этәрде. Монда да яңа проблемалар белән очраштык: төрле бюро һәм институтларда эшкә мөнәсәбәт тә төрле, подрядчы кинәт кенә бөлергә мөмкин, төрле төбәкләрдә яшәп эшли торган белгечләрнең үзара эшчәнлеген җайлаштырырга туры килә һ.б. Ахыр чиктә, проектлар белән идарә итүгә үз мөнәсәбәтебезне дә яңадан карап чыгарга кирәк булды. Хәзер һәр проектка бер төркем җитәкче беркетелгән. Бу төркемгә проектның баш инженеры, баш инженерның урынбасары, берничә ярдәмче керә. Ярдәмчеләр эш вакытының күпчелек өлешен проект барышында субподрядчы территориясендә уздыра. Проблемалар килеп чыгуы сизелсә, без алмаш эзли башлыйбыз. Находка минераль ашламалар заводы һәм «Аммоний» проектларында шундый хәлләр булды, әмма без, тиз арада күреп-аңлап алып, вакытны сарыф итмәдек, проект үз срогында тапшырылды.

– Хәзер яшь кадрлар гына түгел, ә клиентлар да шактый таләпчәнгә әверелде. Бу тренд сезгә дә кагылдымы?

– Беренчедән, без һәрвакыт заказчыга экспертиза белән ярдәм итәбез. Заказчының ышаныч язуы буенча документацияне Баш дәүләт экспертизасына җибәрәбез, килешү төзибез, нәрсә дөрес булмавын ачыклыйбыз, төзәтмәләр кертәбез. Икенчедән, без гадәттә махсус бүлекләрне эшләп бетерүне үз өстебезгә алабыз, махсус шартларны җиренә җиткерү куркынычсызлыкны тәэмин итә. Безнең заказчы подрядчыны озак сайларга мөмкин, процесс та сузыла, дигән сүз. Без инде кайсы компанияләр тиз һәм тиешле срокларда эшләгәнне яхшы беләбез. Өченчедән, безнең биредә, Татарстанда, эзләнү бүлекчәләребез бар, без чит төбәкләрдән дә эшне дөрес башкаручыларны таба алабыз. Монда да контроль сорала, чөнки барлык эзләнү компанияләре дә үз эшләрен җиренә җиткереп башкармаска мөмкин, ә бу урында инде кирәк булмаган сюрпризларга тап була аласың.

«ПРОЕКТЛАУ – БЕЗНЕҢ ҖАВАПЛЫЛЫК ЗОНАСЫ, ТӨЗЕЛЕШ БАШКА РЕСУРСЛАР ТАЛӘП ИТӘ»

– Ягъни, икенче төрле әйткәндә, сез тулы цикллы инжиниринг компаниясе буласыз?

– Проект документациясен әзерләү буенча – әйе, әмма без төзелешне үз өстебезгә алмыйбыз.

– Ни өчен?

– Кайвакыт проектлаудан төзелешкә килүчеләр техник карарларны артык арзанайту ягына басым ясый башлый, бу еш кына сыйфат белән куркыныч-

сызлык кагыйдәләренә зыян китерү хисабына булырга мөмкин. Ә бу – безнең юл түгел...

– Бу юнәлештә партнёрлар эзлисезме?

– Әлегә бездә мондый төр хезмәттәшлек чит илләр белән җайга салынган. Россиядәге компанияләр арасында бүген бик аз оешмалар гына аерым объектларга түгел, ә тулы комплекслы төзелешкә алынырга әзер.

– Чит ил төзүчеләре белән хезмәттәшлек хакында тулырак сөйләсәгез иде.

– «Делим» Көньяк Корея компаниясе белән без «Аммоний» өчен проект әзерләдек. «Чэнда» Кытай компаниясе белән Находка минераль ашламалар заводы өчен төзелеш проектын эшләдек. Бу дөнья күләмендә әлеге юнәлештәге иң зур җитештерүләрнең берсе булачак, ә Россиядә гомумән иң зуры саналачак. «Чэнда» генподрядчы булып тора, без алар өчен проект әзерлибез.

– Үзенчәлеге нәрсәдә?

– Объект Япон диңгезендә, янартау (сопка) өстендә төзелә. Эшнең иң авыр өлеше – вертикаль планлаштыру. Чөнки сопкаларның бер өлеше киселә, ә аскы катламына вак таш салып калдырыла. Күптеррасалы җитештерү мәйданчыгы барлыкка килә. Хәзерге вакытта фундаментның якынча 90%ы эшләнгән. Моның өчен Кытайдан бик куәтле саналган йөк краннарының берсен китерделәр. Аңа алмашка дип, төзелеш комплексы өчен үзебездә дә кран җыйдылар, ул илдә иң зуры санала. Беренче чиратны – табигый газны метанолга әйләндерү комплексын кулланышка кертү 2027 елга исәпләнгән. Шуннан соң, төзелешнең икенче чираты башланып китәчәк: ул аммиак һәм карбамид җитештерүе булачак.

«ЧИТ ИЛ ТЕХНОЛОГИЯЛӘРЕН РОССИЯ НОРМАЛАРЫНА ЯРАКЛАШТЫРАБЫЗ, МОҢА ИХТЫЯҖ БАР»

– Халыкара проектларда катнашуны арттырырга ниятлисезме?

– Билгеле вакыйгаларга кадәр без Иран компаниясе белән эш башлаган идек, ул Ленинград өлкәсендә метанол җитештерүен төзергә тиеш булды. Хәзерге вакытта техник бирем формалаштырыла. Безнең бурыч – төп техник карарларны (ТТК) эшләп бирү, Иран технологияләрен Россия нормаларына туры китерү. Проектны дәвам итә алырбыз, дип ышанасы килә. Моннан тыш, Кытай төзүчеләре белән эшчәнлекне дәвам итү күздә тотыла. Башка заказлар да бар.

– Россиядә комплекслы зур проектларга әзер компанияләр әллә ни күп түгел, дидегез. Алар артсын өчен, сезнеңчә, нәрсә кирәк?

– Компанияләр мондый төр тәҗрибәгә ия булсын өчен, тиешле төзелешләрнең саны артырга тиеш. Хәзерге вакытта күпчелек җитештерүчеләр, кредитларның кыйммәтле булуы сәбәпле, проектларны туктатып тора. Аз тоннажлы нефть-химия өлкәсендә дәүләт дәрәҗәсендә тормышка ашырыла торган проектларга ярдәм каралса, бу бик зур этәргеч булыр иде. Тагын бер ысул бар – универсаль технопарклар булдыру, аларда дәүләт ярдәме белән беррәттән, кооперация форматы да була ала. Алар заказ буенча үзебезнең базарга кирәкле күләмнәрдә продукция чыгаруны җайга сала алыр иде. Шартлар тудырырга кирәк, ә илебездәге кече һәм урта сәнәгать бизнесында потенциал да, кызыксыну һәм компетенцияләр дә бар.

ЦИФРЛАШТЫРУ:

ЦИФРЛЫ ТРАНСФОРМАЦИЯ* ПРОГРАММАСЫН

Дмитрий Григоренко, Хөкүмәт Рәисе урынбасары – РФ Хөкүмәте Аппараты җитәкчесе:

Россия үзебезнең технологияләрне үстерүгә басым ясый һәм төрле тармакларда ясалма фәһем кертү буенча актив эшли. ЯФ зур икътисадый нәтиҗәлелеккә ия була, төрле бурычларны үтәүне тизләтә һәм гадиләштерә ала. Бездә чит илнекеннән калышмый торган технологияләр күп, биометрия буенча сервислар да бар, алар көндәлек тормышны җиңеләйтә, мәсәлән, кунакханәләргә урнашу яки КФҮ хезмәтен алганда.

Фото: kremlin.ru, government.ru

КАМИЛЛЕККӘ ЮЛ

ГАМӘЛГӘ АШЫРУ БУЕНЧА ТОП 5 РОССИЯ ТӨБӘГЕ

Цифрлы трансформация программасын гамәлгә ашыру буенча ТОП-5 ведомство

1. РФ Хезмәт министрлыгы
2. Росавиация
3. Росгвардия
4. Россия мәгариф күзәтчелеге
5. Россия социаль фонды

Владимир Путин, РФ Президенты:

Россия икътисады технологиялерәк булырга тиеш. Һәм бу теләк түгел – бу бүгенге һәм иртәгәге көннең объектив таләбе, көчлерәк булырга теләсәк, һичшиксез җавап бирергә кирәкле таләп.

5

Сахалин өлкәсе

ЦИФРЛЫ ТРАНСФОРМАЦИЯНЕҢ МАКСАТЫ – технологияләр хакына технологияләр түгел, чыннан да һәр кешенең тормыш шартларын яхшырту. Һәр проект, һәр инициатива дәүләт хезмәтләрен алуны – уңайлырак, хакимият белән аралашуны – гадирәк, көндәлек тормышны җайлырак итүгә юнәлдерелгән.

ТӨБӘК ЭШЧӘНЛЕГЕН БӘЯЛӘҮ КРИТЕРИЙЛАРЫ – дәүләт хезмәтләре һәм тормыш ситуацияләре, ясалма фәһем, күрсәткечләр һәм хисап эшләре, импортны алыштыру, мәгълүмат куркынычсызлыгы, социаль өлкә, тармакка ярдәм күрсәтү.

** Агымдагы елның маена булган мәгълүмат. РФ Хөкүмәте рейтингы Түбән Новгородта узган «Сәнәгый Россиянең цифрлы индустрия» конференциясендә тәкъдим ителде.*

ХАЛЫКЧАН ЮСТИЦИЯ

Евгения Чеснокова

Әгәр Россиядә яшәүченең суд системасына эше төшсә, 70 процент очракта бу җәмәгать суды, гомуми юрисдикция судлары системасының беренчел звеносы булачак. Республикада әлеге институтның ничек торгызылуы һәм аның бүгенгесе турында Татарстан Республикасы юстиция министры Рөстәм Заһидуллин белән сөйләштек.

ХАЛЫККА МӨМКИН КАДӘР ЯКЫНРАК

– Рөстәм Илдусович, ни өчен җәмәгать судьялары институтын торгызу турында карар кабул ителде?

– Минем уйлавымча, моның төп ике сәбәбе бар. Беренчесе: район һәм шәһәр

Фотолар ТР Рәисе матбугат хезмәтеннән алынды

судларына, нигездә, зур булмаган эшләр буенча, гаять зур йөкләнеш төшә иде. Икенчесе: халыкка мөмкин кадәр якынрак суд системасын оештырырга кирәк булды. Һәм 1998 елда «Россия Федерациясендә җәмәгать судьялары турында» закон кабул ителде. Ә 2000 елда шундый ук канунны Татарстанда да кабул иттеләр.

– Эшне нәрсәдән башладылар һәм 25 ел эчендә нәрсәләр эшләнде?

– 2000 елда республикада җәмәгать судьяларының 168 суд участогы төзелде. Бүгенге көндә алар 190, бер участокка 15–23 мең кеше туры килә. 2000 елның көзендә республика Дәүләт Советы тарафыннан беренче 103 кеше җәмәгать судьясы вазыйфасына билгеләнде. Аларның бишесе, сүз уңаеннан, әлегә кадәр эшли.

Системаны асылда нульдән төзеделәр. Биналар юк. Суд өчен бина табылса да, анда еш кына элементар уңайлыклар да каралмаган була, кирәкле компьютер техникасы турында әйтеп тә торасы юк. Хәтта кәгазь һәм канцелярия товарлары да җитешми иде.

Бүген вазгыять тамырдан үзгәрде. Бигрәк тә 2014 елдан соң, Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов карары белән «Татарстан Республикасында юстицияне үстерү» дәүләт программасы раслангач. Аңа «Социаль һәм инженерлык инфраструктурасын үстерү» төбәк проекты керә. Проектта биналарны матди-техник яктан тәэмин итү дә, капиталь ремонтлау да каралган. Әгәр 2000 елда суд участогының мәйданы 90 квадрат метр булса, бүген ул 180 квадрат метрдан артык. Бу күрсәткеч буенча Татарстан Идел буе федераль округында алдынгыларның берсе. Участоклар хәзер барлык кирәк-яраклар белән тәэмин ителгән – җиһазлар, техника, видео-конференц-элемтә системалары...

ҖӘМӘГАТЬ СУДЬЯЛАРЫ ЭШЛӘРНЕҢ БАРЛЫК КАТЕГОРИЯЛӘРЕН КАРЫЙ, ӘММА, КАГЫЙДӘ БУЛАРАК, БУ КАТЛАУЛЫ ЭШ ТҮГЕЛ – ӘГӘР ҖИНАЯТЬ ЭШЕ БУЛСА, ҖӘЗА СРОГЫ ӨЧ ЕЛГА КАДӘР КАРАЛГАН ҖИНАЯТЬЛӘР БУЕНЧА; ӘГӘР ФИНАНС БӘХӘСЛӘРЕ ИКӘН, БӘХӘС СУММАСЫ 50 МЕҢ СУМНАН АРТМАСКА, СҮЗ АЕРЫЛЫШУ ТУРЫНДА БАРСА, БАЛАЛАР ТУРЫНДА БӘХӘС БУЛМАСКА ТИЕШ.

ТӘҖРИБӘ ХУПЛАНА, МӘНФӘГАТЬЛӘР КОНФЛИКТЫ – ЮК

– Без Татарстанда җәмәгать судьясының якынча портретын ясый алабызмы?

– Аңа уртача 45 яшь. Араларында хатын-кыз бераз күбрәк исәпләнә: 97 судья, 81 е – ир-ат. Тагын җәмәгать судьяларының аппаратлары бар: секретарьлар, канцелярия хезмәткәрләре... Менә анда эшләүчеләрнең 97 %ы – хатын-кыз.

– Җәмәгать судьясы булу өчен нәрсә кирәк?

– Беренчедән, яше 25 тән дә ким булмаска тиеш, юридик эш стажы – кимендә биш ел. Шунысы мөһим: юридик стаж белем алганнан соң гына исәпләнә башлый. Әгәр кеше студент елларында кайдадыр эшләгән икән, бу исәпләнми. Моның үз логикасы бар. Судья – кеше язмышына кагылышлы карарлар чыгара, билгеле бер тормыш һәм һөнәри тәҗрибәгә ия булмаганда, мөгаен, ниндидер тайпылышлар күзәтелергә мөмкин.

Җәмәгать судьяларын Югары суд тәкъдим иткән белгечләр арасыннан республика Дәүләт Советы раслый. Әмма иң әлек кеше җитди квалификация имтиханы тапшырырга тиеш.

Казан шәһәре Киров районы җәмәгать суды бинасын капиталь төзекләндергәннән соң, бирегә Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов килде.

Капиталь төзекләндергәннән соң, Арча районы җәмәгать суды бинасы да ачылды.

ҖӘМӘГАТЬ СУДЬЯЛАРЫ ИНСТИТУТЫ РОССИЯДӘ 1917 ЕЛГЫ ИНКЫЙЛАБКА КАДӘР БУЛГАН, СОВЕТ ЧОРЫНДА ЮККА ЧЫГАРЫЛГАН ҺӘМ БАРЫ ТИК XX ГАСЫР АХЫРЫНДА ГЫНА ЯҢАДАН ТОРГЫЗЫЛГАН. 2025 ЕЛДА ТАТАРСТАННЫҢ ҖӘМӘГАТЬ ЮСТИЦИЯСЕ ЧИРЕК ГАСЫРЛЫК ЮБИЛЕЕН БИЛГЕЛӘП ҮТӘ.

«Мәнфәгатьләр конфликты» дигән төшенчәгә аерым игътибар бирелә. Мәсәлән, ире прокуратурада, Эчке эшләр министрлыгында яки адвокатурада эшләүче хатын-кыз судья булырга тели икән, бу мәнфәгатьләр конфликтын китереп чыгара, бу очракта кандидатура расланмаячак.

– Безгә мәгълүм булганча, җәмәгать судьяларының эше бик күп...

– Әйе, дөрес, һәм ул елдан-ел арта бара. 2005–2008 елларда җәмәгать судьялары елына якынча 300 мең эш караган, бер судьяга 1800ләп эш туры килгән. Ә узган ел алар 872 мең эш караган, бу бер белгечкә 4,5 меңнән артык эш дигән сүз. Саннар зур, әмма ышаныч белән шуны әйтергә була: җәмәгать юстициясе бу йөкләнешне күтәрә ала.

ЭЛЕКТРОН ФОРМАТТАГЫ ГАДЕЛ ХӨКЕМ

– Бүген цифрлаштыруга йөз тотабыз. Бу җәмәгать судьялары эшендә чагыламы?

– Цифрлы карарлар гражданнарның хакимият органнары белән үзара хезмәттәшлеген җиңеләйтү өчен уйлап табылган. Суд хакимияте дә искәрмә түгел. «Электрон гадел хөкем» проекты гамәлгә ашырыла – җәмәгать судына онлайн мөрәҗәгать итү мөмкинлеге бар. Моңа кадәр документларны суд участогына шәхсән китерергә (ягъни эштән китәргә, юлга вакыт сарыф итәргә) яки рәсми кәгазьләрне почта аша җибәрергә кирәк иде (бу да вакыт һәм акча сарыф итү). Шулай булгач, электрон гариза бирү гражданнарга бурычны җиңеләйтә. Хезмәт күрсәтү торган саен популярлаша бара: 2023 елда электрон рәвештә 90 меңнән артык гариза бирелгән булса, 2024 елда бу сан 142 меңгә җитте.

Карарларның үтәлешен тәэмин итүче суд приставлары хезмәте белән судларның электрон хезмәттәшлеге дә уңайлы. Узган ел судьялар приставларга электрон рәвештә 170 меңнән артык документ җибәргән. Быел без җәмәгать судьяларының Эчке эшләр министрлыгы, Росреестр һәм салым хезмәтләре белән үзара хезмәттәшлеген электрон форматка күчерергә планлаштырабыз

ТӘҖРИБӘДӘН БЕР ОЧРАК

– Без җәмәгать судьяларының ваграк эшләрне караулары турында сөйләшкән идек. Бу системада шау-шу куптарган процесслар булмыймы?

– Кызыклы хәлләр килеп чыккалый. Күптән түгел, мәсәлән, бер эш каралды: берәү, кибеттә «бер плюс бер» (бер товарны тулы бәясенә сатып аласың, икенчесен – бер сумга) акциясе барлыгын белгәч, 31 әйберне үз бәясеннән сатып алган, тагын 31 товарның һәрбесе өчен берәр сум түләгән. Ягъни ул 62 әйбер сатып алган. Ә өйгә кайткач, үз бәясеннән алынган бер әйбернең дә үзенә туры килмәвен «ачыклаган». Ә менә бер сумлыклары бик яхшы туры килгән. Һәм гражданин, тулы бәядән сатып алынганнарны кире кайтарырга дип, кибет килгән. Әлбәттә, кибеттә акчаны кайтарудан баш тартканнар. Ул судка мөрәҗәгать иткән. Әмма судья бу очракта сатучы ягына басты.

– Мөгаен, гражданин бигүк канәгать калмагандыр... Гомумән, җәмәгать судьялары эшенә шикаятьләр еш киләме? Бәлки, киресенчә, аларга рәхмәтләр язалардыр?

– Конституция буенча безнең җәмәгать судьялары башкарма хакимият органнарыннан бәйсез, шуңа күрә аларның эшен судьялар бергәлеге контрольдә тота. Тик менә суд аппараты хезмәткәрләре – алар Юстиция министрлыгы хезмәткәрләре, шулай булгач, әгәр аларның гамәлләренә карата нинди дә шикаятьләр бар икән, без, әлбәттә, тикшерәбез. Узган ел мең ярымга якын шикаять теркәлде. Шактый кебек. Ләкин аларның күбесе тикшерү вакытында нигезсез булып чыкты. Гомумән, җәмәгать судьялары аппараты эшенә карата нинди дә дәгъвалар булса, безгә язмача да, электрон рәвештә дә, 8 (843) 222-60-30 телефоны буенча да мөрәҗәгать итәргә мөмкин.

Әмма җәмәгать судлары эше турында уңай фикерләр дә аз түгел. Күптән түгел, мәсәлән, Яр Чаллыдан инвалид хатын-кыз рәхмәт язган, участокка үзе килеп йөри алмаган. Суд хезмәткәре, телефон аша консультация биреп, аңа мәсьәләне хәл итәргә булышкан. Физик мөмкинлекләре чикле кешеләргә суд белән хезмәттәшлек итү уңайлы булсын өчен, кулдан килгәннең барысын да эшлибез. Менә мондый рәхмәтләрне ишетү, әлбәттә, бик күңелле.

акыллы гамәлләр

игелекле эшләр

мәңгелек кыйммәтләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Җәйне **ничек** файдалы итеп үткәрергә

Тукай эзләрен **ничек** яңартырга

Бакый Урманче Кече Салтыкны **ни өчен** яраткан

Николай Фешин **кайда** тәрбияләнгән һәм укыган

Татарстанның халык артисты **ничек** җырлый башлаган

Фото: Әхмәт Шакиров

ТАТАРСТАН: ДАҺИЛАР ТӨБӘГЕ

Июль аенда елдан да яхшырак нәрсә булырга мөмкин? Тик бер нәрсә бар – ял Татарстанда булырга тиеш. «Татарстан» журналы редакциясе моны җәй саен гамәлдә исбатлый, чөнки тулы составта республика буйлап сәяхәткә чыга. Төрле елларда чираттагы ялыбызны Идел, Чулман, Нократ һәм Агыйдел ярларында үткәрдек. Татарстан күлләрен күреп ләззәтләндек, кайвакыт экстримнан да баш тартмадык. Тыюлыклы урманнар арасына кереп, Болгар белән Зөянең, Чистай белән Алабуганың архитектура җәүһәрләренә һәм борынгы һәйкәлләренә сокландык...

Ә быел нишләргә? Үткәннәрне кабатларгамы?! Юк, әлбәттә! «Татарстан»ның быелгы ял маршруты күңелле генә түгел, истәлекле, танып-белүне тирәнәйтерлек тә булырга тиеш, дип хәл ителде редакция планеркасында. Без танылган якташларыбызның яшәү һәм иҗат итү урыннары буйлап сәяхәткә чыгарга карар кылдык. Татарстан үзенең матурлыгы белән генә түгел, күренекле шәхесләре белән дә дан тота бит.

Әгәр басманы укыгач, сезнең дә безнең юлдан сәяхәткә чыгасыгыз килә икән, димәк, ялыбыз уңышлы да, файдалы да узган.

«НӘКЪ КАЗАН АРТЫНДА БАРДЫР...» ТУКАЙ МАРШРУТЫ

Фәнзилә Мостафина

Казанның да, Татарстанның да, гомумән, татар милләтенең чын мәгънәсендә брендына әверелгән Тукай – гел телебездә һәм күз уңыбызда. Дөрес, XX йөз башы әдәби ренессансы вәкилләре белән бәйле тарихи һәйкәлләребезне саклый алмавыбыз өчен ачынырга яратабыз. Моңа сәбәпләр дә юк түгел. Шулай да, туристларга күрсәтер урыннарыбыз бар.

Тукай 27 генә ел яшәсә дә, эзләре Казанда, Татарстанның кайбер районнарында, Россия төбәкләре белән калаларында сакланып калган. Болар – Арча һәм Балтач районнарындагы Кушлавыч, Өчиле, Сасна Пүчинкәсе, Яңа Кырлай авыллары; Казан, Җаек, Санкт-Петербург. Шулай да шагыйрьнең киндек каны тамган, иҗатына кабатланмас каһарманнар белән рух биргән Арча төбәге – иң әһәмиятлесе. Әйдәгез, андагы Тукай маршрутын барлап карыйк әле: нәрсәләр карарга, күрергә, ни хакына барырга була икән?

ТУКАЕВЛАРНЫҢ КУШЛАВЫЧТАГЫ МУЗЕЙ-ЙОРТЫ

Адрес: Кушлавыч авылы, Тукай урамы, 61 нче йорт

«Тукай ягы»ндагы әдәби маршрутта иң билгеле һәм үзенчәлекле нокта ул, әлбәттә, Кырлай. Әмма без маршрутны барыбер дә шагыйрьнең туган авылыннан башлыйк әле – Кушлавычтан. Казан ханлыгы чорында нигез салынган бу авыл хәзер Утар-Аты авыл җирлеге составына керә. Аны Ту-

Фотолар «Г.Тукай дәүләт әдәби-мемориаль музей комплексы» ДБУ дан һәм Тукай томнарыннан алынды

кай үзе болай искә ала: «*Атам Мөхәммәтгариф авылымыз Кушлавычка кайтып, мулла булмыштыр. Өчиле карьясе Зиннәтулла хәзрәтнең Мамдүдә исемле кызыны алмыштыр. Анам илә бер ел ярым кадәр торгач, беренче бала уларак, мин дөньяга килгәнмен. Минем туганыма 5 ай заман үткәч, атам аз гына вакыт авырып тәрке дөнья итмештер*» (Г.Тукай, «Исемдә калганнар»).

Мөхәммәтгариф кайткан мәхәллә дә, авыл да шактый нык, җитеш тормыш белән яши. Казан якын булганлыктан, сәүдә, һөнәрчелек алга киткән була. Яңа ысул белән укыта торган мөгаллимнәр дә, матбугат белән әдәбият та килеп ирешә.

Кушлавычтагы Тукаевларга багышланган нигез-йорт 1976 елда – Тукайның 90 еллыгына багышлап ачыла. 1996 елда биредә «Тукаевлар утары» комплексы торгызыла. Фондларда 610 берәмлек теркәлгән. Иң кыйммәтле экспонатлар арасында шагыйрьнең әнисе Бибимәмдүдә абыстайның шәхси әйберләре – чәйнеге, аш тәлинкәләре бар.

Музей территориясендә Иван Новосёлов ясаган Тукай бюсты да куелган. Авыл зиратында Тукайның әтисе – җиде буын мулла нәселеннән булган Мөхәммәтгариф Тукаев җирләнгән.

Шагыйрь бу авылда 1886 елның 14 (26) апрелендә аваз сала. 4 ай ярым чагында атасы кату зәхмәтеннән үлә. Шул ел азагында, улын вакытлыча Шәрифә карчыкка калдырып, 23 яшьлек Бибимәмдүдәне Сасна Пүчинкәсенә 69 яшьлек Мөхәммәтшакир Фәйзуллинга кияүгә бирәләр.

Тукаевлар гаиләсе музей-йорты мөдире Ләйлә Мөхәммәтшина бер әңгәмәсендә болай ди:

– Авыл халкы Тукайның туганнарын беренче мәртәбә 1946 елда каршы ала. Тукай ак фәрештәгә тиңләгән апасы Бибисаҗидә кызы белән кайта. Әтиләре бер, әниләре башка булган Газизә апасы 1949 елда улы Хөсәен Зәбиров белән кайтып, нигез урынына кереп, дога кыла...

САСНА ПҮЧИНКӘСЕ

Адрес: Татарстанның Балтач посёлогыннан 25 км төньяктарак, Көшкәт елгасы буенда урнашкан

Сасна Пүчинкәсе хәзерге вакытта Балтач районына карый. Авылның төп урамы Тукай исемен йөртә, мәчетләренә «Бибимәмдүдә» исеме бирелгән. Тукай көннәрендә киң җәмәгатьчелек вәкилләре, әдипләр Бибимәмдүдә каберен зыярәт кылырга кайта, ел әйләнәсендә дә халык өзелми.

Тукайның әнисен матур, зифа буй-сынлы, уңган хатын дип хәтерлиләр. Ник соң ул, шулай ашыгып, үзеннән бик күпкә олы иргә чыккан? Ата йортына кайтып, ятим бала белән ике артык кашык булганчы, тамагыбыз да тук, өстебез дә бөтен, балама терәк булыр, дип уйлагандыр, бәлки.

«*Мин хәзер дә атта утырып Саснага барганымны, үземне бер киң вә рәхәт галәмдә хис иткәнемне, юлда барганда күз алдымда әллә нинди нурлар уйнаганын онытмаган шикелле булам. Кемнәр каршылады – анысын белмим; ләкин үги әтиемнең мине сөюе, чәй янында кәрәзле балны ак күмәчкә ягып бирүе, минем шунда куанганнарым, биш минутлык төш шикелле генә, әле дә булса хәтеремдә. Минем анам бу муллада бер ел кадәрме, күпмедер торгач, белмим, нинди авырудандыр, вафат булган. Әнкәм-*



нең җеназасын күтәреп алып киткәннәрен сизгәч, яланаяк, яланбаш хәлемдә, капка астыннан үкереп җылый-җылый йөгереп чыгып: «Әнкәйне кайтарыгыз, әнкәйне бирегез!» – дип, шактый гына барганымны хәтерлим. Бөтенләй ятим булып, бу Сасна мулласы өенә дә сыймаганга, ул мине Өчиле карьясендәге анамның атасы булган бабайга кайтарып биргән» (Г.Тукай, «Исемдә калганнар»).

ӨЧИЛЕ

Адрес: Татарстанның Бирәзә елгасы буенда, Арча шәһәреннән 13 км төньяктарак урнашкан

Өчиле – Тукайның Зиннәтулла бабасы нигезе. Биредә шагыйрь 4 тапкыр була. Беренче тапкыр нәни Габдулла Өчилегә этисе үлгәннән соң, әнисе белән кайтып тора. Аннан ары, әнисе үлгәннән соң, Саснадан китерелә. Бу нигездән Казан ярминкәсенә асрамага озатып җибәрелә. Кырлайга асрамага җибәрелер алдыннан да Габдулла Зиннәтулла бабасында яшәп ала. *«Үги әбинең алты күгәрченнәре эчендә мин бер чәүкә булганга, мине җыласам – юатучы, иркәләним дисәм – сөюче, ашыйсым-эчәсем килсә – кызганучы бер дә булмаган, мине эткәннәр дә төрткәннәр. Бу семья эчендә фәкыйрьлек шул дәрәҗәгә җиткән булырга кирәк ки, мин хәзер дә булса бабайның күрше баерак авыллардан икмәк сыныклары теләнеп алып кайтканын исемдә тотамын»* (Г. Тукай, «Исемдә калганнар»).

Зиннәттулла бабасы турында бәхәсләр күп. Әмма Тукай аны истәлекләрендә үзе аклап яза. Ачлык хөкем сөргән, баланы сыендырыр җылы, наз булмаган йорттан ул аны, бәлки, яхшырак тормышка диеп озаткандыр? Монысын без инде фаразлый гына алабыз.

КАЗАН

Адрес: Казан, Печән базары, Яңа бистә

Тукайның Казан белән бәйле истәлекле урыннары – аерым сәхифә. Бу урында бары бала вакытта ук бирегә килеп эләгеп, шул чордагы Казанның һәм бистә кешеләренең тормыш-көнкүрешен истәлек язмаларына кертерлек итеп теркәп калдыруын гына искә алабыз. Чынлап та, язмыш баланы, әйтерсең, үз дәвере елъязмачысы итәр өчен сайлап әзерләгән: *«Ямщик Казанга килеп җиткәч, Печән базарында: «Асрауга бала бирәм, кем ала?!» – дип кычкырып йөргәндә, халык арасыннан бер кеше чыгып, мине сроксыз бер асрау итеп ямщиктән алган. Миңа әти булганы Мөхәммәтвәли исемле булып, әни булганы Газизә исемле иде. Торулары Яңа бистәдә. Әти талчукта сату итә идеме, әллә тирече идеме шунда – анысын яхшы белмим. Әни, бер дә армый-талмый, байларга кәләпүш эшләп чыгара иде. Аның белән байларның өенә барганда, мин йорт эченең матурлыгыны, идәннән түшәмгә кадәр торган зур көзгеләрен, чиркәү кеби суга торган сәгатьләрен вә сандык кадәр зур органнарын күреп, боларны оҗмахта торалар кеби уйлый идем»* (Г.Тукай, «Исемдә калганнар»).

Казанда Тукай урыннары буенча да, Яңа бистә буенча да төрле экскурсия маршрутлары бар. Казандагы Тукай музее да сәяхәтләр тәкъдим итә.

КЫРЛАЙ

Адрес: Яңа Кырлай, Үзәк урам, 4 йорт; Тукай урамы, 30 йорт

Яңа Кырлайда Габдулла Тукай 1892-1895 елларда яши. Бу аның балалыктан чыгып, үсмерлеккә кереп килгән, иң ваемлы, формалашып җиткән еллары. Күрәсең, шуңа да Кырлай аның шәхесенә дә, иҗатына да гаять зур йогынты ясагандыр. Инде әдип булып җитлеккәч тә, ул монда кайтып, җанына ял таба. Кырлай аның өчен илһам чыганагына әверелә, таяныч ноктасы ролен үти.

«Сәгъди абзый юлда: «Менә хәзер Кырлайга кайтып җитәбез, әниең каршы чыгып көтеп тора торгандыр. Бездә катык, сөт, ипи күп, теләгәнчә ашарсың», – дип, бәхетләр илә мине җуатып бара иде. Сәгъди абзыйның йорты, басу капкасыннан кергәч, күп ерак түгел икән. Коймасы читәннән булган тәбәнәк кенә, салам түбәле өйгә туктадык. Әни капканы ачты; ачык йөз илә каршы алып, арбадан күтәреп төшереп, өйгә алып керде. Баздан катык алып менеп, миңа зур гына икмәк телеменең яртысын тоттырды. Казаннан кайтканнан бирле җүнләп аш йөзен күрмәгәнгә, икмәк белән катыкны ялт иттердем» (Г.Тукай, «Исемдә калганнар»).

Кырлайдагы музей комплексында **Сәгъди абзый йортына** кереп карарга, шул чор атмосферасына чумарга мөмкин. Монда барысы да нәни Апуш яшәгән вакыттагы рухны саклый.



Нәкъ Кырлай туфрагыннан Габдулла иҗади портфеленә мифлар белән риваятьләр генә түгел, ә халык җырларын да төяп алып чыга. Әлеге җырларны ул салкын «Болгар», «Амур» номерларында җырлап та, ресторанга төшеп, уен коралларында уйнатып, тыңлап та җыйна. Классификация ясап, «Җыр дәфтәрләре» бастыра, ягъни аларны яңадан эшкәртеп, анализлап, милләтенә кайтарып бирә.

Ике катлы **музей бинасы – Бакый Урманче архитектурасы үрнәге**. Экспозиция шагыйрьнең тормыш этаплары буенча сәяхәткә чакыра. Музей коллекциясе белән фондларында Тукайның фотографияләре, басмалары, публикацияләре, шәхси әйберләре бар. Шулай ук аның чордашлары белән бәйле экспонатлар да тупланган: Фатих Әмирхан, Галиәсгар Камал, Сәгыйть Сүнчәләй, Камил Мотыйгый, Зәйтүнә Мәүледова.

Тагын бер уникаль корылма 1893 елгы – бу халык архитектурасы үрнәге **Әхмәтхан бай йорты**. Авылда аны «Богач» дип йөрткәннәр, 30 нчы елларда кулак дип кулга алганнар, сөргәннәр. 2011 елда музейга тапшырылган йортта XIX гасыр азагы – XX гасыр башы көнкүреше торгызылган. Аутентик эчке мохиттән соң, мәгърур наратлар ябалдашын җилләтеп утырган урманга чыгып, елгадагы челәннәрне, кондызлар төзегән бөяне күреп хозурлана алабыз. Ерак түгел генә – Кыш бабай белән Кар кызы резиденциясе, анда да кунакларны Тукай һәм милли фольклор каһарманнары каршылый.



ДАҺИНЫҢ АЛТЫН КӨЗЕ

Әскәр Сабиров

Останың тәмамланмаган картинасы. Без аны Урманченың Казандагы музеенда күреп алдык. Ул бу картинасын вафатына бик аз вакыт калганда язган: чиксез елга диңгезе фонында – хатыны, дусты, мәхәббәте Флора... Аның ике музасы – яраткан хатыны һәм елга бер картинада сурәтләнгән. Әйтерсең лә даһи үзе: «Мольберт каршында басып торган урыным – минем көч туплау урыным. Шуннан башлагыз», – дип пышылдый безгә...



Очсыз-кырыйсыз елга диңгезе – Кама Тамагы. Хатирәләр буенча, Урманче анда барырга яраткан. Безнең бурыч исә – нәкъ менә рәссам сурәтләп калдырган урынны табу. Бистә урамнары буйлап шактый йөргәннән соң (чөнки монда картинадагыга охшаш манзаралар һәр тыкрык саен диярлек очрый), елганың кечерәк кенә бер борынына килеп чыгабыз. Биредә яшел болын сиздермичә генә иксез-чиксез зәңгәр төскә күчә, офык янында исә елга гүя күк йөзе белән кушыла... Бакыйның бу күренешләрне беренче тапкыр күргән урыны, мөгаен, шулдыр: ул моны могҗизага тиңләгәндер! Һәм шунда ук кулына кылкаләмен алгандыр.

ЧУЛМАН ҺӘМ ИДЕЛ КУШЫЛГАН НОКТА...

Бакый ага үзенең Айгөлен (Флорасын ул шулай атарга яраткан) сурәтләгән пейзаж – менә ул, нәкъ безнең каршыда, Чулманның Иделгә кушылган җирендә. Уңдарак – Лобач тавы. Ул Урманченың элегрәк язылган «Иделдә (Чулмантамак, Лобач)» картинасында сурәтләнгән. Карагыз әле, Урманче картинасындагы Лобач белән безнең фотодагы Лобач бер үк урыннан мәңгеләштерелгәнгә охшаган. Ә «Кама Тамагы» картинасы? Ихтимал, рәссам аны да нәкъ менә биредә мольберт каршында басып торганда язарга уйлагандыр...

Автор фотолары



Гаҗәп, хәзер без басып торган яшел борын – аны «Урманче борыны» дип атыйсым килә – табигате рәссам яшәгән чактагы кебек үк сакланып калган бердәнбер урын кебек. Яр буендагы гап-гади эскәмияне генә алыштырганнар – аның урынына заманчарагын ясап куйганнар...

Даһи кылкаләм остасының бирегә иртә таңнан килүен, кояш чыгу белән хозурлануын күз алдына китерергә була. Каршыда җәйрәп яткан манзарадан тын кысыла, хис-тойгыларын тыеп тора алмыйча, рәссам кайчандыр әнисеннән откан борынгы татар җырын сузып җибәрә. Җыр моңлы һәм елганың үзе кебек озын була... Аннары мольбертка тотына. Бик сәер, әмма сагыш шунда ук юкка чыга: булачак картиналарның этюдлары, аннары картиналарның үзләре дә (хәтта останың яше җитмештән узгач та) якты һәм сөенечлегә әверелә...

«Һәр иртә, һәр көн кояш чыгу – могҗиза ул. Һәм яз килүе дә шулай ук һәрвакыт могҗиза. Мин бу таң атулар һәм яз килү белән инде сиксән ел буе хозурланам, һәрвакыт аларны беренче тапкыр күргәндәй сөенәм һәм әлеге гүзәллекнең төрлелегенә, муллыгына һәм бетмәс-төкәнмәс булуына гаҗәпләнәм...», – дип аңлатып бирәчәк бу сәерлекне Урманче үзе.

ИҢ ГАЗИЗ ЙОРТ. ҮСМЕР ЧАК

«Кече Салтык авылына җыенабыз. Бу йортның бусагасыннан атлап кергәч, елаячакмын, күземнән яшь агачак. Хәзер үк елый башладым инде...», – дип язып куячак Бакый Урманче 1960 нчы еллар азагындагы август көннәренең берсендә үзенең көндәлегенә.

Соловкидагы лагерь баракларында сабырлыкка өйрәнгән рәссамның күңелен нечкәртерлек нинди Кече Салтык соң ул? Аның балачагы үткән авыл. Әти-әнисе белән яшәгән газиз йорты. Узган гасырның 80 нче елларында Идрис мулланың алты почмаклы нык йорты әле җимерелмәгән була – Урманче аның янәшәсендә истәлеккә фотога төшә... Бәлки, безгә дә бәхет елмаер, йорт әле дә үз урынында торадыр?

Очсыз-кырыйсыз кырлар, урман утраучыклары һәм менә ул – Кече Салтык авылы! Эскәмиядәге сөйкемле әбиләр ярдәм сораганны гына көтәләр бугай!

– Урманче йортымы? Беләбез, билгеле! – арада иң өлкәне, Сания апа, барысы өчен дә җавап бирә. – Мәчеттән ерак түгел, анда медпункт та бар иде шикелле.

Карагыз әле, Урманче картинасындагы Лобач белән безнең фотодагы Лобач бер үк урыннан мәңгеләштерелгәнгә охшаган.

Хатирә апа безгә Урманче йортын табарга булыша.



Ал ягында биш тәрәзә, уелган йөзлекләр. Барысы да фотографиядәге кебек. Хата булуы мөмкин түгел – шул бу, Урманче йорты!

80 нче елларда биш яклы, нык сакланган Идрис мулла нигезе әле торган. Урманче, аның янында басып, истәлеккә фотога да төшкән.

– Менә бу йорт ул, – дип күрсәтә безгә инде Хатирә апа. – Тик анда медпункт түгел, клуб иде....

Фотосурәт буенча чагыштырабыз – бер дә охшамаган бит...

– Бәлки, ул да түгелдер, – ди Хатирә апа, – күпме гомер узган бит инде... Безнең яшелчә бакчасы Идрис Урманче йортына тоташкан диләр иде...

Бакчага бөтенләй башка йорт тоташкан. Ал ягында биш тәрәзә, уелган йөзлекләр. Барысы да фотографиядәге кебек. Хата булуы мөмкин түгел – шул!

«Безнең рәсем сәнгатендәге Тукаебыз». Мирсәй Әмир Бакый Урманченың татар мәдәниятендәге урынына шундый кыска һәм төгәл бәя биргән. Һәм менә без Урманче үскән йорт янында, изге урында басып торабыз! Монда, шушы йортта, киләчәктә зур рәссам булачак бер малай үскән. Ничек яшәгән? Муллыкта үскәнме икән, ни дисәң дә, мулла малае бит? Экскурсия үткәрүче булмагач, ярдәм сорап Урманченың үзенә мөрәҗәгать итәбез.

«ИХ, БӘГЫРЕМ ИДРИС МУЛЛА...»

«1910 елда эти мине Казанга мәдрәсәгә укырга җибәрергә җыенды. Өйдә акча юк инде. Йөккә арыш төяп, Каратунга (Красновидово) киттек – анда гадәттә ашлык җыючы баржалар тора иде. Шуларның берсенә арбага утырган килеш туп-туры барып кердек тә, бөтен ашлыкны тапшырдык та. Әтиемә шунда ук акча түләделәр, һәм ул миңа бишәр сумлык алты акча бирде – ике-өч ай мәдрәсәдә яшәү өчен шул җитәргә тиеш иде. Аннары без кайсыдыр байның чәйханәсендә чәй эчтек бугай. Һәм карбыз сатып алдык – өйгә алып кайтырга... Их, бәгырем Идрис мулла...»

Көндәлектәге әлеге «Их, бәгырем...» сүзләренә улының әтисенә мәхәббәте дә, аны сагыну хисе дә, ачы гаделсезлек өчен дистә еллар буена үтмәгән сыкрау-әрнү дә сыйган. Биш бала атасы, хирыссыз кеше, мәгърифәтче Идрис мулланы 1930 елда кулакка чыгарып репрессиялиләр, ә Бакый Урманче хәтта үзе өчен дә бу гаепләүнең ахмаклыгын, мәгънәсезлеген гомере буе исбатларга тырышып яши.

Рәссамның көндәлегендә инкыйлабка кадәр чыккан «Ислам дөньясы» журналыннан 1913 елгы өземтәгә тукталабыз: «Казан губернасы. «Бәянелхак» газетасының 1189 нчы санында редакциягә килгән хат бастырылган: «Казан губернасының Тәтеш өязе Салтык авылы имамы мулла Идрис Урманчиев балаларыбызны яңа ысул буенча укыта. Быел имам, үз тырышлыгы белән акча җыеп, авылда 500 сумга төшкән мәктәп төзетте. Анда ул балаларыбызны яхшы программа буенча тырышып укыта. Кызларыбызны аның хөрмәтле хатыны һәм кызы шулай ук яңа метод буенча укыта. Мулла Идрис Урманчиев имам булганнан бирле безнең авыл гөрләп үсә. Шуңа күрә хөрмәтле имамга рәхмәт

белдерәбез һәм уңышлар телибез. Мәхәллә кешесе М. Биккенин».

Кызык, туган авылында үз акчасына мәктәп салдырган мулла гаиләсен 1930 елда газиз йортыннан урамга куып чыгаручылар арасында мәхәллә кешесе Биккенин яки аның варислары да булдымы икән?

БУЛГАННЫҢ КАДЕРЕН БЕЛМИБЕЗ

Шулай да Кече Салтык Бакый Урманче өчен чын-чынлап бәхетле урын булып кала. Урта Азиядә дә язып барган көндәлекләрендә (рәссамга, «ышанычсыз элемент» буларак, илнең 39 зур шәһәрендә яшәү тыела), туган илен сагынганда, Урманче Казанны яки Мәскәүне түгел, хәтта гомеренең беренче ун елын үткәргән Буадагы Күл Черкенен дә түгел, бәлки яраткан Салтык авылын искә ала. Ватанына кайткач язачак иң матур картиналарының берсен – «Салтыкта печән өсте»н дә шул вакытта ук ниятләп куя.

Аның үсмер чагындагы Салтыкта язын алмагачлар ак чәчәккә күмелгән. Кичләрен биредә тальян гармунга кушылып гаҗәеп моңлы татар халык көйләре агылган. Урманче исенә төшергәнчә, Карамалы елгасы буенда алар малайлар белән кысла тотар өчен тал чыбыгыннан мурда үргән. Казандагы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укыганда ул монда җәйге ялга кайткан. Иртә таңнан яшьтәшләре белән чыклы үлән өстеннән дүрт чакрымдагы Иделгә балык тотарга йөгергән. Ә әнисе нинди тәмле коймак белән сыйлаган аны!

Монда ул һәрвакыт рәхәтләнеп ял иткән. Җәй көне, бераз акча эшләр өчен, Тенеш пристанендә баржа бушатканда да, эсседә җиде тиргә батып печән чапканда да җаны тыныч булган аның. Әтисе ял вакытында да балаларының сабакларын кабатлаткан. Яраткан әтисе...

Идрис мулла йортында яшәгәннәрнең барысыннан да озаграк гомер кичергән, медпункт һәм авыл китапханәсе дә булырга өлгергән йорт – шул заманның телсез шаһиты. Бүген ул буш һәм онытылган. Ишекләре шар ачык, эчтә бер өем «Мирас» журналы һәм иске китаплар гына аунап ята...



Бакый Урманче. «Салтыкта печән өсте», 1979 ел.

Кече Салтык. Урманче яшәгән урам.



Кече Салтык авылы мәчете.

Бу – Бакый Урманче үскән йорт, безнең мирас. Булганның кадерен белергә кайчан өйрәнербез икән инде?!

Урманчега багышланган зур булмаган экспозициядә – аның портреты, палитрасы, берничә картинасы.

КҮЛ ЧЕРКЕНЕ. БАЛА ЧАК

Сырлап бизәк уелган, төрле җете төсләргә буялган тәрәзә йөзлекләре (аларны бүген тагын кайда күрерсең әле?), чәчәккә чумган түрбакчалар, татар авылларында гына очрый торган иркен яшел тугайлар, ике мәчетнең күккә ашкан манаралары... Без Күл Черкенендә – указлы Идрис мулла гаиләсендә Габделбакый исемле сабый 1897 елда нәкъ менә биредә дөньяга килгән бит.

Мөгаен, даһи рәссам һәм скульпторның кешеләр булдыра алганча матур яшәргә тырышкан бу авылда дөньяга килүе очраклы түгелдер. Фронтоннарына бизәкләр уелган, искереп каралган, ләкин безнең көннәргә кадәр сакланган бу йортлар ун яшьлек Бакыйның яшел болын буйлап яланаяк чабып йөргәнен хәтерлидер әле. Ә менә Бакый үз гомерендә беренче «картиналарын» – атасы яздырып алган газетаны бизәгән начар иллюстрацияләрне күргән указлы мулла йортын вакыт җилләре аямаган.

Аңардан калган бердәнбер әйбер – җирле мәктәп диварындагы мемориаль такта, ул әлеге бинаның нәкъ менә Бакый Урманче туган йорт урынында төзелгәнлеген хәбәр итә. Авылда исә үзләренең бөек якташларын яхшы хәтерлиләр. Тәрәзә йөзлекләре уеп бизәлгән яңа йортта 2012 елда хәтта Бакый Урманче музеен да ачканнар.

Музей һәрвакыт ачык, аны карарга теләсәгез, аяк киемен салып керергә кирәк. Бу бик чиста авыл йортының идәненә өйдә сугылган келәмнәр җәелгән. Тыйнак экспозиция үзендә сөенеч белән фаҗигане бергә туплаган. Куанычлылары: Урманченың туу турында метрикасы, Тукай премиясе лауреаты медале. Хәсрәтлеләре: Соловки лагере тоткыны гимнастеркасы, рәссамның үлгәннән соң алынган битлеге. Һәм аның безнең барыбызга да калдырган мирасы: картиналары, рәсемнәре…

Җирле музейның караучысы Миләүшә Насыйрова остаың тормышы һәм иҗаты буенча үзенең зур белгеч булмавын яшерми. Әмма аның уңган хуҗабикә булуы күренеп тора. Музейны матурайту өчен, кулдан сугылган келәмнәрнең бер өлешен монда үз йортыннан алып килгән.

Буада, Күл Черкененнән ун чакрым ераклыкта, туган якны өйрәнү музеена керәбез. Запасникларда рәссамның имән өстәле дә саклана икән. Хәзер исә Урманчега багышланган экспозициягә аның портреты, палитрасы һәм берничә картинасы (алар арасында икесе – чын) куелган...

Хәер, тиздән күп нәрсә үзгәрер дигән өмет бар. Буада менә-менә картиналар галереясын файдаланугa тапшырачаклар, анда даһи рәссамның төрле музей һәм коллекцияләрдәге картина һәм скульптураларын бер түбә астында тупларга ниятлиләр. Бәлки, монда тулы музей экспозициясе дә барлыкка килер әле...

Казанга кайтабыз, анда рәссамның иҗаты белән бәйле истәлекле урыннар бик күп.



ТУКАЙ, МӘРҖАНИ ҺӘМ ИКЕНЧЕ ЯШЬЛЕК

Шиһабетдин Мәрҗани, мәшһүр мәгърифәтче, татар Геродоты... Данлыклы галимнең ак мәрмәр сыны бүген Кабан яр буен бизи. Даһи рәссамның осталыгына тагын бер тапкыр соклану өчен аның янында тукталыйк.

Әлеге һәйкәл бирегә Бакый Урманченың вафатыннан соң дистәләрчә ел узгач урнаштырылган, бу аның үз вакытында бәяләнмәгән иҗаты нәтиҗәсе. Әлеге искиткеч мәрмәр сын – гипстан ясалган Мәрҗанинең зурайтылган күчермәсе, ул озак еллар буе рәссамның остаханәсендә сакланган.

«Мин Казанга кайткач, КПСС өлкә комитетының икенче секретаре чакыртты, – дип искә ала Урманче, – планнарым белән кызыксынды... Мин хәзер мәрмәрдән Тукай сынын ясавымны, аннары Мәрҗани белән Дәрдемәндкә тотынырга ниятләвемне әйттем. «Без аларны яратмыйбыз бит», – диде. «Мин» түгел, «без», диде. Күрәсең, шул рәвешле моның партия позициясе икәнен аңлатырга теләгәндер...»

«Минем иҗатым сезне бернәрсәгә дә мәҗбүр итми бит, скульптуралар минем остаханәдә калачак, акча сорамаячаклар», – дип җавап бирә рәссам.

Берничә ел узгач, Мәрҗани белән Дәрдемәнд турында партиянең фикере үзгәрә. Һәм шул ук түрә, Урманчены очраткач: «Син ул чакта хаклы булгансың, тик кайбер галимнәребез безнең башны катырды шул», – ди. Дөрес, аның бу фикере сыннарның язмышын берничек тә үзгәртми: алар Урманче остаханәсендә кала бирә...

Рәссам үзенең күп эшенә ихтыяҗ булмавына борчылганмы соң? Менә аның көндәлегеннән тагын бер язма, 1969 елның мае бу: «Кичә күргәзмә җыелды. Бүген нәгыйшь һәм графиканың күбесен китерделәр. Эшләрне янә иске урыннарына куйдым. Бер яктан, күргәзмә хафасы бетеп, бераз тынычлыкка сәбәп булса да, эшләрнең янә «тоткынлыкта» калулары күңелгә ниндидер мәәюслек, моңсулык китерде. Алар музей экспозициясендә яшиләр, сулыйлар, иркен гомер сөрәләр кебек иде. Хәзер җансыз, хәлсез, авыр сырхауга дучар булган кебек, киштәләрдә ятачаклар. Кайберләрен дусларга бүләк итәргә кирәк. Берәр өйдә эленеп торсалар, яхшырак булыр».

Кабан күле буенда Мәрҗанигә куелган һәйкәл.

Казан картасыннан рәссам остаханәләрен табабыз. Беренчесе 1926 елда, Урманче Мәскәүдә укып кайткач, идеялар һәм планнар белән янып яшәгән чорында пәйда була. Бу – сәнгать училищесы бинасындагы остаханә, анда кайчандыр Николай Фешин үзе иҗат иткән (ул вакытта инде рәссам Россиядән киткән була). Урманче моны белә, ул мэтр белән 1919 елда, Казан училищесына укырга кергәндә таныша. «Без, студентлар, профессорлар белән, бер өстәлгә утырып, уку программаларын төзедек – шундый вакыт иде», – дип искә ала Урманче.

1926 елда югары иҗат рухы белән сугарылган Фешин остаханәсе, мөгаен, яшь рәссамны канатландыргандыр. Биредә ул үзенең беренче җете картиналарын – «Татар кызы», «Бикбулатов портреты», «Иделдә», «Кичү янында» әсәрләрен иҗат итә... Ә аннары 1929 елның августы килеп җитә: нахак гаеп тагылган Урманчены шул остаханәсеннән туп-туры Черек күл төрмәсенә алып китәләр. Аннары – Соловкига...

Тагын бер адрес. Королёв – Мөхәммәдьяров урамнары чатында тыйнак кына өч катлы йорт. Монда Бакый Урманче алтын көзнең бәхетен татый. Казанга әйләнеп кайтканда, аңа инде алтмыш яштән артык була, күпләр бу вакытта язудан туктый. Рәссам исә яшьлеккә кайткандай кебек була. Язмыш аңа тагын утыз елга якын гомер бүләк итәчәк, шул вакыт эчендә ул үзенең күп кенә бөек әсәрләрен тудырачак. «Сагыш» һәм «Сөембикә» скульптуралары, Габдулла Тукай һәм Мария Ульянова һәйкәлләре, «Шүрәле»гә иллюстрацияләр, күренекле татарстанлыларның бюстлары, дистәләгән киндер... Болар барысы да Королёв урамындагы остаханәнең тар диварлары арасында ясалачак....

Мөгаен, бу елларда ул яңадан чын-чынлап бәхетле булгандыр. Иртәнге сәгать дүрттә тора да, иске алъяпкычын ябып, шунда ук эшкә тотына. Бөтен дөньясын онытып, төнгә кадәр иҗат итә. Яраткан татар халык җырларын суза. Ял минутларында кулына скрипкасын ала. Тагын бер мавыгуы – үзенең сынлы сәнгатькә җәүһәрләренә тиң шигырьләр язу. Зирәк һәм үзәк өзгеч алар. Шул рәвешле бервакыт бу даһи юллар да пәйда булачак: «Төшемдә кабат көзне күргәч, языма әйләнеп кайттым мин...»

Королёв – Мөхәммәдьяров урамнары чатындагы тыйнак кына өч катлы йорт. Бакый Урманче соңгы көннәрен шунда үткәргән.



Бакый Урманче. Бронза сын.

ЯШӘГӘН, ДИ, БЕР РӘССАМ…

Евгения Чеснокова

«Әгәр мин Казандагы Арча зиратында җирләнәчәгемне белсәм, үлмәс идем»... Рәссамның кызы Ия Фешинага әтисенең васыятен үтәргә ярдәм итү максатыннан 1970 нче елларда Казанга килгән Америка сәнгать дилеры Форрест Фенн истәлекләрендә шулай язып калдырган. Казанда туып-үскән атаклы рәссам Николай Фешинның рус рухы, рус күңеле серләрен мистер Фенн берничек тә аңлый алмаган шул...

КАЗАН МОНМАРТРЫ

Федосеевская һәм Япиев урамнары чатындагы зур яңа йортлар уртасында Спас-Евдокия чиркәве яшеренгән. Ул төзелүгә тиздән өч йөз ел була инде, һәм аның Казан шәһәр төзелешенең гаҗәеп яңа дөньясында җимерелмичә исән калуын ниндидер бер могҗизага тиңләргә мөмкин. Бу чиркәүдә 1881 елда яңа туган Николай Фешинны чукындырганнар.

Эчкә кергәч, чиркәү диварларында сурәтләр булмавына игътибар итәсең, күп тәреләр агачтан уеп ясалган рамга куелган. Бу урында Фешинның әтисе Иван Александровичның, агачтан иконостаслар ясап, аларга алтын йөгертү остаханәсе хуҗасы булуын искә төшерергә кирәктер.

Шунысы кызык: хәзер Федосеевская һәм аның тирәсендәге район – Казандагы иң кыйммәтле торак һәм иң пафослы биналар тупланган урын. Ә моннан йөз ел элек, Казансу бу тирәне әледән-әле су астында калдырганга, биредә тоташ агач йортлар булган. Һәм аларда шул исәптән ярлы рәссамнар да күп яшәгән.

– Шуңа күрә бу райондагы урамнарның берсен Фешинның укучысы Константин Чеботарев үзенең көндәлекләрендә Казан Монмарт-

Фото: Александр Ефремов, Евгения Чеснокова

Спас-Евдокия чиркәве (1734 елда төзелгән). Биредә кайчандыр Николай Фешинны чукындырганнар.

ры дип атаган да инде, – дип сөйли «Крот казанский» туган якны өйрәнү медиапроекты тикшеренүчесе Михаил Остудин.

«Крот казанский» медиапроекты ТР Милли музее һәм Потанин фонды белән берлектә хәзер аудиогидлы Фешин маршруты экскурсиясен әзерли, шунлыктан рәссам һәм аның даирәсе турында бик күп кызыклы фактлар белә.

Менә шулай итеп, үзебезнең Монмартр буйлап барабыз. Евдокия чиркәвеннән Кремль ягына таба берничә йөз метр узабыз һәм Игенчеләр сараена килеп җитәбез. Казанлыларның күбесе бу зиннәтле бинаны зәвыксызга саный һәм яратмый. Әмма килешәсездер, аның түбәсендәге Париж соборларындагы горгульяләрне хәтерләткән барслар «Монмартр» сүзе янәшәсендә яңа мәгънә ала...



Ия елгасына һәм Аркатау храмына ачылган манзара. Питрәч районы, Надеждино авылы тирәсе.

БОРМАЛЫ ИЯ БУЕНДА

Татарстанның Питрәч районындагы яшеллеккә чумган калкулыклар арасында кеше кулы кагылмаган табигать почмагы... Мин калкулыклар арасындагы бормалы тар гына инешкә карап торам. Ия елгасы бу.

Монда Надеждино авылы урнашкан. Зур түгел – бүген биредә 250 гә якын кеше яши. Моннан йөз ел элек, авыл Казан губернасының Лаеш өязенә кергәндә, халык саны күбрәк була – 400 ләп кеше исәпләнә. Казан сәнгать мәктәбе укучы һәм укытучылары шәһәрдән пленэрга килгән чакларда исә кешеләр тагын да ишәя. Биредә, елганың икенче ярында, мәктәп директоры Николай Бельковичның утары урнашкан була.

Николай Фешин да 1910 нчы еллар башында күп тапкырлар бу утарда кунак була. Биредә, авыл коесы янында, Надеждино йортлары фонында, ул үзенең хәзер «Хәзинә» галереясында саклана торган атаклы «Коену» картинасына этюдлар ясый.

Шушында ук, Ия ярларындагы гүзәл калкулыклар арасында, башкала сәнгать богемасының шәһәр читендәге тормышы кайнаган җирдә, Казан сәнгать мәктәбе укытучысы Фешин белән мәктәп директорының кызы, соңрак Николай Ивановичның хатыны булачак яшь Саша Белькович бер-берсенә гашыйк була. Кайбер туган якны өйрәнүчеләр фаразлавынча, рәссам кызына нәкъ менә Ия елгасының исемен кушкан.

Бельковичның агач утары күптән янып юкка чыккан, шуңа күрә елга аръягында хәзер, кая гына күз салсаң да, җәен – яшел, кышын ап-ак калкулыклы тугай җәйрәп ята. Авылдан чак кына китсәң, Ия аша күпергә килеп чыгасың. Дамба артында тар елга мул сулы агымга әверелә, ә еракта күрше Аркатау авылы чиркәвенең гөмбәзе күренә. Бу урын бүген дә пейзажлар язу өчен менә дигән!

Михаил Остудин фаразлавынча, Александра һәм Николай Фешиннар нәкъ менә Аркатауда никахлашкан булырга тиеш. Эш шунда ки, аларның никахлашуы турында берниндИ документлар да сакланмаган, әмма яшьләр моның

Ия елгасы.

Николай Фешин. «Рус пейзажы», Надеждино авылы».

Рәхмәтуллин урамында киң колачлы төзекләндерү эшләре бара, әмма Петропавловский чиркәвенә ачылган күренешне берни боза алмый.

өчен Аркатаудагы борынгы (1746 елда төзелгән) Смоленск чиркәвен сайлагандыр, дип уйлау мантыйкка ифрат та ярашлы бит.

СӘҮДӘ ЙОРТЫ АРТЫНДА

Казанның кечкенә генә Рәхмәтуллин урамы абруйлы Кремль һәм Профсоюз урамнары арасында яшеренгән. Бу Главпочтамт бинасының арткы ягы. Ә кайчандыр урам Петропавловский тыкрыгы дип аталган (бер башы белән ул Петр һәм Павел соборына барып тоташкан).

Күз алдына китерегез: 1914 елның язы. Рәссам остаханәсендә уенчыклар, җиләк-җимеш һәм савыт-саба арасында өстәлдә берничә сәгать селкенмичә дә утыру өчен, бер кечкенә кыз эти-әнисе белән Покровская (хәзерге Карл Маркcның бер өлеше) урамыннан Петропавловский тыкрыгына таба бара...

Кызның исеме Варя Адоратская, аңа 9 яшь, ул бер ай дәвамында атнага ике-өч тапкыр апасы Надежда Сапожникова остаханәсенә йөри. Тегесе – рәссам, Фешинның укучысы һәм меценаты була, ә Петропавловский тыкрыгында, Сапожников сәүдә йорты (хәзерге Главпочтамт) бинасы артында Надежда Михайловнаның остаханәсендә еш кына иҗади интеллигенция җыела. Фешин да монда даими килеп йөри, һәм нәкъ менә шунда үзенең иң атаклы картиналарының берсен – яшь Варенька портретын ясый. Бу сеансларга ничек йөрүе һәм аякларын сузып өстәлдә сәгатьләр буе утыру үзенә ничек уңайсыз булуы турында портрет героинясы соңрак истәлекләрендә язачак әле.

Варя Адоратская безгә хәзер элеккеге Петропавловский тыкрыгында ачылган «Фешин» отеле холлындагы дивардан карап тора. Юк, әлбәттә, бу картинаның оригиналы түгел, күчермәсе генә. Оригиналы – Казанның «Хәзинә» галереясында. Ә Рәхмәтуллин урамындагы остаханә кайда булган – хәзер әйтүе кыен инде. Аның каравы, кечкенә генә бу урамда Мариинск гимназиясенең борынгы классик

Рәхмәтуллин урамында урнашкан «Фешин» кунакханәсенең холлында кунакларны Варя Адоратская каршылый.



бинасы, шулай ук искиткеч Петр һәм Павел соборы белән хозурланырга була, мөгаен, кайчандыр Сапожникова остаханәсе кунаклары да аңа карап сокланганлыр.

КАЗАННАН НЬЮ-ЙОРККА КАДӘР

Без Горький һәм Гоголь урамнары чатында, Казанның 3 нче гимназиясе каршында басып торабыз. Фасадта ерактан ук истәлек тактасын күрергә була, анда башына цилиндр кигән ир-ат сурәтләнгән. Якыннан караганда, әлеге шәхеснең танылган шагыйрь-футурист һәм рәссам Давид Бурлюк икәне ачыклана, ул XIX гасыр азагы – XX гасыр башында бу бинада укыган. Ул елларда бу йортта Казан сәнгать мәктәбе урнашкан була.

Үндарак фасадта тагын бер истәлек тактасын табарга мөмкин. Ул алай ук күзгә ташланмый, шуңа күрә Николай Фешинның да монда ук, тик бераз элегрәк укыганын бар кеше дә шәйләмәскә мөмкин. Һәм, дөресен генә әйткәндә, элеккеге мәктәп, ә хәзер Казан сәнгать училищесы бүген нәкъ менә Фешин исемен йөртә. Аның төп бинасы хәзер 3 нче гимназиядән ерак түгел, Карл Маркс урамындагы 70 нче йортта, архитектор Карл Мюфке проекты буенча төзелгән чын мәгънәсендә шедевр булган йортта урнашкан.

Ә Бурлюк турында без мемориаль такта уңаеннан гына искә алмадык. Аның белән шундый хәл була: 1923 елда Нью-Йорк метросында эмигрант Бурлюк русча сөйләшүче кечкенә кызга игътибар итә. Җентекләп карагач, ул аның әтисен дә танып ала. Казандагы күптәнге танышлары Фешиннар гаиләсе

Казанның 3 нче гимназиясе бинасына беркетелгән мемориаль такталар биредә Бурлюк белән Фешин укыганын хәтерләтеп тора.



Николай Фешин. Давид Бурлюк портретына эскиз.

1917 елда төзелгән йорт «Васильевский» шифаханәсенең үткәне турында бер истәлек.



«Террасада» картинасы, 1913 ел. Фешинның дусты Павел Беньков аны Васильеводa ясый.



Нью-Йоркта Бурлюклар белән күрешедә генә яши икән. Бу чын мәгънәсендә язмышны хәл итә торган очрашудан соң уртак alma mater истәлеге берләштергән ике иҗатчының озак елларга сузылган дуслыгы башлана.

ВАСИЛЬЕВОДАГЫ ТЫНЫЧ ПОЧМАК

Биек-биек төз наратлар күләгәсендә 1917 елда төзелгән чардаклы кечкенә генә агач йорт яшеренгән...

Бу – Казаннан ерак булмаган Васильево бистәсендә «Паратский отрез» дача җәмгыятеннән калган бердәнбер корылма. Хәзер йорт «Васильевский» шифаханәсенең заманча корпуслары арасында «адашып» калган. Ә йөз ел элек, бу якларда тимер юл салынганнан соң, булачак шифаханә территориясен Казан дачниклары актив үзләштерә башлаган. Йортлар салган, җирле күлдә су коену урыны ясаган, җәйге театр ачкан...

Беренче бөтендөнья сугышы алдыннан, хатыны бик сорагач, Николай Фешин да биредә йорт сатып ала. Соңрак революция һәм Гражданнар сугышының куркыныч елларында аның гаиләсе Васильевода яши.

Рәссам үзе Васильевога нигездә ял көннәрендә кайтып йөри, чөнки акча эшләргә кирәк була. Ул сәнгать училищесында укыта, шул ук вакытта яңа хакимият кушуы буенча Ленин һәм Луначарский портретларын да ясый...

Васильевоның искиткеч табигате, күккә ашкан биек наратлар, саф һава аның өчен, мөгаен, эштән соң иң рәхәт ял булгандыр!

Дөрес, көнкүрешкә бик үк җайлашмаган рәссам, революциягә һәм җимереклеккә игътибар итмичә, хатыныннан каймак таптырган, ә табында каймак булмаган... Һәм шуннан соң Александра Николаевна сыер сатып алырга ниятләгән. Кыш көне, каты суыкларда, җирле крестьяннар ярдәменә таянып, ул аны Иделнең аръягыннан алып кайткан. Соңрак, инде Америкада яшәгәндә, ул бу вакыйганы үзенең «Красавка» хикәясендә тасвирлаган.

Васильево аша уза торган тимер юл рәссам язмышында зур роль уйный. Нәкъ менә шул юлдан 1920 нче еллар башында Казанга Америкадан Идел буенда ачлыктан интегүчеләргә ярдәм комитеты вәкилләре килә. Әйтергә кирәк, рәссам Фешин турында ул вакытта Америкада да белгәннәр. Комитет әгъзалары, Николай Иванович белән шәхсән танышып, аннан үзләренең портретларын ясата. Ә Фешин үзе җимереклек хөкем сөргән илдән ерак Америка континентына китәргә карар кыла. Һәм 1923 елда Россияне мәңгегә ташлап китә.

ГОМЕР ТҮГӘРӘГЕ ШУЛАЙ ТӨЙНӘЛӘ

Арча зиратына керәбез, зират администрациясе бинасыннан соң сулга – кайчандыр төп керү урыны булган җиргә борылабыз. Капкадан ерак түгел, уң якта, киң аллея буйлап нибары 40 метр чамасы үткәч, кызыл кирпечтән ясалган һәйкәл бар, аның өске өлешендәге портреттан безгә кулына кылкаләмен тоткан рәссам карап тора...

Якташыбыз Фешин, мәгълүм ки, 1955 елда АКШта вафат була. Һәм үзен туган илендә җирләргә васыять итә. Ул вакытларда моны эшләү җиңел булмый. Бәхеткә, Ия Фешинаның танышлары арасында инде телгә алынган Форрест Фенн да була. Бик кызыклы шәхес – хәрби очучы, Вьетнамда сугыша, аннары сәнгать белән шактый уңышлы шөгыльләнә башлый. Бермәлне аның күз уңына Фешин иҗаты да эләгә. Шул рәвешле ул рәссамның кызы белән таныша.

– 1970 нче елларда Казанга баруы турында Фенн рәссам турындагы китабында яза, – дип сөйли Михаил Остудин. – Анда ул Арча зиратына кабер өчен урын эзләп баруын искә ала: яңгыр ява, тирә-як бик пычрак була...

Казанның бу зираты америкалыга бер дә ошамый. Әмма шуңа да карамастан, ул үз бурычын үти, Фешин кабере өчен урын таба, һәм бер елдан соң, 1976 елда, Ия Николаевна этисенең җәсәден ватанына алып кайта. Аның үзен дә, васыятьнамәсе нигезендә, 2011 елда этисе янында җирлиләр, бу хакта һәйкәлнең аскы өлешендәге табличка-портретта язылган. Фешиннар гаиләсенең Казандагы гомер түгәрәге әнә шулай төйнәлә.

СУКНО БИСТӘСЕНЕҢ ОРФЕЕ

Евгения Чеснокова

Казанның атаклы Сукно бистәсен хәзер танып та булмый: нигездә кызыл кирпечтән салынган тоташ биек йортлар. Кайбер урамнар мәңгегә юкка чыкты.

– Минем Суконкамнан берни дә калмаган диярлек, – дип моңсуланып куя Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты, шушы районда туып-үскән якташыбыз Альберт Әсәдуллин. Шулай да үткәннең ниндидер хәтер бөртекләрен, аеруча Альберт Нуруллович өчен истәлекле урыннарын, Суконкада барыбер таптык.

ЮГАЛГАН НАТУРА

Павлюхин урамындагы 7 нче шәһәр мунчасының кайчандыр кызыл, ә хәзер инде ак кирпеч бинасы алагаем биек яңа төзелешләр арасында бөтенләй диярлек күзгә ташланмый. Хәзер аның тирәсе буш, югыйсә ишектә расписание дә, бәяләр дә язып эленгән. Димәк, мунча барыбер эшли дигән сүз. Ә бит кайчандыр халык мунчага барыр өчен монда чиратка тезелә торган булган... Аптырарлык берни юк, чөнки күпчелек торак йортларда ул вакытта кайнар су түгел, гомумән, суүткәргеч тә булмый.

Менә шундый, уңайлыклары да булмаган агач йортларның берсендә, мунчадан ерак түгел генә, Советлар Союзының һәм Россия

Автор фотолары

Павлюхин урамындагы 7 нче шәһәр мунчасының кайчандыр кызыл, ә хәзер инде ак кирпеч бинасы.

эстрадасының булачак йолдызы үскән гаилә яшәгән.

– Урамның безнең йорт урнашкан өлеше ничектер сәер атала иде – «Задняя Павлюхина» дип йөрттеләр аны, – дип искә ала Альберт Әсәдуллин, елмаеп. – Йорт авыл ызбаларына охшаган иде, тәрәзә капкачлары да бар. Үзебезнең бакча. Тыйнак кына үзе. Ләкин йортны җимергәч, үзәгем өзелеп сагындым. Әле дә хәтеремдә, Ленинградтан (Әсәдуллин анда Казаннан Сәнгать академиясенә укырга китә. – **Ред. иск.**) каникулга кайттым да, гадәт буенча 4 нче трамвайга утырып, йортыбыз урнашкан җиргә бардым. Карасам – йорт урынында бушлык... Шулай да, Суконкада бөтен иске йортларны юк итәргә карар кылуларын, аны үз йөзе булмаган яңа корылмалар белән алыштыруларын бик үк дөрес гамәл түгел, дип саныйм...

– Сукно бистәсе, – дип искә ала Альберт Нуруллович, – төрле катламнардан һәм милләт вәкилләреннән тора иде. Романтик, дустанә мөнәсәбәтләр белән хәтердә калган ул – монда иңгә-иң терәп, күрше хакын хаклап, татарлар да, руслар да, яһүдләр дә яшәде... Шул ук вакытта Суконкада хәтәр дә иде, монда хулиганлык та булмады түгел, булды. Электромонтёрлар иртән баганаларга яңа лампочкаларны борып куя, ә кичкә инде аларны ваталар. Урамнарда караңгылык хөкем сөрә.

Әнә шул дөм караңгы урамнар буйлап булачак музыкант сәнгать мәктәбеннән өенә кайта торган булган (үсмер елларында Альберт, җырлауга караганда, рәсем ясауны күбрәк яраткан. – **Ред.иск.**). Үзен «урам»нан да художка саклап калды, дип исәпли ул. Суконкадагы шпана да аны шуңа ихтирам иткән. «Ә, рәссам килә, уз», – дип, җирле авторитетлар аны тынгысыз урамнарда уздырып җибәргән.

БУФЕРДАГЫ СӘЯХӘТЛӘР

«Сукно бистәсе» метро станциясеннән чыкканда, үзенә күрә ачык һавадагы музейга эләгәсең: әле күптән түгел генә Казан урамнары буйлап йөргән трамвай һәм троллейбус вагоннары хәзер инде шәһәрнең үткәнен искә төшереп торучы экспонатларга әверелгән. Әнә шундый трамвайларның берсендә үсмер Альберт туган Суконкасыннан 1 нче сәнгать мәктәбе урнашкан Ирек мәйданына бара торган булган.

Хәзер 27 нче урта мәктәп гимназия итеп үзгәртелде.

Татар дәүләт филармониясе бинасында кайчандыр Киров исемендәге мәдәният сарае урнашкан була.

Узган гасыр уртасында Сукно бистәсе буйлап менә шундый трамвайлар йөргән.

Дөресрәге, ул ике трамвайда барган, чөнки ул елларда да, хәзерге кебек үк, бу юлны күчеп утырмыйча үтү мөмкин булмый.

Ул вакытта трамвайга өлгерү, эләгү – бәхет эше, алар шыгрым тулы йөриләр. Малайлар гадәттә вагон ишегенең тышкы ягындагы култыксаларга тотынып, аскы баскычта бара. Әсәдуллин да шулай йөри.

– Ә кайчакта, – дип искә төшерә Альберт Нуруллович, – аскы баскычта да урын булмый, андый очракта вагон артындагы буферда барырга туры килә, билгеле...

Бүген Сукно бистәсенең яшь рәссамнарына мондый маҗаралы ерак сәяхәткә чыгарга кирәкми инде – 1 нче балалар сәнгать мәктәбе Петербург урамындагы Курчак театрының яңа бинасына күчте, шунда ук, Суконка урамында гына. Хәер, дәресләрнең бер өлеше элеккечә мәктәпнең искесендә – Зур Кызыл урамында урнашкан ТР Министрлар Кабинетына кыйгачлап урнашкан бинада уза.

ИСТӘЛЕКЛЕ 1961 ЕЛ

Павлюхин һәм Назарбаев урамнары чаты. Монда, аның ике почмагында, бер-берсеннән кыйгачлап, артист өчен әһәмиятле ике бина урнашкан. Шуларның берсе – 27 нче гимназия. Дөрес, Альберт Әсәдуллин биредә 5–8 сыйныфларда укыганда, ул әле гимназия түгел, гади мәктәп кенә була. Аннан фасады Павлюхин урамына карап торган икенче бинага юл аркылы йөгереп барып җитү уңайлы була. Сталин ампиры стилендәге бу классик корылмада бүген Татар дәүләт филармониясе урнашкан. Монда затлы тамашачы йөри. Совет елларында бу – Киров исемендәге мәдәният йорты, анда бик яхшы кинозал эшләгән. Малайлар көтүенең көтеп алынган сеанска билет сатып алу өчен кассага чиратка тезелүен күз алдына китерү авыр түгел...

– Бу яраткан кинотеатрыбыз иде, – дип искә ала Альберт Әсәдуллин. – Дуслар белән гел шунда йөрдек. Бик яхшы хәтерлим, һәр фильм алдыннан һичшиксез киножурнал күрсәтәләр. Экранда зур җир шары пәйда була, ул якынайганнан якыная, аннары «Көн яңалыклары» дигән язу чыга. Бигрәк тә 1961 елдагысы истә калган: титрларда бу сан пәйда булды һәм аннары, мәтәлчек аткандай, йөзтүбән борылды һәм... яңадан 1961 килеп чыкты!

Бу елның бер көне аеруча исендә калган аның.

– Әле дә хәтерлим: өлкән класста укучыларның берсе йөгереп керде дә: «Безнекеләр космоста!» – дип сөрән салды. Шунда нәрсә башланганын күрсәгез! Барыбыз да урамга йөгереп чыктык. Барысы да «Ура!» кычкыра, кочаклаша... Дәресләр өзелде, әлбәттә!

КҮЛ БУЕНДАГЫ МӘКТӘП

Марсель Сәлимҗанов һәм Һади Такташ урамнары киселешендәге Кабан арты мәчетенең кызыллы-аклы кирпеч манарасы Сукно бистәсе кунакларына ерактан ук күренә. Бинаның язмышы гыйбрәтле: мәчет йөз ел элек, 1924–1926 елларда, совет хакимияте вакытында салына, гәрчә илдә ул чакта инде дингә каршы сәясәт ныклап алып барыла торган булса да. Хәер, бик тиздән, 1930 елда, мәчетне ябалар. 1950 нче еллар уртасында биредә, кайчандыр мәчет каршында эшләп торган мәдрәсә бинасында, башлангыч мәктәп эшләп китә. Альберт Әсәдуллин беренче класска укырга нәкъ менә шушында килә, дүрт ел буена укый.

1950 нче еллар уртасында Кабан арты мәчетендә башлангыч мәктәп урнашкан була.

Мөштәри урамында Казан сәнгать училищесы бинасы.

Сүз уңаеннан, җырчының туган көне – 1 сентябрьдә, димәк, беренче мәктәп көне дә аның өчен ел саен аерым бәйрәм булган, дип фаразлый алабыз. Мәктәптән соң, дуслары белән аларның өенә йөгерәләр. Туган көн хөрмәтенә әнисе өстәлгә пироглар чыгара.

– Әни искиткеч хуҗабикә иде! – дип искә ала Альберт Әсәдуллин. – Мин аның пирогларын ашап туялмадым! Иң яратканым – яшел суган һәм йомырка белән пешерелгәне. Хәзер искә алсам да, авызыма сулар килә...

Хәер, кабат мәчеткә әйләнеп кайтыйк. Бинаны әйләнеп узуга, нибары 200 метр арада – Кабан күле.

– Кайчандыр, – дип искә ала Альберт Әсәдуллин, – җылы көннәр җитү белән, без, малайлар, мәктәптән соң Кабанга су коенырга йөгерә идек.

Хәзер монда заманча модага ияреп корылган яр буе, тирә-якта – гранит, суга турыдантуры керү мөмкинлеге юк диярлек. Бары тик үрдәкләр һәм байдаркада йөрүчеләр генә янәшәдән йөзеп узгалый.

ЯШЬ РӘССАМНАР ПРИСТАНЕ

«Фешин исемендәге Казан сәнгать училищесы» – Мөштәри урамындагы 16 нчы йорт ишегендәге язуны укыйбыз. Совет чорында Мюфкеның Карл Маркс урамындагы сәнгать училищесына караган төп бинасы Казан авиация институтына бирелгән була, ә яшь рәссамнар биредә – Мөштәридә (ул вакытта Комлев урамы. – **Ред.иск.**) шөгыльләнә. Алар арасында 8 нче сыйныфтан соң училищега кергән Альберт Әсәдуллин да була.

– Бу искиткеч вакыт иде, – дип искә ала артист. – Без тирә-якта иң яхшы сәнгать кичәләре үткәрә идек. Башка югары уку йортларыннан да студентлар килә, зал шыгрым тулы, алма төшәр урын да юк. «Күләгәләр театры» оештырдык, анда мин дә катнаштым, «Орфей» бит-төркеме чыгыш ясый иде. Нәкъ менә шунда мин беренче тапкыр гитара чиертә һәм җырлый башладым.

Шунысы гаҗәп: инде соңрак, Ленинградта, Әсәдуллинны бөтен СССРга таныткан роль дә беренче совет рок-операсы «Орфей һәм Эвридика»дагы Орфей була.

АЛЬБЕРТ ӘСӘДУЛЛИННЫҢ КЕЧЕ ХАҖЫ

Татарстанның Балтач районы Ор авылында бер чишмә бар. Авыл халкы, өйләргә инде күптән су кертелгән булса да, эчәргә диган суны шуннан ала. Бу чишмәгә ел саен Альберт Әсәдуллин да килә.

– Киләм, битемә бөрким, тешне камаштырырдай салкын суны учыма тутырып эчәм, аннары утырып догалар укыйм, тормыш турында уйланам, якыннарымны искә алам, – дип сөйли җырчы.

Казаннан Ленинград сәнгать академиясенә укырга керергә 1967 елда ук китүенә карамастан, Альберт Әсәдуллин балачак шәһәренә ел саен кайта һәм, һичшиксез, әтиәнисенең туган җиренә дә сәфәр кылмый калмый. Шул ук Балтач районының Чапшар авылында аның әтисе туган, ә Ор – әнисенең туган авылы. Ике авылда да Әсәдуллинның туганнары күп, алар аның кайтуын һәрчак көтеп алалар.

– Бу минем кече хаҗым, – дип елмая Альберт Әсәдуллин. – Монда кайтып йөрер өчен миңа тагын күпме гомер биргәнен Аллаһы Тәгалә үзе белә.

Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты Альберт Әсәдуллин Казанда узган бала чагын һәрвакыт сагынып искә ала.

ТАТАРСТАНДА – ҖӘЙ

Татарстанда җәй – чын мәгънәсендә бәйрәм! Бәйрәмнәр, дөресрәге! Нигездә, милли бәйрәмнәр. Чөнки республикада 175 милләт вәкиле яши. Әгәр сез безнең кунакчыл Татарстаныбызга җәй көне килеп төшәсез икән, бу бәйрәмнәрнең берсенә булса да эләкми калмаячаксыз! Ә инде эләгәсез икән, әзер булыгыз: сезне анда ашатачаклар-эчертәчәкләр, әйлән-бәйләннәрдә катнаштырачаклар, җырлап-биеп күңелегезне күрәчәкләр! Бәйрәм күрсәтә торган «хезмәтләр»нең колориты белән күплеге кабул итә торган якның традицияләренә турыдан-туры бәйле:

– теләсәң – русча

– теләсәң – татарча

– теләсәң – удмуртча

– теләсәң – мордвача

– теләсәң – марича

– теләсәң – чувашча...

Сезнең күңелгә кайсы якынрак – рәхәтләнеп сайлагыз! Безнең үзебезгә – барысы да бердәй һуш! Без бит – күпмилләтле, җирле халык.

Татарстан халыкларының бәйрәмчә дуслыгына сез дә килеп кушылыгыз!

РУСЛАРДА – КАРАВОН

Фото: tatar-inform.ru

Никольское авылы, ТРның Лаеш районы

2025 ел, 24 май

КОЯШ БЕЛӘН БЕРГӘ ӘЙЛӘНИК

Җәйге милли бәйрәмнәр чылбыры рус халык Каравонында башлана, ә аның визит карточкасы – әйләнбәйлән: бер-береңне чәнти бармак белән генә эләктерәсең дә, «каравон» адымы белән түгәрәк әйләнергә кушыласың. Кояш әйләнешенә тәңгәл бу түгәрәк бер киңәеп, бер тараеп тора, кешеләр кушыла-чыга, әмма әкрен генә хәрәкәтләнүен дәвам итә.

Сез дә бу «кояш әйләнеше»нә кушыла аласыз, йә булмаса «Закрутиха» борынгы рус уен аттракционнарында үзегезне сынап карарга мөмкин. Болардан кала, «Каравон»да кунакларны әле тагын «Тимерче алачыгы», «Ярминкә мәйданы», «Яшел алан» көтә... Хәер, «Закрутиха» булсынмы, «Яшел алан»мы, сез барыбер әйләнбәйләнсез калмассыз!

Фото: minnac.ru

МАРИЛАРДА – СЕМЫК

Починок-Кучук (Мултан) авылы, ТРның Кукмара районы

2025 ел, 31 май

АЗАГЫ ЮК «СИГЕЗЛЕ»

«Семык» бәйрәме белән марилар җәйге бәйрәмнәр циклын ачып җибәрә. Бу көнне фани дөньяны калдырып киткән туганнарны искә алып, алардан хуҗалык эшләрендә һәм көнкүреш итүдә фатиха сорыйлар.

Семык җете киемнәре белән кунакларның күзләрен камаштыра, бер эзгә салынган әйлән-бәйләннәре белән дә башны әйләндерә. Программаның төп бизәге – атаклы «мари сигезлесе». «Сигезле»не марилар тын да алмыйча, сәгатьләр буена, берөзлексез башкара ала – озынлыгы километрдан артык аның. Борынгы яулар вакытында алар бу «сигезле» белән дошманны үлгәнче биетә алган, диләр. Әмма монысы инде – бөтенләй башка тарих.

Фото: tatarstan.ru

МОРДВАЛАРДА – ВАЛДА ШИНЯСЬ

Килдеш авылы, ТРның Тәтеш районы

2025 ел, 15 июнь

«АЛ ЯМ»ГА ҖИТМИ!

Мордва мәдәниятенә багышланган «Валда Шинясь» республика бәйрәме мордвачадан «Якты көн» дип тәрҗемә ителә. Ул җәйге кояш яктысының һәм җәй биргән сый-нигъмәтләрнең муллыгын символлаштыра. Шуңа Тәтеш районының Килдеш авылында уза торган бәйрәмдә кояшка табына торган борынгы йола да һәр елны уздырыла.

Кояшка табынырга теләүчеләр таң алдыннан Кирәмәт дип аталган изге урынга бара. Су алып, тау битенә менәләр дә дога укыйлар. Мордва-эрзяларның бу борынгы йоласы, шулай ук этник культура фестивальләре дә «Раскень Озкс» дип атала, ә мордва халыклары баш иеп табынган Югары Алла – Шкай, Кояш Алласы – Ши-Пазу. Аларга табынып, биргән бәрәкәтләре өчен рәхмәт әйтәләр, алга таба да ташламауларын сорыйлар.

Дога укылганнан соң, һәркемне изге су белән бөркиләр, ул авырулардан саклый, дип ышаналар. Шулай ук – мул уңыш китерәчәгенә дә.

Шуннан соң учакта йола ризыгы – «Ал ям» ашы әзерләнә. Том ям белән бутарга кирәкми! Том ям да – менә дигән үзе, әмма «Ал ям»га җитми инде!

Фото: tatar-inform.ru

ТАТАРЛАРДА – САБАН ТУЕ

Казан шәһәре

2025 ел, 21 июнь

БЕРКЕМ БҮЛӘКСЕЗ КАЛМАЯЧАК

Татар халкының иң күңелле бәйрәме – Сабан туе. Сабан бәйрәме кыр эшләре тәмамланып, ниһаять, күңел ачарга вакыт җиткәнлеге турында хәбәр итә. Сабан туенда һәртөрле ярышлар – мулдан, аларда иң мөһиме җиңү түгел, ә, катнашып, үзеңне сынап карау.

Димәк, бу бәйрәмдә катнашырга мөмкин ярышлар менә нindиләр: ат чабышы, батыр калыр өчен көрәш, колгага менү, катыктан акча эзләү, капчык бәреш, йомырка салынган кашыкны авызга кабып йөгерү, җырбиюләр...

Беркем дә бүләксез калмаячак, чөнки Сабан туена бүләк җыю – бик борынгыдан килгән традиция. Бу үзе үк бәйрәмнең бер өлеше – ат җигеп, арбага бүләкләрне төяп, авыл әйләнү йоласын һәркем күтеп ала. Һәр йортта бүләк җыючыларны сыйлап та җибәрәләр әле. Көне буе йөреп, Сабан туе мәйданына җиткәндә, арба бүләкләрдән сыгылып төшә.

Фото: tatar-inform.ru

УДМУРТЛАРДА – ГЫРОН БЫДТОН

**Чепья авылы,
ТРның Балтач районы**

2025 ел, 28 июнь

МЕТЕОҮЗӘК БЕР ЯКТА ТОРСЫН!

Гырон быдтон – бәйрәм генә түгел, ә җәйге кояш торгынлыгын билгели торган әһәмиятле астрономик күренеш тә. Удмуртлар бу көнне изге дип исәпли, чөнки нәкъ менә кояш кешегә көч тә, сихәт тә бирә бит.

Бәйрәмне дөньяның барлык почмакларында да билгеләп узарга була, моның өчен борынгы удмурт традицияләрен үтәү генә сорала. Нинди соң алар? Иң мөһиме – үләннәргә йола иманын уку, шулай итеп, уңышны үзеңә җәлеп итеп була дип ышанган удмуртлар. Иманны суга да, уңыш яхшы булсынга, җиргә дә укырга кирәк. Бу көнне эшләргә ярамый, яңа һөнәрләргә тотыну хупланмый. Йорт төзелешенә тотынырга кушмыйлар, яшәү урынын алыштыру да юньлегә түгел, диләр. Табигать балансын җимерергә һәм уңышны куркытырга киңәш ителми.

Кагыйдәләрне тиешенчә үтәр һәм бәйрәмнең чын тәмен тояр өчен, аны билгеле удмуртларның үзләре белән уздыру яхшырак: алар кайдан нинди үләннәрне җыясын да, аларга ничек итеп укыйсын да белә, йолаларны да җиренә җиткереп башкара. Шуңа өстәп, Гидрометеоүзәкнең үзеннән дә болайрак итеп, бәйрәм кояшының ничек төшүенә карап, җәйнең ни рәвешле узасын, уңыш нинди буласын да әйтеп бирә.

Фото: Ирина Кузьмина, Вера Александрова

ЧУВАШЛАРДА – УЯВ

**Нурлат шәһәре,
ТРның Нурлат районы**

2025 ел, 29 июнь

АКСАКАЛЛАР НИЧЕК ХӘЛ ИТӘ, ШУЛАЙ...

Иң озын халык бәйрәме – ул, билгеле, чувашларның Уявы. Язгы кыр эшләре тәмамлану белән башлана да җәйге уңышлар өлгергәнче, хәтта җыеп алганчы дәвам итә ул. 3, 5, ә кайчак 7 атна да – аксакалларның ничек хәл итүенә карап. Бу нәрсә дигән сүз? Димәк, көн саен иртәдән кичкә кадәр әйлән-бәйлән уйнарга, учаклар ягарга һәм күңел ачарга ярый! Әлеге ял һәм күңел ачу йолалары озакка сузылса да, чувашлар үзләре ялыгуны белми.

Уявның тыюлары да бар: җирдә эшләргә кушылмый, кара киемнән йөрергә киңәш ителми, кер юарга, өйләрне җыештырырга рөхсәт бирелми, ут ягарга һәм... ризык хәстәрләргә ярамый. Борынгырак чорларда кешеләр бу көннәрдә элек хәстәрләп куелган сый-нигъмәтләр белән туенган.

Тыюны бозган кешене җәза көтә. Дөрес, хәзерге заман күзлегеннән караганда, бу күбрәк уен рәвешендә кабул ителә. Җәзасы – бигрәк тә. Әмма ул бар, һәм аның нинди булачагын да шул ук аксакаллар хәл итә.

Фото: Александр Ефремов

СЛАВЯННАРДА – ИВАН КУПАЛА

Яшел Үзән шәһәре, ТРның Яшел Үзән районы

2025 ел, 5 июль

УТ ҺӘМ СУ БӘЙРӘМЕ

Иван Купала – көнчыгыш славяннарның төп җәйге бәйрәме. Июльнең 6 сыннан 7 сенә кергән төндә борынгылар ут, су һәм үләннәр белән бәйле күпсанлы йолалар уздырган.

Бәйрәм ритуалларыннан бәхет китерүне һәм теләкләрне чынга ашыруны көткәннәр. Гашыйклар кулга-кул тотынып учак аша сикергәндә, кулларын аермаса – бергә булалар. Күмәкләп су коену йоласында катнашсаң, сәламәт тә, бәхетле дә буласың. Үләннәр җыеп, мунча өчен себерке дә хәстәрләп куясың икән – барлык сырхаулардан азат ителәсең. Тиешле вакытта суга такыя төшереп агызсаң, насыйп ярың юньле һәм әйбәт туры киләчәк. Ә менә кайсыдыр туташ йә ханым учак аша сикерми икән, ул сихерче дип шикләнгәннәр.

Шулай итеп, туйганчы су коенып, учак аша сикереп (сихерчеләрдән кала, билгеле), инде чәчәк атып утырган абаганы эзләп, урманга юл тотканнар. Ул бит бары шушы төндә – Иван Купалага гына чәчәк ата! Абага чәчәген тапкан кеше суперкөчкә ия була, дип инанганнар: җәнлекләр телен аңлый башлый, зур байлыклар ала, җир һәм су көчләре белән идарә итә, теләсә нинди кыяфәткә кереп, күзгә күренми торганга әйләнеп йөри...

Гасырлар агыла да агыла... Абага чәчәген генә тапкан кеше юк әле. Бәлки, ул нәкъ менә безне көтәдер?

«ГАИЛӘ УЛ – КЕШЕНЕҢ КОДЫ»

Руфия Фазылова

Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе 1937 елда милли музыка сәнгатен үстерү һәм пропагандалау максатыннан оеша. Туксан елга якын дәвердә ул үз кыйбласына тугры кала. Бүген филармония икенче яшьлеген кичерә кебек: тулы заллар, зәвыклы концертлар, милли дә, заманча да бизәлеш...

Ашаган белми, тураган белә: сәхнә артынданиләр бар? Бүгенге югарылыкка ирешү өчен нәрсәләр эшләнгән? Өч йөзгә якын кеше хезмәт куйган коллективны ниләр борчый һәм ниләр шатландыра? Бу хакта филармонияне егерме ике ел җитәкләгән Кадим Назыр улы Нуруллин белән сөйләштек.

– Кадим Назырович, сүзне туган ягыгыз – Буа районы Ташкичү авылы турында сөйләшүдән башлыйк әле. Туган нигезегезгә еш кайтасыз, дип беләм. Анда сезне кемнәр көтеп тора?

– Туган якка бик еш кайтам, бигрәк тә соңгы елларда. Шөкер, төп нигезебездә безне һәрчак елмаеп әниебез көтеп тора. Ул безнең «Ана даны» ордены иясе, әти белән җиде бала тәрбияләп үстерделәр.

Җәннәт – аналарның аяк астында, дигән гыйбарәгә бик ышанам. Атнасына бер генә көнгә кайтып килсәм дә, күңел тынычлана. Алла боерса, сентябрьдә 79 яшь тула, олыгайган саен әнинең кадере арта гына бара. Кызганыч, әни төп нигездә үзе генә яши, барыбыз да шәһәргә чыгып киттек. Әтиебез 2013 елда ук арабыздан китте. Шуның өчен

Фото: Александр Ефремов, Кадим Нуруллинның шәхси архивыннан

кышларын әни безнең яныбызга килеп тора. Айлап та, икешәр атналап та кунак була. Күбебез үз йорты белән яши, һәрберебездә әнигә аерым бүлмә булдырылган, һәрберебез әни дип өзелеп тора.

– Сез ишле гаиләдә үскән егет, ә аның үз кагыйдәләре. Гадәттә, анда барысы да көйләнгән була: өлкәнрәкләр кечерәкләрне тәрбияли. Кием мәсьәләсендә дә исрафчыллык булмый: берсеннән калганны икенчесе кия. Ишле гаиләдә туганлык җепләре дә нык була...

– Тулысынча килешәм. Мин – гаиләдә дүртенче бала. Авылда тагын безнең кебек ишле гаиләләр бөтенләй юк та иде кебек. Тәрбиягә килгәндә, күп балалы гаиләнең бер уңай ягы – абый-апалар кечерәкләрне тәрбияли. Сүз белән генә түгел, кирәк чакта кул белән дә. Һәм мин моны начар дип санамыйм.

Туганлык җепләренә килгәндә, җидебез дә башлы-күзле булдык, гаиләләребезгә тугры калып, матур итеп яшәп ятабыз. Ә иң мөһиме – җиде туган да бер-берсе өчен җан атып тора. Бу яктан әни бәхетле аналарның берсе, дип уйлыйм. Үземә дә шундый картлык теләр идем.

– Кадим Назырович, сез Камал театрының легендар директоры Шамил Зиннуровичның укучысы. Кичә студент булган яшь-яшь егетне шундый тәҗрибәле җитәкче нәрсәгә өйрәтте? Шамил Зиннуровичның шелтәләрен, мактауларын хәтерлисезме?

– Әйе, остазым Шамил Зиннуровичтан күп нәрсәгә өйрәндем. Беренчедән, эчке культурага. Шундый бер фәлсәфә бар: үсәсең, ниндидер дәрәҗәләргә ирешәсең килсә, көчле шәхесләр белән аралашырга, эшләргә кирәк. Кайда үсүе, нинди җирлектә яшәве, аралашу даирәсе – барысы да кешегә йогынты ясый. Шамил Зиннурович булдыклы, зыялы гаиләдә туып-үскән. Менә шуннан барысы да аңлашыла. Мин аңа бик рәхмәтле. Студент эскәмиясеннән җитәкләп диярлек эшкә алып кереп китте. Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать академиясендә дәүләт имтиханын тапшырганда, Шамил Зиннурович комиссия рәисе иде. Диплом алганнан соң ул мине Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт Академия театрына администратор вазыйфасына эшкә алды. Җиде елга якын Шамил Зиннурович кул астында эшләдем. Җаваплылык, эш сөючәнлек – остазымнан иң беренче шуларга өйрәндем. Ул тынгысыз кеше иде: еллар буена ялсыз эшләде. Ялда булса да, барыбер театрга килми калмас иде. Без аны, яратып, «Камал театрының өрәге» дип йөрттек. Шунысын да әйтим: Камал театры бүген дә ул салган эздән бара.

Шамил Зиннурович милли җанлы кеше иде. Һәм үз тирәсендәгеләргә дә шуны сеңдерде. Туксанынчы елларда милли хәрәкәтнең башында торган шәхес ул. Остазым турында бик озак сөйли алам. Тормышымда зур роль уйнаган кеше ул. Шамил Зиннурович мәктәбен узган кешеләрнең берсе дә тормышта югалып калмады. Аның тагын бер сыйфатын әйтми кала алмыйм: ул бик ярдәмчел кеше иде. Теләсә кемнең гозеренә колак салып, хәленнән килгәнчә булышты.

– Егерме ике ел Татар дәүләт филармониясен җитәклисез. Сез килгән чактагы филармония бүгенгесеннән кайсы ягы белән аерыла иде?

– Беренчедән, буш сәхнә эзләп йөрүче өйсез коллективтан үзенең «дәүләте» булган филармониягә әйләнде. Мин килгәндә, администрация артистлардан аерым утыра иде. Шуңа бик аптырадым. Үзе юкның күзе юк, коллектив өчен бу яхшы түгел, дип саныйм. Әнә шушы фикердән чыгып, администрация утырган Гоголь урамындагы бинадан бирегә күчендек. Концерт залы түбәсеннән су үтә иде, бинаны тулысынча төзекләндердек. Аннары филармония концертлар залында ул чагында мәдәният өлкәсенә карамаган башка чаралар да уза иде. Боларны да туктаттык. Программа булдырдык. Филармониянең берьеллык программасы әзер, ягъни бер буш көн юк. Тәртип, дисциплина булса гына, эшләргә мөмкин.

Әлбәттә, биш сутый җирдән уңыш та шуның кадәр генә була, ә утыз сутый җирдән исә – фәлән кадәр. Бүген бездә 600 урын бар. Без шуны максималь рәвештә кулланабыз. Тик безгә бу зал гына җитми, монысы хак. Командабызда профессионаллар гына хезмәт куя, алар 2–3 мең тамашачылык зал белән дә рәхәтләнеп эшли ала. Бүген 28–30 юнәлеш, жанр буенча эшлибез һәм һәркайсының – үз аудиториясе. Бу – безнең филармониянең көче. Шуның өчен дә заллар гел тулы.

– Элек бөтен җырчылар филармониягә беркетелгән, барлык гастрольләр дә анда килештерелә, хәл ителә иде. Хәзер исә күп артистлар үзләренчә яши. Урынлы сорау туа: бүгенге филармония элеккеге көчен саклап кала алдымы?

– Көч дигәндә, нәрсәне күзаллыйбыз бит. Ул элек филармониянең көче яки көчсезлеге булдымы икән? Советлар Союзы таркалганда, филармония, опера театрларының хәлләре матди яктан мактанырлык булмый. Ә менә эстрада үзен үзе ашата. Бүген дә шулай. Ул иң демократик өлкәләрнең берсе булып калды.

Еш кына ишетәм: тегe яки бу артист, фәлән кеше аркылы сөйләшеп, зал тутырып, концерт куйган, диләр. Тик бу бит гел алай

дәвам итә алмый. Әйе, бер-ике тапкыр шулай залны тутырырсың, өченчегә алай мөмкин түгел. Халык үзе кемне сайлап ала бит, эстрада шулай яши.

– Инде җавабыгызга күрә янә сорау туа: халыкка гына иярү дөресме соң? Күп кенә исемле җырчылар, шул ук Римма Ибраһимова, Фердинанд Сәлаховлар нәкъ менә худсовет кирәк, дип саный. Ә сез ничек уйлыйсыз? Һәм филармониягә яңадан бу ысулны кайтарырга мөмкинме?

– Бу сорауга җавапны тирәннәнрәк эзләргә кирәк. Илебезнең системасы нинди? Әгәр ул капиталистик система икән, худсовет дигән монополия турында сүз дә булырга мөмкин түгел. Ә ул – монополия. Әйе, һәр иҗат оешмасының эшчәнлеге берникадәр дәрәҗәдә диктатурага якын. Шул ук театрларга да кагыла бу.

Филармониягә караган коллективлар безнең карамакта, ягъни аларның репертуарлары өчен без җаваплы. Ә урамда йөргән артистларны контрольдә тоту мөмкин түгел. Һәрхәлдә, әлеге вазгыятьтә.

– Бүгенге эстрадага мөнәсәбәтегез?

– Дөресен әйтим, элегрәк эстрадага карата тәнкыйди фикердәрәк идем. Ләкин, яшияши, башкачарак уйлый башладым: нәрсәнедер инкарь итү бигүк дөрес позиция түгел. Тормыш ул күпкырлы, ягъни бер яклы гына караш була алмый. Эстрадага килгәндә, тәнкыйтьлисең икән, яхшыракны тәкъдим ит. Бүгенге көндә гореф-гадәтне, телне саклап калган бердәнбер өлкә, бәлки, нәкъ менә сәхнәдер. Ул элек тә шулай булган. Һәм без аңа таш атсак, ни булыр? Мине икенче нәрсә борчый – тиздән татар эстрадасы да руслашырга мөмкин. Инде бүгеннән үк сәхнәдә артистларның русча сөйләп, татарча җырлауларын күрәбез. Минә монысы – проблема, бу турыда сөйләргә-сөйләшергә кирәк.

– Кадим Назырович, июль аенда зурлап гаилә көнен билгеләп узабыз. Сезнең өчен гаилә ул нәрсә?

– Әле диннәр, дәүләтләр булмаган чорда да гаилә булган. Гаилә ул – кешелек тарафыннан иң беренче оештырылган дәүләт. Ул тормышның мәгънәсе. Кем генә булсаң да, башта гаиләңне күз уңыннан кичерәләр. Гаилә ул – кешенең коды. Әлбәттә, һәр гаилә үзенчә була, чөнки һәркайсының үз законнары. Ләкин адәм баласы өчен ул – иң мөһиме.

– Гаиләдә ир-ат – баш, хатын-кыз – муен. Ләкин муен кайсы якка бора, баш шунда карый. Сезнең гаиләдә ничек?

– Бездә дә шулайрактыр (көлә – авт.). Бер күзәтүем бар: яшь барган саен гаиләдә дилбегә күбрәк хатын-кыз кулына күчә. Әллә нинди көчле җитәкче ир-ат булса да, ул хәләл җефетенең сүзеннән чыкмый. Шуңа күрә тулы бер гаиләнең, ә кайчакта аерым оешманың, хәтта дәүләтнең киләчәге хатын-кызның акыллы булуына бәйле. Зирәк, уңган хатын белән яшәү – зур бәхет ул, шунысы көн кебек ачык. Хатын-кыз мактау аша, яхшы сүз белән ир-атның үзбәясен күтәрергә тиеш, дип саныйм.

– Балалар тәрбиясе турында да фикерегезне беләсе килә. Сез нинди эти? Балаларыгыз татарча сөйләшәме?

– Җәмәгатем белән бер ул, бер кыз үстердек. Шөкер, өч телдә – татарча, русча, инглизчә иркен сөйләшәләр. Тәрбиягә килгәндә, бүген – бала культы, мин моңа шаккатам, аңламыйм да. Бернәрсәне тәгаен беләм: балада акча булсын өчен, ата-анасында акча булмавы кирәк. Ә бүген без балалар өчен иң беренче үзебез чабабыз. Һәм монда хатын-кызның гаебе күбрәк, дип уйлыйм, балаларны артык иркәлиләр.

– Кадим Назырович, күптән түгел туган авылыгызда бик зур бәйрәм үткәргәнсез...

– Әйе, 12 июль көнне туган авылымда бик зурлап Авыл көнен уздырдык. Казаннан күп кенә танылган артистлар да кайтты. Быел Ташкичү авылы оешуга 365 ел, үзенә күрә матур дата. Авылдашлар белән җыелып, шундый күңелле бәйрәм оештырдык. Бу минем түгәрәк датам тирәсенә туры килде. Туган көнне шау-гөр килеп ресторяннарда бәйрәм итәргә дигән теләк булмады. Бу, беренче тапкыр, әнинең бәйрәме, шулай булгач, әлеге көнне аның янында үткәрәсем килде.

редакция кухнясы

Фото: Александр Ефремов, эзтабарларның архивыннан

ТАТАРСТАН ЭЗТАБАРЛАРЫННАН КЫЧЫТКАН АШЫ

Дмитрий Сивков

«Татарстан»ның традициягә кереп киткән редакция кухнясын исеме республикага гына түгел, бөтен Россиягә билгеле эзтабар, «Ватан» республика яшьләр оешмасының эшләр белән идарәчесе, хәрби авиация тарихчысы, «Татарстан канатлары» проекты авторларының берсе – Илья Прокофьев белән оештырдык. Безгә аның хатыны Ирина да булышты. Аларның Югары Осландагы дачасында эзтабарларның кыр рационына кергән гади дә, туклыклы да ризык – арпа ярмасы салынган кычыткан ашы пешердек.

ПЕЧӘН ЧАБУЧЫ, БАЛЫКЧЫ, МОСАФИР ҺӘМ СОЛДАТ РИЗЫГЫ

Рус телендә мондый ризык «кондёр» дип аталган, хәзер инде бу сүзне күпләр аңламый, ул ризыкка бәйле бернинди хисләр дә уятмый. Ә менә безнең бабайларга, юлда чакта яки кырда авыр эш эшләгәндә, бу аш бик туклыклы булган, казанда пешкән арада, тирә-юньдә, төкерекләрен йотып, учак янында көтеп утырганнар. Кеше ерак сәфәргә чыгып киткәч, юлда кондёр (көньяк далаларда «кулеша» дип тә атаганнар) пешермичә калмаган. Шундый туклыклы ризыктан соң, көне буе ач булмыйсың, җитмәсә, кондёр аш буларак та, куерак итсәң, ботка (мәсәлән, тары белән) буларак та әйбәт. Сугышта, алгы сызыкта, мондый ризыкка һәрвакыт шат булганнар. Ә менә бүген без шуны да ачыкладык: хәбәрсез югалганнарны табу, исемнәрен мәңгеләштерү, тиешле хөрмәт күрсәтеп, аларны җир куенына иңдерү белән мәшгуль эзтабарлар да мондый ризыкны яратып ашый икән бит.

– Кычытканны язын да, җәй башында да ашарга пешергәндә еш кулланабыз: щи, кондёр әзерләгәндә салабыз, – дип аңлата Илья Прокофьев, казан асылган учак төтененнән эче исеннән күзләрен кысып.

Экспедицияләр вакытында эзтабарларның рационы турындагы соравыбызга да, теләсә кайсы кибеттә сатып алу мөмкинлеге булган

БЕЗГӘ КИРӘК БУЛА:

- Яшь кычыткан – бер казан;
- сыер итеннән югары сортлы «тушёнка» – 1 банка (500 г);
- арпа ярмасы – 1,5 стакан;
- бәрәңге – 3 данә;
- кишер, суган – 1әр данә;
- тоз, борыч, дәфнә яфрагы – тәменчә.



1 Турыйбыз

2 Өстибез

3 Пешерәбез

4 Ваклыйбыз

5 Салабыз

6 Тозлыйбыз
һәм тәмләп карыйбыз

продуктлар, дип җавап бирә. Моңа ит, балык консервлары, макарон, төрле ярмалар, яшелчә һ.б керә. Меню дип баш ватасы юк, иң мөһиме – пешерүе ансат булсын, туклыклы ризык килеп чыксын.

– Җәй көнне табигать биргән нигъмәтләрне кулланабыз, гөмбә җыябыз, мәсәлән. Менә быел май аенда Ленинград өлкәсеннән кайттык, анда җыерчалы гөмбә (сморчок) вакыты иде. Бик тәмле жульен ясадык: башта гөмбәне пешерәсең, аннары табада кыздырып аласың, өстенә сыр уып җибәрәсең. Халык ашап туймый... Шунысы да бар: рационга кайда эшләвең дә йогынты ясый, әлбәттә, – дип сүзен дәвам итә Илья, бәрәңгесен турый-турый. – Мәсәлән, Мурманск өлкәсендә, балыкчылардан, балыктан тыш, диңгез продуктлары, краблар сатып алырга була. Хәер, үзебез дә экспедицияләр вакытында балык тоткалыйбыз, чөнки күбрәк су янынарак урнашырга тырышабыз. Үзебез белән кармак йөртмибез, әмма кирәк-ярагын алабыз. Җай чыга икән, берәр чыбык кисеп алабыз да – алга. Арабызда аучылар да бар, алар кайчак мылтыкларын ала. Андый табыш та ярап куя. Ауга чыгалар икән, бездә барысы да закон кысаларында алып барыла.

Бүген исә без кондёр пешерәбез!

ЯЗЫН – ЛЕНИНГРАД ӨЛКӘСЕНӘ

– Күптән түгел барган экспедиция турында әйтеп киттегез, ул «Татарстан канатлары» проекты кысаларында оештырылдымы?

– Юк. Любаньга, Ленинград янында инде 30 ел үткәрелә торган төбәкара экспедициягә бардык. Без ел саен барабыз, язын булабыз, пехота гаскәрләре буенча эшлибез. Быел җирле администрация үтенече белән югала барган хәрби каберлекне күчердек. Өске яктан инде беленми дә башлаган иде. Мондый каберлекләр, кызганычка каршы, әле бик күп. Аларны беркем дә тәртипкә китерми, чөнки алар үтеп керү кыен булган урыннарда урнашкан. Быел 90 сугышчының калдыкларын күтәрдек. Татарстанның эзтабар студент отрядларына йөрүчеләрне дә җәлеп иттек бу эшкә. Безнекеләр алтмыштан артык кеше иде, тагын Ленинград өлкәсендә урнашкан 90 нчы аерым махсус эзләнү батальонының бер ротасы. Казаннан 16 апрельдә киткән идек, 6 майда кайттык.

ҖӘЕН ҺӘМ КЫШЫН – ПОЛЯР АРЪЯГЫНА

– Ә самолётларны эзләргә соңгы тапкыр кайчан бардыгыз?

«ТАТАРСТАН КАНАТЛАРЫ» – Бөек Ватан сугышы чорындагы легендар Пе-2 самолётын торгызу проекты. 1941–1945 елларда 11 214 Пе-2 бомбардировщигы чыгарыла, шуларның 10 174 е Казандагы 22 нче авиация заводында (бүген – С.П. Горбунов исемендәге Казан авиация заводы) җыела.

Бүген Казанда һәм Татарстанда совет чорында иң күп чыгарылган очкычның бер генә данәсе дә сакланмаган. Ә Россиядә бары тик өч Пе-2 үрнәге генә бар: икесе – Мәскәү өлкәсе Монино авиация музее экспозициясендә, берсе – Свердловск өлкәсенең Югары Пышма шәхси хәрби техника музеенда.

Казанның Җиңү паркында урнашкан Пе-2 самолёты макетының чын хәрби машина белән уртаклыгы бик аз. Силуэты, пропорциясе, буяулары – бары тик шулар гына. Шассие булмау да тәэсир итү көчен киметә. «Ватан» төбәк иҗтимагый яшьләр оешмасы энтузиастлары үз алдына атаклы самолётны фронт машиналары фрагментларыннан торгызу бурычын куя.

– Соңгы дип сөйләшмик инде, – дип төзәтеп куя мине пешекчебез, ашка суган белән кишер өсти-өсти. – Март ае иде, Мурманск өлкәсенә. Хәзерге вакытта күбрәк Поляр арьягына йөрибез. Ул урыннарга үтеп керү бик кыен, шуңа күрә самолётларның таланып, таралып бетмәгән фрагментлары еш очрый. Ул урыннарга ике тапкыр керәбез. Беренчесе – җәен, быел август аенда барачакбыз. Вездеходларда, проблемалар булгаласа да, кереп җитәбез, эзләнәбез – экипаж калдыкларын табабыз, түшәмәләр ясап, шунда безгә кирәкле самолёт фрагментларын тезеп куябыз. Аларны инде кыш беткәндә, гадәттә март аенда, ул урыннарга снегоходларда кереп булганда алып чыгабыз. Узган елда Төньяк фронт Хәрби-диңгез флотының 95 нче авиация полкына караган Пе-2 самолётларын эзләдек. 1942 елның 26 апрелендә әлеге полк беренче бәрелешләрдә алты очкычын югалта. Августта тагын бер мәртәбә шунда эшләп карыйбыз.

ҖЫЯР ӨЧЕН 50 МИЛЛИОН СУМ КИРӘК

– Бүген сезнең проектны гамәлгә ашыру кайсы этапта?

– Казанга 81 самолётның фрагментлары кайтарылды, 185 очучының язмышы ачыкланды. Проект эшләп киткәннән бирле, эзләнү экспедицияләренең максаты – башта экипажның язмышын, очучыларны ачыклау, тәңгәлләштерү, шуннан соң гына самолётның үзе белән эшләү.

– Сугыш елларында ун меңнән артык Петляков бомбардировщигын җыйган Казанда чын Пе-2 кайчан пәйда булыр, югыйсә Җиңү паркында да әлеге очкычның макеты гына тора бит?

– Чынлыкта самолётның төп базасы – Пе-2 очкычын торгызырга мөмкинлек бирә торган фрагментларның 70 проценты җыелган. Барысы да акчага килеп терәлә. Куллары белән эшли белә торган белгечләрне ялларга, авиареставраторларны җәлеп итәргә кирәк. Аларга лаеклы эш хакы түлисе була. Шунысын әйтә алам: әгәр безгә 50 миллион сум акча бүлеп бирсәләр, бер ел – ел ярым вакыт эчендә самолётны җыеп, казанлыларга тәкъдим итеп булыр иде.

Бүгенге көндә моның белән бер Александар Коноплёв кына шөгыльләнә. Буш вакытында аңа Олег Арбузов булыша. Калганнар – болай гына, чакырганда, кирәк булганда гына.

– Сүз уңаеннан, киләсе елга Пе-2 очкычын Казанда чыгара башлауга 85 ел була. Әлеге юбилей уңаеннан шәһәргә һәм республикага менә дигән бүләк эшләү мөмкинлеге бар, димәк.

– Сезнең фикер белән килешәбез, без, әлбәттә, каршы түгел, – ди Илья, аш казанына төп ингредиент – кычытканны сала-сала. Чакмасын өчен, аны башта кайнар су белән пешекләп тә ала.

P.S.

Бу көнне ашарга пешергәндә дә, тәмләп ашаганда да сүзләр шактый булды. Кондёр – бабаларыбыз, ягъни арыган юлчыларны, мосафирларны, солдатларны гына коткарып калмаган, замандашларыбыз – эзтабарларны һәм журналистларны туендыра-берләштерә торган ризык, дигән нәтиҗәгә киләбез. Шулай ук ул «Татарстан канатлары» куйган максатына ирешер һәм Пе-2 бомбардировщигының легендар канатлары туган якка әйләнеп кайтыр, самолётка әйләнер, дигән өметне дә бирә. Т

1 Илья белән Ирина эзләнү экспедицияләренең берсендә 90 нчы елларда ук танышалар, әмма бер-берсен ун ел узганнан соң гына «күрәләр». Ә 2012 елда Илья РФ Оборона министрлыгындагы эшен калдыра һәм башкаланы Казанга алыштыра.

2 Среднее Ваенгское куле, Мурманск өлкәсе. 2017 ел.

3 Карелия, Лоухи районы. 2019 ел.

4 «Крылья Татарстана. Восстановить легенду» китабы авторы 2 нче томны «Татарстан» журналы китапханәсенә бүләк итте. Хәзерге вакытта 3 нче томның 26 бүлеге әзер. Аны бастыру финанслаудан тора.

Бөек Җиңүгә 80 ел тулу уңаеннан, «Кырык беренче ел балалары» рубрикасын дәвам итәбез. Бу юлы Бөек Ватан сугышы елларында өлкәннәр белән бергә тормыш арбасын җигелеп тарткан гади бер авыл баласының язмышын бәян итәбез.

«ГАРМУНДА УЙНАРГА ӨЙРӘНӘСЕМ КИЛДЕ...»

Әлфия Шаһиева

– Мин сентябрьдә туганмын. Сугыш июньдә башланган. Әтигә дә повестка килгән. Урактан кайткач ук, сугышка киткән. Шуннан әйләнеп кайтмаган, – дип башлады сүзен Мәдинә апа.

Ул вакытта Апас районына кергән (хәзер – Буа районы) Иске Чәчкаб авылында 1941 елны Мәдинә Сафина дөньяга килә. Әтисе Бәхетгәрәй сугышка киткәндә, ул әле тумаган да була. Биш ир малайдан соң бердәнбер кыз ул гаиләләрендә. Әтисе аны бик көткән, тик күрешергә генә насыйп булмаган шул...

«ӘТТӘ»

– Мин «әти» дигән сүзне гомумән белмим. Сугыш вакытында эти рәхәтенә тиенү кемгә генә тәтегәндер, – дип дәвам итте сүзен Мәдинә апа. – Ярый әле әни бар. Ул безне тәрбияләп үстерде. Әнием тырыш иде. Кул эшенә бик оста, бигрәк тә кием-салым тегәргә. Шуңа минем өскә дә эш күп төште. Сугыш чоры булса да, яшьләр күлмәкләр тектерә. Сабан туйларында әнигә чират тезелә иде. Хәзер мин бу сәләтне Аллаһы Тәгаләнең безнең гаиләгә булган рәхмәте, чиксез нигъмәте дип кабул итәм. Чөнки шушы хезмәт безнең «ипи» иде. Бераз булса да май, ипи, сөт, бәрәңгегә алыштыра алганбыз. Әниебез кырыс булмады. Киресенчә, бик йомшак, динле, мөлаем хатын-кыз иде. Миңа кадәр туган биш абыйның өчесе тугач та 2-3 ай яшәгәннән соң үлгән. Икесе генә исән калган. Әле этинең әнисе – әби дә безнең белән яшәде. Әбием миңа тугыз

Фотолар автордан, геройбызның шәхси архивыннан алынды

яшь тулганда бакыйлыкка күчте. Әбием догалар өйрәтеп үстерде. Чын күңелдән рәхмәтлемен аңа. Мәрхүмәнең бер генә баласы булган. Ул миңа «әттә» дип әйтергә өйрәткән. Мин «әттә» дигән саен, атасы кайта микән әллә дип куанган. Бала булган бит әле мин, «әттә» дип әйтергә кушкандыр да, әйткәнмен инде, – дип елмаеп куйды Мәдинә апа. – Кем улын котмәсен? Барысы да өмет белән яши.

– Фронттан хатлар килеп тордымы? – дип сорап куям.

– Әйе, әтинең хатлары килеп торды. Алар хәзер, кызганыч, сакланып калмаган. Әти 1943 елда хәбәрсез югалды, күмелгән урыны да билгесез. Соңгы хатында, Днепр күперенә керәбез, дигән. Ә шул көнне немецлар күперне шартлаткан. Халык күп кырылган. Елга суы кып-кызыл булган, дип сөйлиләр иде. Менә шунда үлгәндер безнең әти дип, күңелемнән генә уйлап йөрим. Ул хатында: «Дөньялыкта күрешә алмасак, ахирәттә күрешербез», – дип бәхилләшкән. Өчпочмаклы хатлары хәзер дә күз алдымда тора. Аларны әни укый иде. Алар кадимчә, ягъни иске татар хәрефләре белән язылган иде.

Әнием соңгы унбер елын урын өстендә үткәрде, бик озак җәфа чикте. Шушы күренеш хәзер дә йөрәгемдә төер булып утыра. Һәр кешенең үз язмышы инде, нишләтәсең...

«СУГЫШ БЕТТЕ», ДИП ЕЛАШТЫЛАР...

– Авыр чор булган бит, ничек көн күрдегез? – дим.

– Дөньяда ачлык, ашарга ризык юк. Кайвакыт, булганда, ипигә бәрәңге уа идек. Мичкә көрәк белән кертеп җибәрәсең дә, шунда пешә. Аннан да тәмлерәк ризык юк иде кебек. Ә кемдәдер ипи дә, бәрәңге дә юк. Юклык, хәерчелек бит. Менә без, сугыш чоры балалары, шуларны күргәнгә, үзебезнең җилкәдә татыганга, бернәрсәне дә әрәм итмибез, һәр ризыкның, һәр әйбернең кадерен беләбез, – диде Мәдинә апа.

– Ә сез сугыш беткән көнне хәтерлисезме? – дип сорыйм.

– Сугыш беткән көнне чат хәтерләмим. Миңа әле ул чагында 4 яшь тә тулып җитмәгән, аңлап та бетермәгәнмен инде. Алай да, сугыш бетте дип, шатлыктан елашканнары истә кебек.

«КӘБЕСТӘНЕ АБЫЙ АШАП БЕТЕРГӘН»

– Балачак дигәч, күз алдыгызга нәрсә килеп баса? – дим.

– Ул чагында эш инде. Терлек асраган, үләнгә барганнар. Ашарга булсын дип, базарга төрле нәрсәләр сатарга чыгып киткән чаклар. Ачлык рәхәт нәрсә түгел бит.

Сабан туенда дус кызлар белән. Сулдан беренче – Мәдинә апа.

Балачагым бер дә күңелле булмады. Дөресен генә әйткәндә, рәхәт балачакның нәрсә икәнен белмим дә. Эш күп булды. Казлар асрый идек. Бераз кул арасына керә башлагач, әче таңнан биби сакларга чыгып утырасың. Көтү куыш инде, бар хәлгә йөгереп, бәрәннәр эзли идек. Керне инешкә төшеп юасың, ә кыш көннәрендә бәкедә чайкыйсың. Абыйларга булыша, пычкы белән утын кисешә идем. Бервакыт Габбас абыем белән утын ярабыз. Селкенмәсен дип, агачны тимер чөй белән тотып торам. Абый чөйгә китереп сукты да, чөй минем маңгайга килеп бәрелде. Аның төзәлүе – үзе бер маҗара... Ул чорда бит врачка күренүләр юк. Маңгайдан ап-ак сөяк күренеп торгач, баш мие чыккан, дип уйлаган әни. Яулык белән башны кысып бәйләп куйды да, шөкер, шуннан төзәлеп китте. Ләкин эзе гомерлеккә калды. Аллаһы Тәгалә саклап калган инде мине, – ди Мәдинә апа. – Ул вакытта җиде яшьләрдә булганмын. Әй, күрмәгәнне күрдем инде. Чыныгып үскән, рәхәт күрмәгән балалар без.

Мәдинә апа, җиде класс тәмамлап, фермага эшләргә төшкән. Анда атлар, куяннар караган, сыер да сауган.

– Яшь булгач, кич белән урамга да чыгасы килә, иртәнге дүрттә эшкә ничек йокымсырап төшкәнне әле дә хәтерлим, – дип, елмаеп искә ала яшьлеген Мәдинә апа. Ул фермада 55 яшькә кадәр хезмәт иткән.

– Әле гектар-гектар чөгендер дә бирәләр иде. Фермада да эшләргә, чөгендерне дә кәтмәнләргә, йортны да карарга кирәк. Урам саен сөт җыйдык. Сөт флягасын да мин юа идем... Ул заманда борчакларны да чалгы белән чабыш, – диде Мәдинә апа. – Бер елны 10 гектар борчак чаптым. Әле аны юлга җәеп салырга кирәк. Аннары егылган люцернаны да унышар кеше чалгы белән чаба. Безнең чорда эшләр авыр иде шул, – дип, авыр сулап куйды әңгәмәдәшем.

Олы абыйсы 1930 нчы елгы, Мәдинә апа туганда аңа 11 яшь булган.

– Сугыштан соңгы еллар иде, аның эштән кайткач сөйләгәне истә: «Әй, бүген кич белән

Яшь чак истәлеге.

Мәдинә апа иренең сеңлесе Рушания белән.

бакчага кәҗә кәбестә ашарга килгән иде», – ди бу миңа. Баксаң, кәбестәне абый үзе ашап бетергән икән. Егет кешенең эштән соң, билгеле, ашыйсы килгәндер инде. Тамак сорый бит, юк дигәнне белми.

Элек хуҗалыкларда яшелчә утыртмыйлар иде, дип тә искә ала Мәдинә апа. Колхоз бакчасында үскән яшелчәләрне «труд»ка – эшләгән көнгә карап бирә торган булганнар. Абыйсы шул кәбестәнең башына җиткән икән. Әле 1964 елда да «труд» көннәре язганнары турында да сөйләде әңгәмәдәшем. Ул чагында инде 1 «труд»ка 6 ипи килә торган булган.

– Безнең заманда 16–17 яшьләрдә шәһәргә китәләр иде. Шунда эшкә урнашып, хәтта урам себерергә керсәң дә, квартира бирәләр, – дип сөйли әңгәмәдәшем. – Китәргә дигән уй бар иде. Ләкин әни: «Ике абыең монда булып, син бурлакка чыгып китмәссең инде», – диде. Шулай итеп монда калдым. Әнигә рәнҗемим. Үкенмим дә. Аллаһка шөкер, авылда калып та ким-хур яшәмәдек. Барына канәгать булып яши белергә дә кирәк бит. Бер уйласаң, акча беркайчан җитми инде ул.

ХЫЯЛДА КАЛГАН ХЫЯЛ

– Мәдинә апа, хыялыгыз бар идеме, нинди хыяллар белән яшәдегез?

– Минем бер генә хыялым бар иде – гармунда уйнарга бик өйрәнәсем килде. Тик фермада эшләгәч, өйдә килен дә булгач, кая гармун сузып утырасың инде. Шәһәргә киткән булсам, бәлки, хыялымны чынга ашырган булыр идем, дип уйлыйм.

– Хәзер гармунда уйнарга өйрәнер идегезме? – дип сорап куйдым.

Бу соравыма елмаеп җавап бирде Мәдинә апа:

– Юк инде, кызым. Ул хыяллар үткәндә генә калды...

– Ә бала чакта кем булырга теләгән идегез? – дим.

– Аларын хәтерләмим инде, әллә ни теләк тә юк иде. Тамак ач булгач, башка андый уйлар керми. Күңелең тыныч булса гына, төрлесен уйлыйсың икән, – дип җавап кайтарды ул.

Мәдинә апа, хуҗалыкта бетмәс-төкәнмәс эш булуга да карамастан, кайчак, буш вакыт табып, китап укырга яраткан. Хәзер дә ярата. «Икенче дөньяга кереп киткән кебек булам», – ди. Авырлыклар аша үткән, тирән, гыйбрәтле язмышлы кешеләр турында уку күңеленә хуш килә аның.

«ҖӘННӘТТӘ ЯШИМ...»

– Кияүгә үзебезнең авыл егетенә – Гарифуллага чыктым. Артымнан бер дә калмыйча йөрде. Миңа – 22, аңа 23 яшь иде. Әйбәт яшәдек. Аның тарафыннан начарлык күрмәдем. Төп йортка 10 нчы кеше булып килдем. Кайната, кайнана, әби, 6 бала. Ирем эне-сеңелләреннән күпкә олырак. Алар әле мәктәптә укыйлар иде. Шулай яшәп киттек, – дип сөйләде Мәдинә апа.

– Җәмәгатем белән өч бала үстердек. Гөлгенә, Гөлия һәм Марат. Ике кызым да 15 яшьтә шәһәргә чыгып китте. Тотмадым. «Хәлегездән килгәнчә укыгыз», – дип, фатихамны бирдем. Үзем китә алмагач, балаларны җибәрдем. Берсе Англиядә яши, икенчесе – Казанда. Марат минем белән тора. Оныкларым да үсеп буйга җитте. Аллаһка мең шөкер, үз юлларын таптылар.

Әмма ире белән энҗе туйлар күрергә язмаган Мәдинә апага. Иренең үлеме аяныч булган. 52 яшендә тол калган. Сабыр булган, түзгән, балалар хакына булса да, яшәргә көч тапкан.

– Ул чакларга кире әйләнеп кайтырга теләр идегезме? – дип сорыйм, күңел яраларына кагылуыма борчылсам да.

– Хәзерге тормышымнан канәгать. Әлхәмдүлилләһ, җәннәттә яшим, – диде ул, елмаеп.

Мәдинә апа кызы белән.

игелекле эшләр

мәңгелек кыйммәтләр /

акыллы гамәлләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Татар поэзиясендә **кайсы** чорда хатын-кызлар хөкем сөрә башлый

Китап киштәсендә **нинди** китаплар бар

Тымытык авылы **ничек** яши

Казанда агач йортлар **ничек** сакланган

МАНСУР АБДРАХМАНОВ: ТАТАРНЫҢ СОВЕТ ЧОРЫ ФИЛОСОФЫ ҺӘМ ИДЕОЛОГЫ

Айдар Шәйхин

Һәрбер халык дөньяны үз фәлсәфәсе аша танып белә. Бу фәлсәфәнең чаткылары халык авыз иҗатында, әйтем-мәкальләрдә, гореф-гадәт һәм йолаларда табыла, ә матур әдәбиятта ул үзен тагын да куәтлерәк итеп ача ала. Төрки-татарларда меңәр ел булган фәлсәфи күзаллау XX гасырда Европа философиясе белән очраша. Казан дәүләт университеты профессоры Мансур Абдрахманов – диалектик материализм фәлсәфәсен һәрбер татар баласы туган телендә аңларлык итеп дәреслек төзегән мөгаллим дә, философия фәннәре докторы дәрәҗәсенә ирешкән беренче татар галиме дә.

БӨЕК СУГЫШНЫҢ БЕР ЯТИМЕ

Ул 1912 елның 31 гыйнварында Казанда туа. Госманов мәчетенең (хәзерге Солтан мәчете) туулар, никахлар һәм үлемнәр теркәү кенәгәсендә Мансурның иске стиль белән 18 гыйнвар көнне тууы хакында метрика язмасы бар. Документтан булачак философның әтисе – Спас өязе Пичкас волостенең Көек авылы крестьяны Ибраһим Габдрахман улы Гомәров, ә әнисе Рабига Хөсәен кызы Таһирова икәне дә ачыкланды.

Бу авылдан чыккан иң атаклы кешеләрнең берсен барыбыз да беләбез: Көектә каһарман шагыйрь Абдулла Алиш туган. Авылның язма тарихы 1656 ел тирәсеннән башлана, инкыйлабка кадәр ул ике мәчетле, ике мәктәпле, биш тегермәнле, 2 меңләп халкы булган зур авыл буларак дан казана.

Ибраһим Гомәров ни сәбәп белән Көектән Казанга киткәндер, әмма гаиләсенең киләчәге алга таба татар мәркәзе белән бәйле. Мансур туган чакта 22 яшьлек Ибраһим приказчик булып эшли. 1914 елның җәендә гаилә башлыгы Беренче бөтендөнья сугышына алына. Күп тә үтми, хәзерге Польшаның Быхава шәһәрчеге тирәсендә 1914 елның 11 августында хәбәрсез югала.

Рабига ханым ике улы – Мансур һәм Мәсгут белән ялгызы кала. Рабига Хөсәен кызы Таһирова үзе 1892 елда Казанда туса да, аның нәсел-нәсәбе Әтнә районы Мәрҗән авылыннан булган. Бу авыл Шиһабетдин Мәрҗани нәселе барып тоташа торган җирлекләрнең берсе. Бәлки, Мәрҗани һәм Абдрахманов арасында уртак туганлык җепләре дә булгандыр...

Рабига ханым яхшы белем ала, Казанда кызлар мәктәбендә укыта, Гражданнар сугышы елларында тегүчелек белән дә көн күрә. Ире һәлак булгач, яңадан кияүгә чыкмый. 1921 елгы ачлык вакытында Мансур белән Мәсгут балалар йортына эләгә. Рабига ханым, сәламәтлегенең нык какшаганын аңлап, улларын балалар йортына тапшыра, бераздан вафат була.

Дәһшәтле ачлык елларында Казанда ятимнәр һәм бик фәкыйрь ата-аналарның балалары өчен йортлар күпләп ачыла. Анда ачлык аркасында аеруча зыян күргән гаилә балалары да була. Алар өчен бу – исән калу мөмкинлеге. Сәламәтлек саклау комиссариаты һәм Американың ачлыктан котылу идарәсе ярдәм итсә дә, бу оешмаларның күбесендә яшәү шартлары коточкыч начар була. Мөгаен, шунлыктандыр Мансур белән Мәсгут, тиз арада балалар йортыннан качып, әниләренең туганнарына барып керәләр.

1924 ел. Мансурга 12 яшь. Моңа кадәр башта бераз мәдрәсәдә, аннан татар мәктәбендә укыган яшүсмер Ленин исемендәге 4 нче

Фото: ТР Милли музее һәм КФУ тарихы музее фондларыннан

рус мәктәбенә керә, биредә биш ел укый. Укытучылары да, шәрикләре дә шәп була аның. Мәсәлән, бер сыйныфташы һәм буш вакытта шахмат уйнаганда төп иптәше – Рәшит дигән малай. Озакламый ул малайның даны бөтен Союзга таралачак, дөнья аны Рәшит Нәҗметдинов дигән гроссмейстер буларак беләчәк.

Тәрбиягә алган туганнарына булышу йөзеннән, Мансур җәй көннәрендә сезонлы эшләрдә катнаша. Башта бер кондитерда йомышчы малай булып йөри, үсә төшкәч, Казанда мех комбинаты төзелешендә бетон коючы булып эшли.

1929 елда мәктәпне тәмамлый, комсомолга кабул ителә. Авылларда халыкны агартырга тиешле яшьләр сафына керә һәм культармияче буларак Яңа Ибрай авылына җибәрелә.

ЯҢА ИБРАЙДА

Аксубай районының Яңа Ибрай авылы – Абдрахманов өчен туган авыл дәрәҗәсенә якын торган урын. 1930 елда ул бирегә башлангыч мәктәпкә укытучы булып килә. Ул елларда Яңа Ибрай – 800ләп хуҗалыгы булган искиткеч зур авыл. Мансур монда бер ел эшләргә тиеш булса да, 4 елын уздыра.

Мансурга утырып калган балалар укый торган сыйныфны бирәләр. Балалар белән бергә егетнең үзенә дә укырга туры килә. Ул бит әле педагогик белем алган укытучы да түгел, өстәвенә, рус мәктәбендә укып, татар авылына шәһәрдән килгән. Язу да алышынган, яңалифкә күчкән вакыт.

Яңа Ибрай мәктәбе музеенда Абдрахмановның шул еллардагы блокнотлары саклана. Анда аның физик күнегүләр ясау тәртибе, расписаниеләре теркәлгән. Ул үзе кыш көне чаңгыда шуа, балалар белән бергә агачтан «тимераяк» ясап, аларны бозда шуарга өйрәтә. Спорт белән дуслык һәм үз өстендә эшләү аңа балалар белән эшне оештырырга да булыша, тормышында да төп ярдәмче була.

Мәктәп директоры кинәт үлеп киткәч, Мансурны аның урынына билгелиләр. Бик тиз арада кызу эш башлана: ул мәктәп өчен ике катлы агач бина төзетә, нәтиҗәдә, башлангыч мәктәп җидееллыкка (колхоз яшьләре мәктәбенә) әйләнә. Авылда колхоз төзүгә дә Мансур һәм аның белән бергә килгән яшьләр зур өлеш кертә.

Авылда Мансур гомерлек юлдашын да таба. Яшьтәше, мәктәптә татар теле укытып йөргән Зәкиязәйнәп Хуҗамәхмүт кызына гашыйк була ул. Яшь укытучылар гаиләсе башта мәктәп чормасында яши. Зәйнәп соңрак, 1935–1939 елларда, Казан педагогика институтында укып чыга,

Мансур белән Зәйнәп 1934 елда Казанга китәләр. Әмма авыл белән элемтә беркайчан да өзелми. 1966–1967 елларда Яңа Ибрайда 320 урынга исәпләнгән яңа таш бина җитештерелә. Бу яңа төзелешкә дә Мансур Абдрахмановның ярдәме тими калмый, чөнки бу елларда ул Татарстан Югары Советы Рәисе вазыйфасын башкара, депутат буларак, авылдашларына ярдәм кулын суза. 1974 елдан мәктәп Мансур Абдрахманов исемен йөртә.

ПЕДИНСТИТУТТАН – ПОЛИТРУККА

Ике ел армия хезмәтен үтәгәннән соң, 1936 елда Мансур Казан педагогика институтының тарих факультетына укырга керә. Соңгы курска җиткәч, укуны туктатырга туры килә, чөнки ул 1939 елның декабрендә фин сугышына китә, анда чаңгычылар батальонында хезмәт итә. Кыска сугыш тәмамлангач, ниһаять, кызыл диплом иясе була һәм үзе укыган тарих кафедрасына эшкә урнаша. Карьерасы бик тиз күтәрелә: институтта партбюро секретаре, декан урынбасары, китапханә директоры.

Бөек Ватан сугышы башлангач, институт җитәкчелегендә булган ирләрнең күбесе үз теләкләре белән фронтка китә. Мансур берничә тәүлек эчендә пединститут китапханәсен тулысы белән дәүләт университетына тапшыра (институт бинасында госпиталь ачылырга тиеш була). Шуннан соң, югары белемле яшь кешене әүвәл Куйбышевтагы хәрби-сәяси училищега, аннары Фрунзе академиясенең командирлар курсларына җибәрәләр. Нәтиҗәдә, Абдрахманов сугышта пулемёт ротасы командиры буларак катнаша.

1943 елның 4 июлендә Белгород янында командир Абдрахманов бик каты яралана, аның янында гына мина шартлый. Мансур бер аяксыз кала. Шуннан соң Ереванда һәм Әрмәнстанның башка шәһәрләрендә эвакогоспитальләрдә бер ел тирәсе дәвалана. 1944 елда, култык таякларына таянып, Казанга кайтып керә. Сугышка кадәр сәламәтлеге ташып торган мөгаллимне сугыштан соңгы буын студентлары һәрвакыт аксый-

Мансур Абдрахманов имтихан кабул итә.

аксый гына кафедрадан төшкән, кайвакыт яралы аягы бик борчыганга, дәресләрен калдырырга мәҗбүр булган ветеран дип истә калдырган.

Аны янәдән Казан педагогика институтына өлкән укытучы итеп эшкә алалар. Әмма бу юлы да ул пединститутта озак тормый. 1944 елның көзендә Казан дәүләт университетына аспирантурага укырга керә. «Казан губернасында крестьян хәрәкәтен җитәкчелек итүдә РСДРП Казан комитеты эшчәнлеге» темасына кандидатлык диссертациясен язып яклый.

Хезмәт биографиясе университетта дәвам итә. 1948–1949 елларда – марксизм-ленинизм кафедрасы өлкән укытучысы, аннан философия кафедрасы укытучысы, соңрак доценты була. Ә 1950–1953 елларда ул данлыклы тарих-филология факультетын җитәкли. Абдрахманов деканлык иткән дәвергә Мансур Хәсәнов, Альфред Халиков, Гариф Ахунов, Казбек Гыйззәт кебек булачак фән һәм әдәбият эшлеклеләренең студент еллары туры килә. Академик Мансур Хәсәнов деканын, «легендар кеше һәм ветеран иде», дип искә ала.

1957 елдан ул диалектик һәм тарихи материализм кафедрасы мөдире итеп сайлана һәм озак еллар шушы вазыйфада хезмәт итә.

БЕРЕНЧЕ ДОКТОР

1954 елда Мәскәүдә докторантурага керә. Докторлык диссертациясе «Социалистик производство мөнәсәбәтләре – СССРда производство көчләре үсешенең төп двигателе» темасына багышлана. Ул төп фәнни эшен СССР Фәннәр академиясенең Фәлсәфә институтында 1958 елның 11 февралендә яклый. Бу хезмәтендә СССР икътисад системасында социалистик җитештерү мөнәсәбәтләренең барлык җәмгыять күренешләренә тәэсир итү механизмнарын өйрәнә. Әлбәттә, иң мөһим тезисларның берсе – социалистик җитештерүнең капиталистик мөнәсәбәтләрдән өстенлерәк булуын, капитализмның тупикка терәлүен тәкрарлау.

Фәнни хезмәтне диссертация советы бик югары бәяли. Утырышта катнашучыларның берсе, иҗтимагый үсеш диалектикасы белгече Григорий Штракс: «Бу мәсьәләгә багышлап язылган әдәбиятны укыган кеше буларак, Абдрахмановның диссертациясе теманы иң тулы рәвештә ачкан хезмәт икәнлеген әйтә алам», – дип белдерә. Шулай итеп, фәнни җәмәгатьчелек татар кешесе марксизм-ленинизм фәлсәфәсе буенча язган беренче диссертацияне хуплап каршы ала. 1958 елдан Абдрахманов – татарлардан беренче философия фәннәре докторы. Бер елдан соң исә диалектик һәм тарихи материализм кафедрасы буенча профессор дигән гыйльми исем ала.

ҖӘМӘГАТЬ ЭШЛЕКЛЕСЕ

Доктор һәм профессор 7 ел буена Казан дәүләт университетында фәнни эшләр буенча проректор булып эшли. Ә 1968–1971 елларда ТАССР Югары Советы депутаты һәм рәисе була.

Абдрахманов – Казанда социологиягә нигез салган галим Марат Садыйковның фәнни җитәкчесе, 90 нчы елларда татарча философия һәм эстетика дәреслекләре язган Казбек Гыйззәтнең остасы. 20 философия фәннәре кандидатын тәрбияли ул. СССР Фәлсәфә җәмгыятен оештыруда катнаша, аның Татарстан бүлеген барлыкка китерә һәм җитәкли.

Мансур Абдрахманов архивында сакланган кызыклы документларның берсе – аның Леонид Брежневка хаты. 1965 елда ул Брежнев, Микоян һәм Косыгинга хат юллый. Сүзне партиягә рәхмәтләр укудан башлый, аннан төп мәсьәләгә – Ленинның 100 еллык юбилеенә әзерлек кысаларында бөек юлбашчы укыган университетка игътибар җитмәү темасына күчә.

«Сезгә шундый фактны гына искәртәм: иптәш Хрущев Казанда булган чагында университет яныннан узып китте һәм В.И. Ленин бүлмәсенә кереп чыгуны кирәк дип тапмады. Халкыбыз моны сәяси өлгермәгәнлек билгесе дип кабул итте». Яңа гына хакимияттән төшерелгән Хрущевның сәяси хатасын ассызыклап, ул яңа башлыкның игътибарын университет темасына җәлеп итәргә тели. Ә максат гади: төзелеш. Бу елларда студентлар, факультетлар арта, әмма уку-укыту, фәнни-тикшеренү өчен мәйданнар да, хезмәткәрләргә торак белән ярдәм итү мөмкинлекләре дә җитми. «Мәсьәләгә җитди караган очракта, ул капиталь һәм мемориаль рәвештә хәл ителә ала. Хәзерге университет шәһәрчеге янындагы бөтен территорияне, эчендә Ленин шәһәрчеген (1887 елгы чикләрдә) саклап, чын Университет шәһәренә әйләндерергә була», – дип әйтә ул.

Мансур Абдрахманов эш бүлмәсендә.

Мансур Абдрахманов чыгыш ясый.

Мансур Абдрахманов президиум утырышында чыгыш ясый.

Чыннан да, 60–70 нче елларда Казан дәүләт университетында зур төзелешләр башлана. Казанның татар тормышында да Мансур Абдрахманов актив катнаша. Архивта аның Тукай бәйрәмнәрендә, Гомәр Бәширов, Таҗи Гыйззәт кебек әдипләрнең юбилейларында ясаган чыгышлары сакланган. 1970 елда «Татарстан коммунисты» журналы, ягъни хәзерге «Татарстан» журналы, үзенең 50 еллык юбилеен бәйрәм итә. Татарстан телевидениесендә бу уңайдан 11 декабрь көнне махсус тапшыру да чыга. Мансур Абдрахманов әлеге тапшыру кунакларының берсе була. Аңа бу тапшыруда 55 ел элек бирелгән сораулар Татарстанда матбугат һәм иҗтимагый фәннәр тарихы күзлегеннән бүген аеруча кызыклы яңгырый. Бу тапшыруның сценарие Яңа Ибрай мәктәбе музеенда сакланган. Абдрахмановның әйтәсе килгән төп фикере аңлашыла: республиканың төп коммунистлар журналында татар темасы, милләт мәсьәләсе партия позициясеннән дөрес яктыртыла, иҗат берләшмәләре тормышы, актуаль әдәби процесс яңалыклары күрсәтелеп бара.

БЕРЕНЧЕ ДӘРЕСЛЕК

Мансур ага, 1940 нчы еллардан башлап, татар телендә иҗтимагый-сәяси һәм фәлсәфи темаларга мәкаләләр яза. Мәсәлән, 1952 елда «Совет әдәбияты» журналында Әбү Гали Ибн Синаның 1000 еллыгы уңаеннан «Әбүгалисина» дигән очеркы басыла. Абдрахманов сурәтләгән Ибн Сина ул – үзен халык вәкиле дип танучы, материализм-идеализм каршылыгын фәнни тәҗрибәләр аша хәл итәргә омтылып, «ислам кануннарына көчле удар ясаучы», шуның аркасында хакимлек итүче катлау тарафыннан эзәрлекләнүче кеше. Абдрахманов биредә татарларда таралган Әбүгалисина образын да кыстыра: «Татар буржуа милләтчеләре дә Әбүгалисина турында ялган экиятләр төзеделәр һәм аны әфсенче, сихерче дип күрсәтергә тырыштылар», – дип яза ул. Шулай да, фәлсәфи карашларны анализлавы кызыклы. «Димәк, чынбарлык безнең аңыбыздан башка яши. Безне чолгап алган нәрсәләрнең төп эчтәлекләре һәм аларның очраклы чагылулары бар. Ул чагылуларны төп эчтәлек билгели. Әбүгалисина монда эчтәлек белән форма турында ачык әйтмәсә дә, аның бу фикерләре философиядәге эчтәлек һәм форма категорияләре турындагы өйрәтүләргә нигез сала, дип расларга була». XI гасырда яшәгән таҗик-фарсы галименең карашларын марксистларча аңлатып кара әле син!

1960 нчы еллар уртасында Абдрахманов иң кыю проектына керешә. Университет студентлары да, агитаторлар да кулланырлык дәреслек яза башлый ул. Марксизм-ленинизм фәлсәфәсе турында дәреслекне Абдрахманов ике кисәктән торырга тиешле дип саный. Беренчесе «Диалектик материализм» дәреслеге булса, икенче кисәге тарихи материализмга багышланырга тиеш булган. Беренче китап 1966 елда басылып чыга. Фәнни мөхәррир вазыйфасын фәлсәфә фәннәре кандидаты Камил Фасеев үтәп чыга. Абдрахманов дәреслеге җыйнаклыгы һәм аңлаешлыгы белән дан казана. Авторның, марксизм-ленинизм тәгълиматын аңлатканда, татар халык иҗатыннан һәм актуаль әдәбияттан мисаллар китерүе аеруча уңышлы була. Бу дәреслек озак еллар дәвамында Казан дәүләт университетында кулланыла.

Бай фәнни мирас, төзелгән мәктәп биналары, шәкертләр һәм дәвамчылар калдырган Мансур Ибраһим улы Абдрахманов 60 яшендә, 1972 елның 25 декабрендә вафат була. Яңа Татар зиратында мәңгелек сыену таба.

Портретына соңгы бер штрих итеп бөек рәссам Бакый Урманче көндәлегендә язылган ике җөмләне китерик: «Ул да мәрхүм Мәрҗани кабере катында җирләүләрен васыять иткән икән, шулай иттеләр. Бусы акыллы, аңлы кеше иде».

ХӘТЕРНЕҢ ДӘҺШӘТЛЕ БИТЛӘРЕ

2025
ВАТАННЫ САКЛАУЧЫЛАР ЕЛЫ

80 ЖИҢҮ!

1948 елда Казан Тел һәм әдәбият институтының фольклор секторы галимнәре Хәмит Ярми белән Халидә Гатина һәм булачак язучы, ул вакытта Казан университеты студенты Нурихан Фәттахов сугыштан соң беренче тапкыр Татарстанның Актаныш, Калинин (бу район 1959 елдан Актаныш һәм Мөслим районнарына бүлеп бирелә), Мөслим һәм Минзәлә районнарына фольклор экспедициясенә чыгалар. Сугыш тәмамланып өч ел узган. Әмма, тыныч тормыш башлануга карамастан, сугыш турындагы истәлекләр дә, ул калдырган яралар да яңа була әле. Бу экспедицияләр вакытында галимнәр белән аралашучыларның, мәгълүмат бирүчеләрнең дә күбесе – Бөек Ватан сугышында катнашкан кешеләр, фронтовиклар. Алар Бөек Ватан сугышы турында шактый гына истәлекләре белән дә уртаклашалар, үзләре катнашкан яулар, дошман тылына разведкага барулары, сугышчан дуслары турында да сөйлиләр.

Сезне дә 1948 елгы шушы фольклор экспедициясе вакытында Халидә Гатина белән Нурихан Фәттахов язып алган сугыш турындагы истәлекләр белән таныштыруны дәвам итәбез. Язмаларны, сөйләүчеләрнең сөйләм үзенчәлекләрен саклаган хәлдә, үзгәрешсез диярлек тәкъдим итәбез. Сугыш ветераннарының җанлы сөйләме истәлекләрдәге вакыйгаларны тулырак күзалларга, шул чорның дәһшәтен тоярга ярдәм итәр, дип өметләнәбез.

Фотолар: Г.Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге фондыннан, Минзәлә туган якны өйрәнү музее.

ХӘНИФ ШӘЙМӘРДАНОВ: «МОННАН ИСӘН ЧЫГУЧЫ ЮК...»

Илсөяр Закирова

Мөслим районының Сикия авылында яшәгән Хәниф Шәймәрданов (1948 елда 38 яшьтә була) истәлекләрендә сүз сугышның тагын бер фаҗигасе – әсирлек турында бара. Авыр яраланып, дошман кулына эләккән һәм фашист концлагерьларында тәмуг газапларын кичергән кеше ул. Бер лагерьдан икенчесенә күчерелеп, ахыр чиктә Майданек – Польша җирендә, Освенцимнан кала, икенче урында торган үлем лагерена барып эләгә. Бу лагерьда исән калу бик сирәкләргә генә эләгә.

Сугыш истәлеген 1948 елның 24 июнендә Нурихан Фәттахов язып ала.

– Мин 1942 елның декабрь азагында Старая Русса шәһәре тирәсендә бик каты яраландым. Ике аяк «ранен» булды минем, пуля тиеп чәрдәкләде. Уң кул ике җиреннән «ранен» булды. «Ранен» булгач, мин 5 сәгатьләп кар өстендә ушсыз ятканмын. Исемә килеп, күземне ачсам, немесләр килеп җиткән.

Өч немес солдаты килде минем кырга. Торырлык хәлдә түгел бит мин. Ике немес солдаты таяк белән кыйный башлады. Өченчесе нәрсәдер кушты да, тегеләр мине кыйнаудан туктады. Шул өч неместән соң тагын бик күп булдылар болар. Җиңелрәк раненный солдатларга күтәртеп, безне каядыр алып киткәннәрен сиздем. Миннән башка да раненныйлар күп икән. Безне автомашинага илтеп салдылар. Шуннан соң, бер авылга тукталып, анда сыер лапасына ябып куйдылар. Бик күп кенә иек без анда.

Монда тыштагыга караганда бераз җылырак. Безгә бер бидрә бозлы су китереп бирделәр, аннан соң бераз туң борчак. Җиңел раненныйлар суны эчтеләр. Миңа хәрәкәт итәргә бер җай да юк. Аннан соң безне алып киттеләр. Китереп салдылар бер такта лапас кебек җиргә. Аның эчендә кар, бераз салам. Азрак җөри алган кешеләр шул саламны җылыттылар. Безнең хәлне белүче-нитүче дә юк әле.

Моннан да алып киттеләр. Безне тагын машина белән каядыр алып баралар, кая барабыз – без белмибез инде. Пересыльный пункттан багунга төяделәр. Багун эче шәпшәрә, коры идән. Салкын. Бик күп тутырдылар безне монда. Халык өстендә халык. Сине «ранен» дип тормыйлар анда. Кая барганны әле дә белмибез.

Пуезд белән Пороховога барып төштек. Пуездан төшергәч тә, безне мунча керттеләр. Шуннан соң госпитальгә илттеләр. Палатада халык бик күп ие. Минем шунда аякны кистеләр болар. Эч китә башлады, гел ачыган кәбестә суы, черек бәрәңге ашаталар бит монда. Икенче палатага күчерделәр. Монда суык, пычрак, туендыру җук. Бөтен тәндә, өс киемендә – бет, сыпырып төшерәбез.

Халык көн үлә, төн үлә монда. Үлекләрне алмыйлар, шулар белән бергә ятабыз. Безгә көненә 200 грамм опилка әпие бирәләр, 700 грамм кәбестә суы. Мин шундый хәлдә биш ай яттым. Бу вакыт эчендә тән тире белән сөяк кенә калды. Немесләр һәрбер кешегә нумер тактылар, ул фанир тактага язып куелган. Әгәр шул нумерыңны муеныңа такмасаң, алып чыгып кыйныйлар иде. Уштан язганчы, хәлең беткәнче, җаңакка чапкалыйлар. Безне моннан күчерделәр. Киндерхос (Польшада, Лодзь шәһәрендәге Киндерхаус балалар концлагере булырга мөмкин – ред. иск.) дигән лагерьда яттык. Анда да безгә черегән кортлы сыр бирәләр, 200 әр грамм һәм кычыткан суы. Агуланып кешеләр күп үлде.

Ноябрьдә безне Швециягә озаттылар. Мунча керттеләр баргач та. Аннан соң ике аяксызларны, утын төягән кебек, берничә арбага төяп, каядыр җибәрделәр. Арбаны авыр булмаган «ранен» солдатлар алып бара. Бер аяклыларны алдан җәяү җибәрделәр. Алар баралмай башлагач, әрдәнә кебек, безнең өскә атып-атып бәрәләр. Халык кычкырыша. Уштан язучылар да күп булды. «Китер пычак, үземне үтерәм», – дип кычкыралар. Ә немесләргә кызык – көлешәләр, безгә карап.

Бер километр чамасы тартып алып бардылар безне. Баракка илтеп ташладылар. Көзге салкын. Бараклар озын, тактадан. Астан да буран керә, өстән дә буран керә. Монда төрле халыклар бар лагерьда. Дөнҗадагы бер милләт тә калмаган. Катын-кызлар күп, ирләр дә, картлар, бала-чагалар да. Палаталарга кешеләрне суртлап тутыралар. Кайсысына – каты раненныйлар, кайсысына – җиңелләр. Палата өч кат нарыдан тора.

1944 ел. Майданек мичләрендә яндырылган поляк, яһүд, русларның гаилә фотолары. Виктор Тёмин фотосы.

Ул нарыларга утырып торып булмый, ятып кына торасың. Бер нарыда бишәр кеше. Палатаның уртасыннан озын мич салынган. Аңа җату җук инде. Көненә өчәр-дүртәр мәртәбә немецләр проверка ясыйлар. Ул килгәндә, муеныңнан нумерыңны чыгарып күрсәтеп торасың инде. Немес сине кат-кат карап китә. Әгәр ул карап йөргәндә, берәрсе башын кирәк кадәрледән артыграк чыгарып торса, немес килә дә камчы белән мич өстенә яткызып кыйный башлый. Көненә болар бер мәртәбә 300 грамм чамасы эпи, 200–300 грамм чамасы баланда (аш) бирәләр. Я аның урынына – ярты литр кипяток.

Монда бер ай яткызгач озаттылар безне Люблинга, ул Польшада була инде. Мунча керттеләр, үзебездә булган киемнәрне алып бетереп, берсен дә калдырмаенча, трусик белән майка бирделәр. Кышкы салкында шул көе мунчадан чыккач, кар өстендә калдырдылар. Халык бик күп чирләп үлде. Баракка илткәч тә, бик күп халык кырылды. Монда да барак суык, аста-өстә юк, бөрчә күп. Бөрчәнең зарары юк, дип, аны бетерү турында уйлап та карамый немесләр. Төн җокысы җук инде ул. Без барып кергәч, безгә кадәр 48 мең иптәшне яндырганнар, дип әйттеләр, крематорий дигән мичтә. Безгә тәрәзәдән ул күренеп торадырые. Морҗалары бик хәтәр, күккә тиярлек булып тора.

Мин монда бик ябыктым, үлем чигендә калдым. Безне үлчәп тораларые. 38 килограммга калганыем. Сугышка кадәр – 66 кило. Коткарылып, Киевкә килгәч, өйгә кайтканда 64 кило-грамм булдым.

Комиссия булае, чирлеләрне аерым палатага илтеп куялар. Анда кеше чыдамый, барган һәркем үлеп кенә тора, терелэй чыгучы җук. Минем арадагы иптәшләр дә шул туберкулёзный палатада күп кенә үлделәр. Мин сугышка кадәр бик тазаем, шуңа да үлемнән калганмындыр инде.

Үзебезнекеләр килеп коткарганда, шул Майданек лагеренда булдым. Кызыл Армиянең килүен немесләр әйтмиләр, шулай да «охран» немесләрдән аңлап калдык. Алар: «Рус килеп җитә, рус килеп җитә», – дип сүләнәләр ие.

Үзебезнекеләр килер алдыннан бер көн кала, мин күреп тордым, безнең палата белән янәшә булган ничә йөзләп кер җуучы хатын-кызны крематорийга алып китеп җандырдылар. Немес шуннан соң төнлә качты. 1944 елның 22 (23) июнь төнендә үзебезнекеләр килеп безне коткарды. Шуннан соң безне туган илгә кайтардылар.



Лена Шакирҗанова (Лена Шагыйрьҗан) – шагыйрь, публицист, тәрҗемәче. «Мөлдерәмә күңел» (1982), «Ышанам йөрәгемә» (1986), «Иман әлифбасы» (1993), «Шигырьләр, поэма» (1996), «Божра вә хөҗрә» (2002), «Хуш исләре җиһан гөлләренең» (2011), «Кәрәз төбе каты бал» (2014), «Алла ярдәм бирсен сезгә, кешеләр!» (2017) һ.б. китаплар авторы.

ТР атказанган сәнгать эшлеклесе (2000), Һ.Такташ премиясе лауреаты (2007), ТРның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе иясе (2011), Татарстанның халык шагыйре (2016).

2017 елның 16 гыйнварында вафат. Кабере Күлле Киме зиратында.



«КЕШЕЛЕКЛЕ ҖӘМГЫЯТЬ ШАГЫЙРЬНЕ САКЛАРГА ТИЕШ»

Луиза Янсуар

Татар шигъриятендә XX йөз башында, яңарыш дәверендә, бер төркем хатын-кызлар пәйда була. Бөек Ватан сугышы елларыннан соң, җитлеккән, үзенчәлекле иҗаты белән ир-ат әдипләр сафына Саҗидә Сөләйманова атлый. Феноменаль күренеш буларак кабул ителә. Лена Шагыйрьҗан исә 60 нчы елларда мәйдан тоткан Фәйзуллиннар, Гаташлар, Зөлфәтләр дәверендә шулай ук әзер шагыйрь булып килә. Аңа фатиханы да тере классик Сибгат Хәким үзе бирә: «Арысланнарны бәреп еккан. Позициясе нык, ир шагыйрьләрнең хәле мөшкел».



Фотолар: Луара Шакирҗанова архивыннан алынды

18 яшь.

ШАГЫЙРЬ КЫЗЛАР

Лена апалардан соң шигърияттә инде гомумән хатын-кыз шагыйрьләр хөкем сөрә башлый. Ир-атлар, уены-чыны бергә: «Табигатьтә ата сандугачлар гына сайрый», – дип тә карый, әмма, юк, заман үзенекен итә. Анна Ахматова язып калдырган сүзләр дә бар бит: «Я научила женщин говорить...» Бу җәһәттән Лена Шагыйрьҗан да «Кызлар җыры» кебек күмәк альманахларда беренче шигырьләре күренгән дәвердә үк болай яза:

Шагыйрь кызлар, дисез, нинди була? –
Шагыйрь кызлар алар төрле була.
Карашлары тирән, серле була –
Җидесендә җитмеш төрле уй...

Лена апа үзен күбрәк Сибгат Хәким, Фатих Кәрим, Габдулла Тукай иҗатларыннан өйрәндем, аларның «халыкчан мәктәбеннән чыктым» дип нисбәтли. Халыкчан мәктәп, дисә дә, Лена Шагыйрьҗан поэзиясе эстетик затлылыгы, интеллектуаль катламнары, үзенчәлекле образлылыгы, поэтикасы белән аерылып тора. Һәм егәре, куәте, публицистик, бунтарь рухы белән дә. Каршылыклы холыклы, көрәшче рухлы булуына карамастан (ә еш кына шуны сәбәп итеп тә), Лена Шагыйрьҗанны күрмәскә тырышулар да, «читкәрәк» этеп куюлар да булмый түгел, әлбәттә. Чөнки ул еш кына «уңайсыз» була. Җитмәсә, сүз сәнгатенә куйган таләпләре дә шактый кырыс һәм компромиссыз, әдәбиятта «көнлекчелекне» өнәми. Шагыйрьнең «Сүз һәм шагыйрь» дигән эссесындагы кайбер постулатларны уку гына да җитә:

- *«Шагыйрьнең һәрбер иҗтимагый вакыйгага карата үз фикерен белдерергә, реакция ясарга ихтыяҗы да, хокукы да бар».*
- *«Шагыйрь өчен аерым фиркаләрдә тору мәҗбүри түгел. Аның төп идеологиясе – Иман. Ягъни Ирек, Мәхәббәт, Акыл, Намус».*
- *«Кешелекле җәмгыять Шагыйрьне сакларга һәм якларга тиеш. Нәкъ менә шул җәмгыятьнең җимеше булганга күрә. Шагыйрь ул бит үз җәмгыятенең санитары да... Чирләсә – диагноз куючысы».*
- *«Намус – Талантның аерылгысыз юлдашы. Затлы һәм тәҗрибәле укучы аны бик тиз сизеп ала».*

Апалы-сеңелле Лена һәм Луара әниләре Хатирә Шакирҗанова белән. Форсаттан файдаланып, быел шулай ук юбилеен билгеләгән Луара ханымны да журнал коллективы исеменнән котлыйбыз!

«ТУГАН АВЫЛЫМНЫ ПАСПОРТТАН ГЫНА БЕЛӘМ...»

«Мин туган авылсыз кеше», – дип яза бер истәлегендә Лена Шагыйрьҗан. Моңа җавапка, киресенчә, ул ике туган авыллы кеше, дип әйтергә булыр иде. Лена, гаиләдә өченче бала булып, укытучы эти-әнисе – Хатирә һәм Галимҗан Шакирҗановлар элеккеге Калинин (хәзерге Актаныш) районының Пучы авылында эшләгәндә дөньяга килә. Әтисе, сугышка да Калинин районыннан китеп, 1944 елда Ржев шәһәре янында аягы яралана, кире укытырга кайта.

Аннары гаиләне яңадан Әтнә районына чакыртып алалар. Кендек каны Актаныш туфрагында тамган булса да, Лена аны паспортындагы тамгадан гына белә. Инде олыгайгач, әлбәттә, очрашуларга кайтып йөри, аны «безнең туфрактан чыккан шагыйрә», дип каршылыйлар, зурлап, 60 яшьлек юбилеен уздыралар.

Истәлекләрендә Лена Шагыйрьҗан үзен рахит көчәйгән чорда Каенсар урманындагы санаторийга илтеп куйганнарын, эти-әнисе белән абыйларын сагынып елаганын яза: «Мин шунда елап, нервлы һәм бик сагышлы булып калганмын, күрәмсең...» Шуннан соң инде ул үзендә дөньяны ваемлый башлау барлыкка килүен, тәпи китүен искә төшерә. Хәтер дәфтәрендә балачак бишеге булачак Күлле Киме авылы калкып чыга: «Күлле Киме Мари Иленә үк терәлеп тора. Шушы авыл белән гомерлеккә бәйләнеп калачагыбызны сизгәнмен, күрәмсең, ошаттым мин аны... Бу авылда без башта мәктәп йортында яшәп тордык, аннары авыл үзәгендәге бер буш өйгә күчендек. Капкалары, ишегалды бар, чирәмлек... Кеп-кечкенә булсам да, шуның рәхәтен тойганмын...»

Хәзерге вакытта Күлле Киме музеенда, Сибгат абыйлары белән янәшә, татар сәнгатенә тормышларын багышлаган Лена Шагыйрьҗан белән Луара Шакирҗанова почмаклары да бар. Күлле Киме турында Лена Шагыйрьҗан әле мондый йөрәккә үтәрдәй юллар да калдыра:

Казан – Әтнә – Күлле Киме –
Каенсар, Көекләре...
Күп йөрдек без бу юлларда
Булып җан көекләре...

Ул – Шәхес! Шагыйрә!!! Беркая да куя алмыйсың (Берни эшли алмыйсың). Гомумән, ул населдә көчле характерлы шәхесләр. Зыялы гаиләдән чыккан интеллигент балалары.
Тәрҗемә белән дә шөгыльләнде. Дөнья әдәбиятыннан шундый үрнәкләр сайлый белә иде: нәрсәне чын, зур поэзия дип саный, шуларны зур осталык белән татар теленә тәрҗемә итә.
Равил Фәйзуллин

«Шагыйрь кызлар алар төрле була...»

Асылда, аның иҗатында эз калдырган Урта Азия, Санкт-Петербург сәяхәтләрен исәпкә алмаганда, төп гомер маршруты шушы булып калачак.

«БЕЗ ДАВЫЛГА ЮЛЫКМЫЙЧА КАЛДЫК...»

Без давылга юлыкмыйча калдык...
Давылдан соң күрдек дөньяны.
Актарылып сынган имәннәрен
Куркып карап йөрдек без аның.

1945 елның 4 июнендә, сугыш афәте узып, кешеләр яңадан «яшибез» дип сулыш алган чакта күзен ача ул дөньяга. Балачагының тагын бер зур тәэсире – Күлле Киме детдомы балалары. Төрле яктан китерелгән бу балалар холык-фигыльләре, сөйләмнәре ягыннан да төрле була. Кечкенә Лена, бер мәктәптә укып, уйнап үсеп, боларның барысын күңеленә теркәп бара. Бу балалар өчен махсус кинофильмнар китерелә, бөтен авыл нарасые шуны карый. Китапханәдәге китапларны су урынына эчәләр. Бакча һәм хуҗалык эшләре дә читтә калмый, зернотокта ашлык ташу эшендә катнашалар.

Җитеш тормыш алып барган Күлле Кимедә Шакирҗановлар гаиләсе дә муллыкка тиенә: зур хуҗалык, сугыштан соңгы елларның күтәренке рухы, авыл халкының укытучыларга булган ихтирамы, балалар өчен мөмкинлекләр... Юкка гына уллары да, кызлары да республикага билгеле, күренекле кешеләр булып үсеп җитми. Балаларга исем сайлауда да алдынгы карашлы кешеләр булуын раслап тора алар: һәр дүртесенә дә елга исемнәрен бирәләр – Амур, Нил, Лена, Луара... Егетләр техник, фәнни юнәлешне сайласа, Лена белән Луара иҗатка тартыла.

«Концерт куюлар исә бездән башка гомумән булмый иде. Үзебез программа төзибез, үзебез чатнатып шигырь сөйлибез, тыпырдатып биибез, сагышлы мәхәббәт җырларын сузабыз. Безне «әртистләр» дип йөртәләр иде. Клубка Казаннан еш кына язучылар, шагыйрьләр, театр, филармониядән артистлар килә... Без бик актив идек...» – дип искә ала бу чакларны Лена апа.

Алар әле берничә ел Түбән Көеккә күчеп тә яшәп алалар. Лена рус теле укытучысы Нәкыя Фәттахованың бәрәкәтле йогынтысын кичерә, ул җитәкләгән музыка мәктәбенә йөри, мандолинада уйнарга өйрәнә. Озын гомер яшәгән бу мөгаллим апасы – Президент Аппараты җитәкчесе Әсгать Сәфәровның энисе.

Ничек кенә имин тормышлы еллар булса да, соңрак Лена Шагыйрьҗан поэзиясендә сугыш чоры фаҗигаләрен дә, гаиләсе язмышын да киңрәк итеп, драматик аргы ягын «каплап куймыйча» сурәтли. Моңарчы бер генә шагыйрь-язучы да күрсәтмәгән фокус аша бирә:

Дәрес бара... Немец теле дәресе.
Ипи-тозлык кына булса да,
Сузләр ятлый авыл балалары...
Программада – аш-су исемнәре:
Бутербродлар, әллә нәрсәләр...
Балаларның эчен бора ачлык,
Исемен генә укып әйтсә дә.
...Әни сөйләгәндә, мин еладым...

Дөньяның тәгълимат-кануннарының күпкә катлаулы икәнен Лена Шагыйрьҗан яшьлек чоры шигырьләрендә үк әйтеп бирә. «Әткәм немец белән сугышып кайткан, әнием немец теле өйрәткән», – дип тәмамлана аның ул шигыре. Ә икенче берсендә ул өйләрендәге чөйдә эленеп торган иске (әткәсенең Бөек Ватан сугышыннан киеп кайткан) һәм яңа гына энә белән җептән төшкән (яңа армиягә алынган күрше егетенең) шинельләрне чагыштыру аша, шулай ук чорга һәм киләсе буыннарга кисәтү ясый:

Лена Шакирҗанова – ТР Дәүләт Җыр һәм бию ансамбле солисткасы.

Ике шинель, чөйдә безнең өйдә.
Берсе тузган, зур юл узган... берсе – яңа...
Утны-суны кичеп кайткан карт шинельнең
Әйтәсе бер изге сүзе бар күк аңа...

Сибгат агасы, Җәлил, Кәримнәрнең язмышларын да кадерләргә омтылу бар бу юлларда.

Ленаны беренче тапкыр күрүем Бауман урамында булды. «Бу нинди чибәр ханым?» – дип сорадым. Ахматова чорыннан төшкән дама кебек бара. Гомер буе шулай затлы, матур киенде. Зәвыгы шәп иде. Лена – хатын-кызлардан иң зур шагыйрәләрнең берсе. Ул исемен дә юкка гына Шагыйрьҗан дип үзгәртмәде. Чын шагыйрь икәнен белгәнгә үзгәртте.
Табыннарда утырганда, Илһам Шакиров булса, Ленаны җырлатмый калмый иде. «Мин болай җырлый алмыйм», – дип әйтәдерие. Лена Илһам Шакиров янында җырларга җөрьәт итә торган бердәнбер кеше булгандыр...

Марсель Галиев

«ИХ! БАШЛЫЙСЫ ИДЕ ӨР-ЯҢАДАН...»

Их! Башлыйсы иде өр-яңадан,
Ап-ак сөттән – иң гөнаһсыз чактан...
Туен көткән керсез ак күлмәктән,
Ак ефәкләр белән ак калфактан!

Мәктәпне тәмамлагач, Казан педагогика институтының тарих-филология факультетына укырга керә Лена. Әтисе физика-математика юнәлешен сайларга тәкъдим итеп карый, югыйсә кызының аттестатында бу фәннәрдән дә билгеләр ялт иткән. Әмма Лена күңеленең сәнгатькә тартылуын сиземли, бер әңгәмәсендә әйткәнчә, бу карарында «үҗәтлек», «мөстәкыйльлек» күрсәтә.

Институттан соң, Казанның 80 нче мәктәбендә укытучы булып эшли. 1968 елда Татарстан Дәүләт җыр һәм бию ансамбленә вокалистка булып урнаша. Бу еллар, милли мирас, фольклор белән эшләү аның иҗатына да, шәхесенә дә гаять зур йогынты ясый. Аннан соң, 1974–1987 елларда, Татарстан радиокомитетында журналист-тәрҗемәче булып эшләгәндә, сәнгатьнең нәкъ уртасында кайный.

1982 елда, ниһаять, беренче җыентыгы – «Мөлдерәмә күңел» дөнья күрә. Уч төбенә сыеп бетәрдәй бу китапчык әдәбиятка үз әйтер сүзе, позициясе, эстетикасы булган шагыйрь аяк атлавын хәбәр итә. Лена Шагыйрьҗанны 1984 елда Татарстан Язучылар берлегенә кабул итәләр. 1986 елда «Ышанам йөрәгемә» дигән икенче җыентыгы басылып чыга. 1987 елдан ул язучылык белән профессиональ рәвештә шөгыльләнүгә күчә.

Милли-азатлык хәрәкәте иң югары ноктасына җиткән, суверенитет җилләре искән еллар – Лена Шагыйрьҗан поэзиясенең дә иң апогее. Бу чорда аның шигъриятендә милли темалар белән беррәттән, гражданлык позициясе көчәя, публицистик башлангыч зур эпик формаларга алып чыга, баллада, поэма жанрларында уңышлы табышларга китерә. Шагыйрь төрки мөнәҗәтләр, бәетләр кебек форматларны үзләштереп, аларга чор сулышын өрә.

Тәрҗемәдә дә төрки-татар шигъриятенә, милли эпосларга мөрәҗәгать итә: Йосыф Баласагунлы, «Сәят Нәва» һ.б. Берүк вакытта Лена Шагыйрьҗан үз шигъриятенең олы бер дөнья әдәбияты өлеше булуын да онытмый. Асылда, каләм әһелләренә карата куйган кырыс позицияне – «без дөнья таный һәм соклана алырдай әдәбият тудыручылар булырга тиеш» дигән позицияне алга сөрә ул. Сатирик башлангыч, абсурд поэзиясе алымнары аша милли күтәрелештә кульминациягә җиткәндә генә, кабат үз-үзенә аяк чалган, «борынгыдан калган хатасын кабатлаган» милләтенә әрнеп эндәшә. Әйтергә кирәк, күп нәрсәләрне алдан да күрә:

Имеш, хәзер шигырь яратмыйлар,
Кирәк түгел шигырь, янәсе.
Шигырьнең дә, шагыйрьнең дә, имеш,
Арзанайган, төшкән бәясе.
Рухи инфляция – шигъриятнең
Гаебе түгел юкса, бәласе...
Җыр кадерен белгән затлар кайда?
Кемнәр куя шигырь бәясен?

Яңа дәвернең тел, сәнгатьтән йөз борып, башка якка таба юл ала баруын да тоеп кисәтә ул, алыпсатарлык, акча-кәсепчелекнең, ярак-

Лена Шагыйрьҗан – Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты.

Әтисе Галимҗан агай белән.

Камал театрының атаклы директоры Шамил Закиров һәм сеңлесе Луара Шакирҗанова белән.

Кәрим Тинчурин театрында 50 яшьлек юбилей тантанасында.

лашуның, бердәм була алмауның һичшиксез милләтне таркатуга китерәчәгенә дә диагноз куя:

Чакырып тора кайтыр юллар,
Көтмәсә дә такыр юллар...
Оча тора, китә тора
Милли, милли миллионнар...

Нуленче елларда язган әсәрләрендә, ягъни иҗатының соңгы дәверендә, язмышын тулаем әдәбиятка багышлаган Лена Шагыйрьҗан, визионерларча, кешелекнең яңа фаҗигаләрен дә искәртеп куя. Әдәби мохиттә зур резонанс уяткан «Дөнья базары, яхуд Яңа Америка фаҗигасе» (2001), «Галәм кисәтүе» (2006) поэма-аллегорияләрендә киләчәктә милләтләрнең, телләрнең зур бер геосәясәт өермәсендә эреп югаласын, кешелекне ясалма аң алыштырасын... тагын бик күп нәрсәләрне сөйли.

P.S. Тагын бер мәртәбә «ИМАН кодексы»на әйләнеп кайтыйк: ничек ди әле ул анда, шагыйрь җәмгыятьнең санитары да, чирләсә, диагноз куючысы да, диме? Минә ни өчен чын шагыйрьләрне ешрак укырга кирәк дип, һич шикләнмичә әйтәсем килә. Һәрхәлдә, гомергә бер булса да.

СЕРЛЕ ЭЗЛӘР БУЙЛАП, ҮЗЕБЕЗНЕ ЭЗЛӘП...

МӘҢГЕГӘ ҖУЕЛГАН ДӨНЬЯЛАР

ДАНИЭЛЬ ШПЕК, «ЙОГА ТАУН» 18+

«Фантом Пресс» нәшрияты, 2025



Немец язучысы, драматург һәм сценарист Даниэль Шпек безгә моңа кадәр дә үзенчәлекле романнары белән таныш иде. Беренче әсәре – «Bella Германия» – Европада 2016 елда иң шәп дебют китап дип табылды, аны Россия укучысы да бик яратты. Зур гаилә сагалары рухындагы икенче әсәрен 2018 елда укучыга тәкъдим итте – «Piccola Сицилия» озак вакыт бестселлерлар исемлегеннән төшмәде. «Дорога на Яффо» – өченче романы да нәкъ шулай.

Һәм менә 2025 елда Шпек өр-яңа һәм моңа кадәр иҗат иткән әсәрләреннән бераз аерылып тора торган китабын дөньяга чыгарды. Әйтергә кирәк, бу китабында – бөтенләй үзгә колорит.

Көннәрдән бер көнне йога укытучысы Люсиның Берлиндагы студиясенә Лоу – кан ягыннан үзенеке булмаса да, аны тәрбияләп үстергән этисе килеп керә һәм зур дулкынлану белән әнисенең юкка чыгуын хәбәр итә. Коринна – атаклы тележурналист, медиайолдыз һәм күптән инде алардан аерым тормыш белән яшәүче кеше булса да, бу өчәүне күзгә күренмәс җепләр бәйләп тора. 1960-70 нче еллар рок-мохите атмосферасында торып калган, хәзерге көндә дә рок-инструментлар һәм чор музыкасы буенча гаҗәеп белгеч булып саналган Лоу бу җепнең кая барып тоташканын белә, билгеле, әмма баштарак яшерергә теләми. Чөнки барысы да бу теманы инде күптән уратып уза, дистә еллар дәвамында кузгатмый...

Әмма Люсиның эзләнүләре икесенең дә шикләре дөрес булуын раслый: Коринна

> «ЙОГА ТАУН» АНЫҢ ЯРАТКАН ТЕМАЛАРЫ – ХӘТЕР ҺӘМ БУЫННАР АРАСЫНДАГЫ ЧЫЛБЫР ТУРЫНДА БУЛСА ДА, БУ ЮЛЫ УЛ ТУЛАЕМ «ГАИЛӘ САГАСЫ» ФОРМАТЫННАН ЧИТЛӘШӘ ТӨШӘ. БЕЗНЕ ДӘ ИКЕНЧЕРӘК ЛЕЙТМОТИВКА КӨЙЛИ.

үзенең психоаналитигына соңгы җибәргән открытка адресы: Һиндстан, изге шәһәр Ришикеш. Бу хәбәрдән тетрәнгән ата белән кызга бары тик бер юл гына кала – алар беркайчан да әйләнеп кайтмаска дип ант иткән үткәннең күзенә туп-туры карап юлга чыгарга һәм, Коринначы табып, аның ул дәвергә нигә кабат әйләнеп кайтканын ачыкларга.

1960 нчы елларда хиппиларның дөньякүләм башкаласы исәпләнгән Ришикеш – гуру Махариши ашрамы. Әсәрнең сюжеты буенча, биредә Лоу үзенең тумышлый ук ятим калган энесе Марк һәм сөйгән кызы Мария белән килә. Юлда алар Коринна белән танышалар. Хиппи сәфәрендә атаклы «Битлз» төркеме белән очрашып, ашрамда берара яшиләр, рухи практикаларны үзләштерәләр. Әмма сәфәр фаҗига белән тәмамлана.

«Йога Таун» – Икенче бөтендөнья сугышы ярасы һәм гаеп тойгысы белән яшәгән, үз-үзен эчтән ашаган Лоу белән Маркның этиләре йортыннан, немец тормышының, үзләре әйткәнчә, буа торган тынчуыннан «оҗмах вәгъдә итә торган иреккә» чыгып качу тарихы ул. Әмма бу яшь буын да барыбер гаеп тойгысыннан азат түгел: Рейх вакыйгалары – үткәндә, ләкин Вьетнам дөрли... Алар Вьетнам иттарткычын туктата алмаулары, дөньяның тагын хаоска тәгәрәве өчен бимазаланалар, үзләрен гаепле хис итәләр. «Битлз» төркеменең кыюлыгына сокланалар, тора-бара моның да бик шикле кыюлык, күбрәк үзреклама икәнлегенә инана башлыйлар...

Бүгенге күзлектән укыганда, «Йога Таун» гаҗәеп тыгыз, җете төсләрдән тукылган атмосферасы һәм беркатлы, самими, ирекле серлелеге белән җәлеп итә. Без инде ул дөньяның мәңгегә җуелган икәнен бар тирәнлеге белән тоябыз, һәм үзебезнең карашыбызга да сагынулы, җылы бер елмаю җәелүен абайлап алабыз. Шпек безгә ностальгия белән берррәттән хәтер фәлсәфәсен дә бүләк итә.

> Башта без тамырларны кубарып алыр өчен бар көчебезне куябыз, ә аннан, ник соң без шулкадәр каңгырап йөрергә дучар ителгән затлар, дип, сагышланабыз.
> **Даниэль Шпек, «Йога Таун»**

Фото: goodfon.ru, livelib.ru

Луиза Янсуар

Июль аенда укыр өчен 2025 елның ике бик тә колоритлы романын сайлап алдык. Берсе экзотик илләргә һәм үткәндә калган ностальгияле чорларга эндәшсә, икенчесе борынгыдан килгән риваятьләргә бай Алтай мистикасы һәм заман чынбарлыгы белән күзгә-күз очраштырыр.

«АЛТАЙ ГОТИКАСЫ»

КАРИНА ШАИНЯН, «САСПЫГА» 18+

АСТ, «Елена Шубина редакциясе», 2025

КЕШЕ ЙӨРГӘН БАРЛЫК СУКМАКЛАР ДА БАШТА ҖАНВАРЛАРНЫКЫ БУЛГАН.
Карина Шаинян, «Саспыга»

Ялгызы гына монда теләсә кем акылдан яза. Баш мие ышанычлы нәрсә түгел. «Чалулый», үзен төзәтәсе урынга, башкаларга «ябышып» эш итә. Аңа исәп ноктасы кирәк. Монда хәзер исәп ноктасы юк, үтә күренмәле, кул белән «тотып» булмый торган элпә генә. Бүтән берегер ноктасы калмагач, ми өзлексез сүз боткасы тудыруыннан туктарга мәҗбүр. Аннары психик бушлыкта эленеп каласың. Шәхесең, кешелек сыйфатларың шушы тауларга, угычка эләккәндәй, кырып уыла. Кем икәнеңне бөтенләй абайламый башлыйсың.
Карина Шаинян, «Саспыга»

Карина Шаинян 1976 елда Грозный шәһәрендә геологлар гаиләсендә туа. Балачак һәм үсмер еллары Сахалинның төньягындагы Оха шәһәрендә уза. Нәселләре берничә буын геологлар, үзе балачактан табигать белән кошларны өйрәнә, тик һөнәре итеп психологияне сайлый. Социаль психология буенча Ломоносов исемендәге Мәскәү дәүләт университетының психология факультетын тәмамлый. Мәктәптә психолог булып эшләп ала. Соңрак ВГИКта сценарий язу осталыгын үзләштерә, берара журналистика белән шөгыльләнә. Геологлар партиясе белән Сахалинның иң чик ноктасына походларга чыга, 20 елдан артык Таулы Алтайда инструктор буларак атлы походлар йөртә.

2010 елда «Долгий путь на Бимини» фантастик әсәре белән дебют ясый. Шуннан соң, аның «Мраморный фавн», «Игра», «Че Гевара», «С ключом на шее» һ.б. әсәрләре басылып чыкты. Ул – фантастика өлкәсендә берничә премия лауреаты. 2022 елда «Национальный бестселлер» премиясе исемлегенә эләкте, «Иң яхшы кинопитчинг» номинациясендә җиңү яулады. Иҗатында яңа казаныш булган «Саспыга» исә нәширләр өчен дә, китап сөючеләр өчен дә бөтенләй көтелмәгән бүләк булды.

Әсәрдә вакыйгалар безнең заманда бара. Алтайның «Кайчи» исемле ат базасына, ун көнлек походтан соң, туристлар төркеме кайтып төшә. Шунда артык күзгә ташланмый торганрак бер кызның – Асяның югалуы ачыклана. Ася эзе буйлап чыкканда, шунысы да билгеле була – юк, ул адашып калмаган, ә махсус кеше аяк басмаган чытырманнарга таба юл алган икән... Менә шушыннан без әсәрнең икенче планына аяк басабыз. «Саспыга» – гаҗәеп дәрәҗәдә детальле, хәтта ки гиперреалистик әсәр, бер үк вакытта, ул безнең иң тирән аң төпкелләренә төшү куәтенә дә ия. Ә анда төшкәч, һәркемнең – үз упкыннары.

Асылда Шаинян бөтенләй мистик булмаган тема һәм проблемалар территориясенә чакыра. Бу кыргый, борынгы җирләрдә яшәүче кешеләрнең аны кадерли, саклый алмавы, йончыганлыгы, акча өчен намусларын сатуы, онытылырга теләве, күп нәрсәгә күз йомуы, яхшы тормышка ымсынуы... Ә янәшәдә генә, шулай ук ымсындырып, сәер дә, әкәмәт тә бер җан иясе йөри: ни кош түгел, ни җанвар. Менә шул «саспыга»ның итен авыз итсәң, бөтен газаплар, борчулар, йөдәүләр юкка чыга икән...

Язучыны тормыштагы урыныңны белү белән эчке тотрыксызлык, көчсезлек кызыксындыра. Ике чиктә калганда, кеше нәрсәне сайлый – кыю булып, куркулары күзенә турый карый аламы ул, әллә исе белән тәме акылдан яздырырдай «саспыга» хакына үзеннән ваз кичәргә дә әзерме?

«Карина Шаинян «Алтай готикасына» нигез салды», – ди әдәбият белгечләре. Ул җирләрнең мифына һәм кабатланмас аутентик рухына орынырга чакыра, кыздырып тора:

– Төп максатым – һәркемне Алтайга китерү һәм тауларга алып менү, – ди ул.

– Саспыгага корбан булыр өченме? – дип көлешә укучылары.

– Чын могҗизага гашыйк итәр өчен, – дип елмая Шаинян.

Чынлап та, бу әсәрдән соң үзеңне яңадан тугандай хис итә аласың.

ҮЗЕБЕЗНЕҢ ТЫМЫТЫК

ТЫМЫТЫК

Фото: Лилиана Вәлитова

Картада ике Тымытык авылы күрсәтелгән. Икесе дә Ык елгасы буенда җәелеп утырган. Картаны зурайтыбрак карагач, аңлашыла: авылларның берсе – Татарстанга, икенчесе Башкортстан Республикасына карый. Ык елгасы өстенә салынган бер бәләкәй күпер аерып тора үзләрен. Әлбәттә, без Азнакай районындагы Тымытык авылына юл тоттык.

Руфия Фазылова

МӘДӘНИЯТ ЙОРТЫНА РЕМОНТ КИРӘК

Тарихлы, атаклы авыл бу. 1937–1958 елларда Тымытык район үзәге булып торган. Бердәнбер урта мәктәп тә бирәдә эшләгән. 1958 елда Тымытык районы бетерелеп, авылны Азнакай районына кушалар. Шуңа да карамастан, ул элеккечә зур авыл булып кала.

Бүген дә бирәдә 1197 кеше яши, 737 хуҗалык бар. Районның иң зур саласы ул. Совет чорында авылда зур гына хастаханә эшләгән. Катлаулы операцияләргә кадәр ясалган. Дөрес, Тымытыкта әле дә көндезге амбулатория бүлеге эшли. Халык бирәдә кан анализлары тапшыра, беренчел тикшеренүләрне уза. Агач эшкәртү комбинаты, тегү цехы, пекарня – болары да заман җилләренә каршы тора алмаган. Аларны халык бүген дә сагынып искә ала.

Урта мәктәп исә дәрәҗәсен югалтмаган. Әлбәттә, анда элеккеге кебек 800 бала укымый, укучылар саны бүген 150 гә калган. Тик, килешәсездер, хәзерге авыл мәктәпләре өчен начар сан түгел бу. Мәдәният йорты да гөрләп эшләп тора. Шундый зур мәдәният үзәге эчтән бик таушалган – шунысы кәефне кырды. Кечкенә генә авылларда да әллә нинди заманча, матур мәдәният йортлары күрәбез. Ә монда, дөресен әйтим, аптырашта калдык!

– Тышын матурладылар, якын арада эченә дә ремонт булыр дип көтәбез, – диде Тымытык мәдәният йорты режиссёры Лилия Мостафина.

– Районда иң «өлкән» мәдәният йорты безнеке. Тышын матурладылар, якын арада эченә дә ремонт булыр дип көтәбез, – диде Тымытык мәдәният йорты режиссёры Лилия Мостафина. – Авыл зур, көндез дә, кичен дә кеше килә. Халык театры статусын йөрткән труппабыз бар, балалар өчен аерым театр түгәрәге эшли. Район күләмендә узган театр фестивальләрендә һәрчак призлы урыннар алабыз. Кеше күп булгач, эшләргә күңелле. Бөтен бәйрәмгә концертлар әзерлибез. Яше, карты – барысы да бик актив бездә. Кайбер авылларда сәхнәгә чыгарырга кеше таба алмыйлар, бездә андый проблема юк, шөкер. Авылдашларга зур рәхмәт!

«БАЛ КОРТЛАРЫ» РАЙОНДА БЕР ГЕНӘ!

Мәдәният йортында сөендергән, хәтта ки гаҗәпләндергән тагын бер күренешкә тап булдык – авыл апалары, берләшеп, «Бал кортлары» волонтёрлар оешмасы булдырган. Дүшәмбедән пәнҗешәмбегә кадәр алар көн саен дүрт сәгатькә мәдәният йортына киләләр.

– Безнең авылдан гына да егерме бер кеше махсус хәрби операция зонасына китте, – диде волонтёрлар җитәкчесе Люция Шәйгарданова. – Ни аяныч, арада һәлак булучылар да бар. Бер-бер артлы егетләребез мобилизацияләнә башлагач, аларга ярдәм булсын дип, бармакчалы бияләйләр бәйли башладык. Аннан соң йон оеклар бәйләүгә күчтек. Авылдашлар җеп алу өчен акча бирә башладылар, үзебездән дә куштык. Ул арада Азнакайда махсус бер төркем оешты, алар, күпләп җеп алып кайтып, безгә дә тараттылар. Шулай берсендә сыйныфташым Тәслия солдатларга маскировка киеме тегеп карарга тәкъдим итте, кызлар күтәреп алды. Нәтиҗәдә, бер дигән костюмнар килеп чыкты. Эскизын үзебез эшләдек, бу фәкать без уйлап тапкан кием.

Бу урында шуны әйтергә кирәк: «Бал кортлары» волонтёрлары арасында профессиональ тегүчеләр шактый. (Тымытыкта атаклы тегү цехы булган, апаларның күбесе шунда хезмәт куйган. – Авт.) Нәтиҗәдә, волонтёрлар төркеме солдатлар өчен эчке киемнәр, күлмәк-чалбарлар, тагын башка кирәк-яраклар тегә башлый. Бүген алар хәрби ялга кайткан авылдашларына да, МХО зонасына гуманитар ярдәм белән баручылар артыннан күпләп кием-салым, үрелгән челтәрләр җибәрәләр.

– Киндер капчыклар, тәрәзә челтәрләре, иске кием-салым – барысын да шкаф, сандыклардан чыгардык, – дип дәвам итте Люция апа. – Аларны чимал итеп алдык. Хәзер инде интернет-кибетләргә заказ бирәбез. Безнең эшне күреп, авылдашлар да кушылды – тукыма, чимал алырга акча җыя башладылар. Хәйрия концертлары да оештырдылар. Хәтта күрше авыллар да акча җыеп китереп бирде. Һәр тиенне санап, авылдашлар алдында хисап ясап барабыз.

2022 елның октябрендә ике-өч кеше шулай бияләйләр бәйли башлаган булса, бүген Тымытыкның «Бал кортлары» волонтёрлары егермегә якынлашып килә. Унөч хатын-кыз янына дүрт ир-ат та өстәлгән. Монда эш һәркайсына җитә: кемдер тукыма кисә, кемдер машинада тегә, икенчеләр өчкә алты зурлыктагы челтәр үрә. (Һәр көнне берне әзерлиләр). Соңгы вакытта дрон һөҗүменнән саклау өчен дә ятьмә үрә башлаганнар. Кыскасы, монда тулы бер цех... Нәтиҗәдә, «Бал кортлары» волонтёрлар оешмасын районда гына түгел, бөтен

Россиядә беләләр. Төрле часть командирларыннан аларга рәхмәт хатлары килә, медальләр җибәрәләр. Аңлашыла, бу апалар, абыйлар медаль дип эшләми, аларның максаты – яу кырында булган егетләрнең хәлен мөмкин кадәр җиңеләйтү. Чит балалар булмый бит, алар һәркайсы – кемнеңдер газизе...

Тымытык волонтёрлары арасында уллары МХО зонасында булган аналар да эшли. Үзләре әйтүенчә, биредә хәсрәтләрен онытып торалар, үзләренең ялгыз түгеллеген аңлыйлар. Әнә шул әниләрнең берсе – Нәфисә Заһидуллина белән аралашып алдык:

– Улым Ринат МХО зонасына үзе теләп китте. Югары белемле табиб ул, КДМУ тәмамлады. Ике ел элек кайтты да: «Әни, мин китәм, анда күпме яралы солдат. Көнгә бер генә солдатны үлемнән алып калсам да, зур батырлык эшләгән булам», – диде. Әлбәттә, башта бик борчылдым. Аннары ияләнәсең икән. Көн дә догада инде. Башта Ринат алгы сызыкта иде, хәзер кыр госпитальендә эшли. Әле менә ялга кайтырга тиеш, бик көтәбез үзен. Аннан бигрәк сугышның тәмамлануын көтәбез. Барыбызның да балалары исән-имин туган якларына әйләнеп кайтсын иде...

Авыл апалары, берләшеп, «Бал кортлары» волонтёрлар оешмасы булдырган.

Равил Мөхәммәдиевнең унбиш еллап инде күрәккә орынганы юк икән.

УТЫРТА, ТӨБЕН ӨЯ, АЛА...

Равил Мөхәммәдиев ясаган мини-трактор турында бер җөмлә белән әнә шулай дип әйтеп була. Равил абыйның унбиш еллап инде көрәккә орынганы юк икән. Әле үзенә генә түгел, туганнары, күршеләре, авылдашларына да бәрәңге утырта. Аннан, барып, төбен өя, көзгә бәрәңгене алып та бирә.

– TZ-4K-14 – элеккеге чех тракторын яңадан үзгәртеп җыйдым, – диде Равил абый. – Бәрәңгенең сабагын да шушы трактор белән чабам, бик ваклап җиргә сиптереп бара. Гадәттә, бу эшне бәрәңге алганчы бер атна алдан эшлим. Нәтиҗәдә, сабак кибеп, җирдә черемә булып кала. Казыганда да трактор белән алган бәрәңгене чүплисе бик җиңел: ул аның туфрагын коеп, җиргә чәчеп бара.

Равил абый быел егерме алты бакчага бәрәңге утырткан. Утырту гына түгел, кумү, сабын чабу, алу эшләре – бер башлагач, азакка кадәр дәвам итә. Алдагы елларда уналты, унҗиде гаиләгә бәрәңге утыртса, быел теләк белдерүчеләр арткан.

– Аның инде акчасын да сорап алмыйм, дуслар, авылдашлар бит, – диде Равил абый. – Болай кешегә йөрермен дип тә башлаган эш түгел. Берсеннән берсе күреп, әнә шулай даным тарала. (Көлә. – Авт.)

Равил абый ихатасына чакырды. Үзенчәлекле тракторын кабызып, бәрәңге төбен өеп тә күрсәтте. Кул хезмәте бөтенләй юк монда, барысын да техника үзе эшли. Дөресен әйткәндә, мондый техниканы беренче тапкыр күрдем.

– Бу TZ-4K-14 тракторы, 1993 елгы. Аны колхоздан 29 мең сумга, дөресрәге, бартер юлы белән эти алды. Заманасына күрә бик яхшы техника иде, хәзерге мотоблоклар кебек. Ләкин ул күпкә яхшырак, чөнки аны күтәреп йөрергә кирәк түгел. Хуҗалыкта нык булышты безгә. Хәзергәчә – сафта! Дөрес, алты ел элек моторын алмаштырдык. Күршедә Фәрит исемле егет яши, техниканы яхшы белә. Гел ярдәм итә.

– Бу әллә ничә төрле җайланманы тракторга беркетергә дә кирәк бит. Аларны каян уйлап таптыгыз? – дим.

– Аның зур авырлыгы юк инде, интернетта хәзер барысына да өйрәтәләр. Озак еллар эретеп ябыштыручы булып хезмәт куйдым, тәҗрибә зур. Һәр детальне үзем ясадым. Андый эшләрне бик яратам.

Равил абый тимер капка, коймалар, башка кирәк-яраклар да ясый. Эшкә дә чакырып торалар үзен. Ул арада волонтёрлык эшенә дә вакыт таба: бер-ике авылдашы

белән МХО зонасына тимер «буржуйка» мичләре ясап җибәргәннәр.

«КҮП КАЛМАДЫ ЙӨЗГӘ ДӘ...»

Тымытыкның аксакалы белән дә таныштык – Миңнегәрәй Миңнегалиев. Бабай 98 яшен тутырган. Гомер буе туган авылында яшәп, аның киләчәге матур итү өчен хезмәт куйган. 1962–1987 елларда данлыклы Тымытык урта мәктәбенең директоры булган. Бүген исә кызы Фәридә тәрбиясендә, кадерле әти булып яши. Гомер иткән карчыгы Дөрия апа җиде ел элек бакыйлыкка күчкән.

Миңнегәрәй абый катлаулы да, бәхетле дә гомер юлы узган. Үсмер чоры Бөек Ватан сугышы елларына туры килгән. Өч абыйсын сугышка озатканнан соң, бөтен зурлар эшен үз җилкәсенә алган.

– Тымытыктан Бөек Ватан сугышына 600 дән артык кеше китте, – дип, истәлекләрен барлады Миңнегәрәй абый. – Шуның яртысыннан артыгы кире әйләнеп кайтмады. Үземнең дә ике абыем 1942 елда госпитальдә вафат булганнар. Өченче абыйның да үлгән хәбәре килгән иде. Бәхеткә, ул могҗиза белән исән калган һәм авылга да әйләнеп кайту бәхетенә иреште. 1923 елгы иде ул, Сәхәбетдин исемле.

– Сәхәбетдин абыегыз ничек исән калган? – дим.

– Ике ай госпитальдә аңсыз яткан, аннары тернәкләнеп киткән. Шуннан соң аның авылга хаты килде. И, әти белән әнинең сөенгәннәре! Барлыгы унбер бала идек без, мин – дүртенчесе. Миннән алда – өч малай.

Әнә шуларның барысы да үлеп бетте, дип, әти белән әни бик кайгырды. Абыйның хатын укыгач, сеңелләр дә, мин дә шатлыктан елаштык. Госпитальдән Сәхәбетдин абыйны яңадан фронтка җибәргәннәр. Бөек Җиңүне Венгриядә каршы алган ул. Аннары инде туган якларга әйләнеп кайтты. Дөрес, мин ул вакытта армиядә идем, без өч елдан соң гына очраштык.

Миңнегәрәй абый 1944 елны Тымытык урта мәктәбен тәмамлый. Аннан соң фронтка әзерлек курсларына җибәрәләр. 1945 елны аны хәрби хезмәткә чакыралар: Германиягә чик сакчысы булып китә. Соңрак командир ярдәмчесе итеп куялар. Әнә шулай, ил алдында өч ел бурычын үтәгәннән соң, Миңнегәрәй яңадан туган ягына әйләнеп кайта. Шунысын да әйтергә кирәк: Германиядә хезмәт иткәндә яхшы гына хезмәт хакы түлиләр. Авылга ул, баемаса да, ипи-тозлык акча белән кайта.

– Кайткач, мине комсомол райкомына эшкә алдылар, – ди Миңнегәрәй абый. – Аннан үзебезнең «Авангард» колхозына партоешма секретаре итеп җибәрделәр. Ләкин күңелдә гел бер уй иде: укымыйча калам! Бер ел эшләгәннән соң, Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетына документларымны тапшырдым. Имтиханнар биргәннән соң, деканатка чакырдылар. «Синең аттестатка мөһер сугылмаган, әгәр иртәгәгә кадәр булмаса, төшеп каласың», – диләр. Университеттан чыктым. Нишләргә? Азнакайга бер тәүлек эчендә кайтып килеп булмый. Шунда кылт кына искә төште: Казанда РОНО мөдирләре җыелышы булырга тиеш, киттем министрлыкка. Вахтада утыручы апалардан сораштым, җыелыш икән. Шулай итеп РОНО җитәкчеләре чыкканын көттем.



Тымытыкның аксакалы – Миңнегәрәй Миңнегалиев. Бабай 98 яшен тутырган.

Азнакайның РОНО мөдире Хәкимов фамилияле кеше иде. Янына барып, хәлне аңлаттым. Ул тиз генә мөһер сугып та бирде. Шуннан очтым инде университетка! Менә шулай студент булдым. Дүрт ел көндезге бүлектә белем алдым. Диплом алганнан соң, Урсай мәктәбенә эшкә кайттым. Бер елдан, 1962 елда, Тымытык мәктәбенә директор итеп куйдылар. Алты йөздән артык бала, күрше авыллардан, Башкортстаннан да килеп укыйлар иде. Алар инде интернатта торды. Укучыларның тамакларын кайгыртырга, коллективны да җыярга кирәк иде. Әмма сынатмадык – безнең мәктәп районда гел алдынгылар рәтендә булды.

Миңнегәрәй абый мәрхүм җәмәгате Дөрия белән ике кыз, бер малай тәрбияләп үстергән. Аларның барысы да Азнакайда төпләнеп калган. Атна саен кайтып йөргәннәр, хәзер дә шулай. Аксакал бабай бүген дә күзлексез газета-журналлар укый, тавык-чебешләрне карый, мунчасын яга. Дөрес, соңгы елларда колакка катыланган.

– Әти белән әни безгә гел үрнәк булды, – диде Фәридә апа. – Әниебез дә мәктәптә татар теле, әдәбияты укытты. Аларның безгә тавыш күтәргәнен хәтерләмим. Хәзер оныкларны әрли башласак: «Тыныч кына, тавыш күтәрми генә аңлатыгыз», – дип, безгә кисәтү ясый.

ТАЛАНТЛАР АВЫЛЫ

Тымытыкта үз эшен башлаучылар күп, 30 кеше шәхси эшмәкәр булып теркәлгән. Унике гаилә КФХ булып эшли. Үзе өчен биш, җиде баш терлек асраучылар да күп. Болар барысы да халыкның тырышлыгы турында сөйли.

Тагын Тымытык талантларга да бай. Өч йортның берсендә тегү осталары яши, бәйләү, чигү, дисеңме...

Тымытык мәдәният йортының вокаль-инструменталь ансамбле җитәкчесе Рамил Шакирҗанов та күпкырлы талант иясе. Беренчедән, берничә төрле уен коралында уйный: баян, гитара, бәрмә барабаннар, курай, синтезатор, кубыз. Шулай ук көйләр яза, аерым җырлары зур сәхнәләрдән дә яңгырый икән. Икенчедән, Рамил абый үзенчәлекле картиналар ясый. Аларның һәркайсы турында бик яратып, тәмләп сөйли ул:

– Әти тальян гармунда бик матур уйный иде, мине дә өйрәтте. Алтынчы класста укыганда баян алып бирделәр. Музыка дөньясына чынлап гашыйк булу шуннан башлангандыр. Алабуга агарту училищесын тәмамладым. Бүген төп эшем – балаларны уен коралларында уйнарга өйрәтү. Кечкенәләр, зурраклар – ике ансамбль бездә. Дәресләр беткәч, мәдәният йортына киләләр. Барлыгы уналты бала йөри. Ә картиналарга килгәндә, төрле

Тымытык мәдәният йортының вокаль-инструменталь ансамбле җитәкчесе Рамил Шакирҗанов кызы Лилия Мостафина белән.

Люция һәм Илһам Шәйгардановлар дүрт ул, бер кыз үстергән.

туры килми. Илһам малайларны кечкенәдән хоккейга өйрәтте, өй каршына боз катырып, кышы буе урамда булдылар. Нәтиҗәдә, малайларның барысы да оста уйный. Республика ярышларында призлы урыннар алып кайттылар. Өченче улыбыз Риммир Азнакайда хоккей буенча тренер, балалар белән эшли.

...Әлбәттә, санаулы вакыт эчендә районның иң зур авылын йөреп бетерү мөмкин түгел. Әмма шунысы хак: Тымытыкның киләчәге өметле, аңа бетү куркынычы янамый. Яшь гаиләләр күп, балалар бакчасына бүген 53 сабый йөри. Ә иң сөендергәне – авылда балалар татарча сөйләшә, монысы күңелгә май булып ятты. Эш урыннары турында да сораштык: йөреп эшләүчеләр күп. «Ир-атлар икешәр автобус төялеп чыгып китә», – диделәр. Азнакай, Әлмәткә барып хезмәт куялар, нефтьчеләр шактый икән. Кыскасы, телəге булган кеше тик утырмый. Бәхетле авыл бу, дип кайттык. Яшәү өчен бөтен мөмкинлекләр бар, шәһәргә дә чагыштырмача якын. Ә бүген болар бик мөһим.

технологияләр белән эшлим. Мисал өчен, стринг-арт дигән ысул: кадакка җепләр тарттырып эшләү. Бүген бик популярлашып килә торган юнәлеш. Тагын рәсемне мәрҗәннәр белән ясыйм, монысы да бик ошый.

– Ә болай картиналар ясарга кемнән өйрәндегез? – дим.

– Интернеттан, – ди әңгәмәдәшем. – Күңел гел иҗатка тартыла, матурлык тудырасы килә. Яңа берәр әйбер күрсәм, шунда ук кызыксынам. Тагын әле кәгазьне кисеп, төрле сыннар ясыйм, анысы паперкрафт дип атала. Әйтәм бит, гел эзләнүдә. Авыл балаларына да өйрәтәм, мәктәптә мастер-класслар үткәрәм. Күрше районнардан да өйрәнергә, карарга киләләр, үзебезнең районга чакыралар. Картиналар белән төрле конкурсларда катнашам, урыннар алам...

«Бал кортлары» волонтёрлары җитәкчесе Люция Шәйгарданованың кул эшләрен күреп тә ис китте. Гади эш бияләеннән башлап, әллә нинди затлы күлмәкләр, ирләр костюмына кадәр тегә, курчаклар ясый. Һәм чигә дә. Әле тагын бер шөгыле бар – тукымадан шәҗәрәләр ясый.

– Туган көннәре җитсә, туганнарга шәҗәрә бүләк итәм, – диде Люция апа. – Ирем Илһам ягын да шулай өйрәнеп эшләдем. 190 кешегә кадәр җиткергән шәҗәрәләрем бар. Бездән соң килгән буынга калсын дип тырышам, тарих бит ул.

Люция апа биш бала анасы да! «Ана даны» медаленә ия. Балалары зур инде, төп нигездән чыгып киткәннәр. Җәмәгате Илһам белән дүрт ул, бер кыз үстергән ул.

– Илһам да, мин дә тынгысыз кешеләр, – дип дәвам итте Люция апа. – Эштән өйгә кайтып, тыныч кына утыру безнең гаиләгә

Авылда төзек чишмәләр күп.

ТАРИХ БИТЛӘРЕННӘН

– Авылның оешу тарихы шактый үзенчәлекле: XVII гасыр башларында Башкортстанның «юрми» дигән кабиләсе Ыкның уң ягына килеп урнаша. Авылга Тымызык дип исем бирәләр. Ни өчен соң? Авыл янәшәсендәге күлләр тыныч булганга, «тымызык» дип атыйлар. 1750 нче елларда Ыкның сул ягына татарлар килеп урнаша. Нәтиҗәдә, Тымытык дигән татар авылы барлыкка килә. Дөрес, беренче булып Ыкның уң ярына урнашкан авылда да башкорт татарлары яши.
Бездә халык игенчелек белән шөгыльләнгән, бик оста чана табаны бөгүчеләр, балта осталары күп булган. Йон да теткәннәр. Авыл укымышлы да саналган.
1886 елгы архив документларына караганда, Тымытыкта җиде биналы мәдрәсә эшләгән. Һәм анда 300дән артык шәкерт белем алган. Мәдрәсәдә язучы Таҗетдин Ялчыгол белем биргән, 1875–1885 елларда язучы, педагог Закир Һади укыганлыгы билгеле.

Илһам Шәйгарданов, авыл тарихы белән кызыксынучы

Казаныбызда сакланып калган, тарихлары милли мәдәниятебезнең асыл шәхесләре белән бәйле агач йортлар белән таныштыруны дәвам итәбез. «Казанның агач йортлары» проектын «Татарстан» журналы «Татар ядкәрләре» шәхси оешмасы белән берлектә эшли.

Фото: Александр Ефремов, Арбузовлар музей-йорты архивыннан

КАЗАННЫҢ ТЫН ТЫКРЫКЛАРЫ: АРБУЗОВЛАР ЙОРТЫ

Луиза Янсуар, Фәнзилә Җәүһәрова

Дөресен генә әйткәндә, үз Казаныбызның тын тыкрыкларында урнашкан тарихи мирасны бик аз беләбез. Ничә еллар буена янәшәсеннән узгалап та, эчендә нәрсә яшеренеп ятканын ваемламаган бер мәдәни һәйкәл белән таныштырабыз бу юлы. Сез дә тирәсеннән узып йөрисездер, бәлки. Ул – күренекле академик Арбузовлар династиясенең йорты.

ВАКЫТ БУЕНЧА КҮЧЕШ

Кеше күзеннән яшеренебрәк утырган Катанов тыкрыгындагы бу йорт бөтенләй башка тарихи яссылыкта изрәп тибрәнгәндәй тоелды. Әйтерсең, үзебез дә сизмичә, вакыт буенча күчендек. Һәр ишек тоткасына кадәр борынгылыгын югалтмаган, бөтен Россия күләмендәге сирәк сакланып калган агач архитектура һәйкәлләре эталоны исемлекләренә кертелгән бина ул.

Стиле һәм эстетикасына килгәндә, агач модернның ачык мисалы булган шәһәр утары рәвешендә 1913 елда төзелгән. Революциягә кадәр биредә рәссам Иван Шишкинның туганнан туган сеңлесе Мария Алексеева яшәгән. 1916–1968 елларда, ярты гасырдан артык, йортта легендар академиклар династиясе – Александр Арбузов һәм аның олы улы, шулай ук химик Борис Арбузов гаиләсе көн итә.

20 МЕҢ ТӨП НӨСХӘ ЭКСПОНАТ

Утар беркайчан да үзгәртеп корылмаган, шуңа биредә барысы да элек ничек булган, шул хәлендә сакланган. Музей-йортның бай коллекциясендә 20 меңнән артык төп нөсхә экспонат теркәлгән. Мемориаль музей истәлекле бүләкләр, сәнгать предметлары, бай китапханә, музыкаль инструментлар, киндерләр белән дә җәлеп итә. Әнә китап шкафында Рус физика-химия җәмгыяте чыгарган фәнни журнал фолиантлары. Әнә Польшадан махсус кайтартылган, кунак бүлмәсенең яртысын тотырып утырган

затлы Kerntopf рояле, өстендә – Александр Ерминингельдовичның яратып уйнаган скрипкасы. Диварларда атаклы химикның тагын бер мавыгуы – ул Айвазовский, Куинджи манзараларының күчермәләрен җентекләп ясаган.

СИРӘК БӘХЕТ

Атаклы химиклар сәнгатьне генә түгел, ә табигатьне, актив, сәламәт ялны да югары бәяләгән. Аш бүлмәсенә килеп тоташкан җәйге веранда – моның ачык мисалы. Ул гаҗәеп. Верандадан зур булмаган декоратив бакчага төшәсең, анда – француз ыспайлыгын хәтерләткән квадрат түтәлләр, Арбузовлар үз куллары белән утырткан куаклар, агачлар, чәчәкләр. Александр Ерминингельдович әле тагын Иделдә балык тотарга, кышларын чаңгы шуарга да яраткан.

– Мемориаль пространствоны да, йортны да, коллекцияләрне дә шушылай саклап кала алу – сирәк бәхет, – дип елмая музей-йортның мөлаем директоры Наталья Кореева.

Сүз уңаеннан, «керем йорты» беркайчан да Арбузовларның турыдан-туры үз милке булмый: башта аны Мария Алексеевадан арендалап торалар, соңыннан йорт дәүләт карамагына күчә. Тагын бер үзенчәлекле деталь: биредә чын мәгънәсендә галим кабинеты юк, гәрчә эш өстәле булса да. Арбузовлар йортының кануны: өйдә вакытыңны кадерле кешеләреңә, гаилә әгъзаларына багышларга.

1969 елда мемориаль музейда беренче экскурсияне Борис Александрович үзе уздыра. Ул аны химия белән кызыксынган кешеләргә генә кирәкле булыр, дип уйлый. Һәм ялгыша – бирегә казанлылар гына түгел, бөтен Россиядән, чит илләрдән дә халык агыла.

Бина Татарстан Республикасының мәдәни мирас объекты исәпләнә.

Об'явление работы худ. Л. Гамбургер. 1925 ел

«Татарстан» журналының реклама бүлеге:

тел.: (843) 222-09-79, 8-9600-487-900, 8-9033-132-741

Реклама 16+